Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2022

# РУХИ МИРАС

## Эзләнүләр һәм табышлар

*17 нче чыгарылыш*

**Галимҗан Шәрәф.**
**Әсәрләр, хатлар, документлар**

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

## Поиски и открытия

*Выпуск 17*

**Галимджан Шараф.**
**Сочинения, письма, документы**

УДК 94 (093)
ББК 63.2
Р 82

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024)»
ТР Дәүләт программасы кысаларында
ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге
тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***И. Г. Гомәров** (проект җитәкчесе һәм җаваплы мөхәррир),*
***А. М. Ахунов, Э. М. Галимҗанова***

**Төзүчеләр һәм текстларны әзерләүчеләр:**
***Э. М. Галимҗанова, Г. Н. Зәйниева,***
***Ф. Г. Фәйзуллина, Г. А. Хөснетдинова***

Р 82 **Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Галимҗан Шәрәф. Әсәрләр, хатлар, документлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Галимджан Шараф. Сочинения, письма, документы** / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Э.М. Галимҗанова, Г.Н. Зәйниева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.А. Хөснетдинова; кереш сүз авт. Ф.Г. Фәйзуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2022. – 17 нче чыг. – 300 б.
ISBN 978-5-93091-434-4

Җыентык татар халкы рухи мирасының нигезен тәшкил итүче әсәрләрне өйрәнү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару, татар текстларын өйрәнү барышындагы яңа табышлар белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә.

Сериянең чираттагы саны тел галиме, язучы, педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Галимҗан Шәрәф (1896–1950) тормышына һәм иҗатына багышлана. Китапта галимнең фәнни мәкаләләре, әдәби әсәрләре, чыгышлары, хатлар, иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә һәм тәрҗемәи хәленә кагылышлы материаллар туплап бирелде. Текстларның күбесе гамәлдәге хәрефләр белән беренче тапкыр дөнья күрә.

Басма белгечләр, татар мәдәнияте һәм тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-434-4

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2022

## КЕРЕШ

Заманының төрле фаҗигалы юллары аша үтеп, үзен аямыйча халкына хезмәт иткән Галимҗан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1896–1950) татар тарихында аерым игътибарга лаек шәхес. Ул – тел галиме, педагог, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче һәм шагыйрь дә.

Кечкенәдән үз көнен үзе кайгыртып тормыш итәргә өйрәнгән Шәрәфетдин Хөснетдин улының (1852–1916) биш баласы тарихта билгеле шәхесләр булып танылалар. Ир туган Шәрәфләрнең иң кечкенәсе – Галимҗан.

Заманына күрә укымышлы кеше булган әтиләре Шәрәфетдин белән әниләре Гайнелнәвал (1853–1936) үрнәгендә, аларның балалары да яшьтән аң-белемгә тартыла. Галимҗан башта Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый (1912), 2 нче реаль училищены (1915) тәмамлый. Аннан соң 1917 елга кадәр Петроград тимер юл инженерлары институтында белем ала. Әмма бу белгечлек Галимҗанның милли җанлы күңелен канәгатьләндерә алмый, күрәсең, ул шул ук вакытта университетта В.В. Бартольд, В.Д. Смирнов, Л.Б. Щерба, А.Н. Самойлович, И.Ю. Крачковский кебек Шәрык белгечләренең лекцияләрен тыңлый. Шигърият дөньясы белән кызыксынуы аркасында С. Есенин, А. Блок, А. Ахматова һ.б. шагыйрьләрнең иҗат кичәләренә дә йөри.

Институтта уку чорында Г. Шәрәф Петроград студентларының «Татар учагы» дип аталган оешмасын оештыручыларның һәм җитәкчеләрнең берсе була. «Алар түгәрәк утырышларында Явыз Иванның колониаль сәясәте нәтиҗәсендә дәүләтчелекләрен югалткан Русия мөселманнарының милли-мәдәни үсеше мәсьәләләрен тикшерәләр, кайбер татар зыялыларының пантюркизм һәм панисламизм белән мавыгуларын тәнкыйтьлиләр, мөселман халыклары мәдәниятенә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча фикер алышалар»[1].

Февраль революциясе Г. Шәрәфнең язмышына кискен үзгәрешләр кертә. Ул укуын ташлап, сәяси эшчәнлеккә керешә: I–II Бөтенроссия мөселман корылтайларында катнаша (1917), Милләт мәҗлесе депутаты итеп сайлана (1917–1918). Милләт мәҗлесе карары белән «Идел-Урал штаты»н гамәлгә ашыру буенча махсус сайланган һәйәтнең рәисе итеп билгеләнә. Ләкин уй-максатлары төрле каршылыкларга очрау нәтиҗәсендә, Г. Шәрәф үзенең сәяси активлыгын киметергә мәҗбүр була. Инде 1917 елдан ук Казан университетының тарих-филология

---

[1] *Вәлиев Рәмзи.* Фаҗига. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 10–11.

факультетында танылган тел галимнәре, тюркологлар Н. Ашмарин, В. Богородицкий, Н. Катановларның лекцияләрен ирекле рәвештә тыңлаган Г. Шәрәф гыйльми эшчәнлеккә күчә. Эксперименталь фонетика өлкәсендә әлеге белгечләр җитәкчелегендә чуваш, татар телләре һәм гомуми лингвистика буенча тикшеренүләрен башлап җибәрә. Бу елларда көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булган татар орфографиясен үзгәртү буенча да ул зур тырышлык куя. Үзенең «гарәпчеләр» тарафдары булуын ачыктан-ачык белдереп, 1926 елның февраль-март айларында тюркологларның Баку шәһәрендә үткәрелгән I Бөтенсоюз корылтаенда да, фикер-тәкъдимнәрен төрле дәлилләр белән раслап, зур доклад ясый. Г. Шәрәфнең әлеге мәсьәлә буенча ВКП(б) ҮК Генераль секретары И.В. Сталинга хат юллавы да билгеле.[1] Мондый адымнар Г. Шәрәфнең максатына туры баручан кеше булуын тагын бер кат раслый.

Тел өлкәсендәге гыйльми эшчәнлеге белән беррәттән Г. Шәрәф этнографик статистика буенча да фәнни тикшеренүләр алып бара. 1920 елда ТАССРны оештыруда актив катнаша. ТАССРның беренче этнографик картасын (1922) һәм торак пунктлары исемлеген (1936) төзи.

Г. Шәрәфнең Казандагы Шәрык педагогика институтындагы эшчәнлеге (1922–1937) аеруча әһәмияткә лаек. Биредә ул тел, тарих, этнография буенча лекцияләр укый. Татар теле фонетикасы мәсьәләләре белән ныклап шөгыльләнә. Олы галим һәм оста педагог буларак, яшьләрне тәрбияләүдә үзеннән зур көч куя.

«Сонорная длительность татарских гласных» (Казань, 1923), «Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русским» (Казань, 1927) хезмәтләре нигезендә мәшһүр тел галимнәре И.И. Мещанинов, А.Н. Самойлович, Л.В. Шерба Г. Шәрәфнең фәнни эшчәнлегенә зур бәя бирәләр һәм аны, докторлык диссертациясе якламаган хәлдә дә, профессор исеменә лаек дип билгелиләр.

Г. Шәрәф җыентыклар төзүче буларак та танылa. Ул 1913 елда «Җәмигыль кямил (афоризмнары), халык мәкальләре урынында йөрерлек вә йөртелә торган сүзләре» исем асты белән «Тукаев сүзләре» дигән җыентык бастырып чыгара. Күренекле тел галиме Г. Шәрәф, Г. Тукай әсәрләренең һәр сүзенә игътибар итеп, әдипнең афоризмнарга тиң гыйбарәләрен туплый[2]. Аның фольклор әсәрләреннән, татар шагыйрьләре иҗатыннан җыйналып, «Балалар күңеле» сериясеннән басылган

[1] *Вәлиев Рәмзи.* Фаҗига. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 32–34.

[2] Духовное наследие: поиски и открытия / под ред. И.Г. Гумерова. – Казан: ИЯЛИ, 2016. – Вып. 1. – С. 27–47.

«Гөлчәчәк» (1919) әкияте китабы, «Мәсәлләр. Үз шагыйрьләребездән» (1921), «Милли моңнар» (1921) җыентыклары мәгълүм.

Г. Шәрәф тәрҗемәчелек белән дә шөгыльләнә. Ул Г. Рәхим, Г. Камал, Ш. Камал һ.б. язучыларның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. И.А. Крылов, В.С. Никитин кебек рус мәсәлчеләренә ияреп, аларның әсәрләрендәге сюжетларга нигезләнгән мәсәлләр дә яза.

Киң карашлы Г. Шәрәф үзен борчыган мәсьәләләрне хәл итү максатыннан төрле фәнни өлкәләрдә актив эшли. Шуның нәтиҗәсендә, «1926 елда СССРның өлкәләрне өйрәнү Үзәк бюросына әгъза-корреспондент һәм СССР Фәннәр академиясенең СССРдагы һәм чиктәш илләрдәге кабиләләр составын өйрәнү Комитетына әгъза итеп сайлана. 1929 елда эксперименталь фонетика буенча Халыкара ассоциациягә хакыйкый әгъза буларак кабул ителә»[1].

1920 еллар ахырыннан Г. Шәрәфнең үз халкы өчен эшләгән тырышлыклары берьяклы бәяләнеп, аңа ялa ягулар башлана, аның исеме «халык дошманнары» исемлегенә эләгә. 1937 елның 23 мартында Г. Шәрәф кулга алына. Өч ел дәвамында берөзлексез сорау алулардан соң, 1940 елның 27 февралендә галим сигез елга хезмәт төзәтү лагере җәзасына хөкем ителә[2]. Тоткынлык срогын тутырып, тәмам авыруга сабышкан Г. Шәрәф 1945 елның апрелендә ирекккә чыгарыла. Ләкин Казанда яшәргә рөхсәт булмау сәбәпле, татар теле укытучысы буларак, Апас районына җибәрелә. 1945 елның 15 сентябреннән 1946 елның 31 гыйнварына кадәр ул Апас райпедкабинетында методист булып эшли[3]. Исәнлеге бик начарайгач кына, Казандагы бертуган сеңлесе Фатыйма янына кайтып яшәргә рөхсәт ала һәм 1950 елның 13 гыйнварында вафат була. ТАССР Югары судының 1958 елдагы 2 февраль карары нигезендә аның исеме тулысынча аклана.

Галимҗан Шәрәфнең шәхси тормышын өйрәнүдә, татар халкы тарихында тоткан урынын билгеләүдә тарих фәннәре докторы профессор Рәмзи Вәлиев зур эш башкарды. Галимнең җитди эзләнүләре нәтиҗәсендә язылган «Фаҗига» китабы (Казан, 1996) нәкъ менә бертуган Шәрәфләрнең фаҗигалы язмышларына багышланган. Г. Шәрәфнең тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеген яктыртуда Ф.Й. Йосыповның тәфсилле мәкаләләре дә игътибарга лаек.

[1] *Вәлиев Рәмзи.* Фаҗига. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 28–29.

[2] Г. Шәрәф Севердорлаг – НКВДның төньяк тимер юл хезмәт лагеренә җибәрелә.

[3] ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. 20 ф., 2 тасв., 1 сакл. бер.

«Чемоданнарда, шкафта һәм башка җирләрдә калган шигырь, басня һәм фәнни кульязмаларымны һәм барлык биографик кәгазьләремне – һәммәсен җыеп, филиал академия наукның тел, әдәбият кабинетына (институтына) ТНИЯЛИгә тапшырырга» – әлеге сүзләрне Г. Шәрәф үзенең берничә вариантта язылган васыятьнамәләрендә теркәп калдырган. Бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә 1946–1947 елларда үзе, 1963 елда сеңлесенең кызы тапшырган һәм соңрак аерым шәхесләр китергән материаллар саклана.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең Галимҗан Шәрәфкә багышланган чираттагы чыгарылышында, нигездә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана торган материаллар урын алды.

Күренекле тел белгече буларак танылган галимнең фонетика мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре, Беренче тюркология съездында татар орфографиясен үзгәртүгә кагылышлы ясаган чыгышлары китапның беренче бүлегенә урнаштырылды.

Фондта сакланган кульязма шигырь дәфтәрләре Г. Шәрәфнең шагыйрь булуы хакында сөйлиләр. Ул шигырьләр күбесенчә балаларга багышланган. Икенче бүлеккә аның әдәби эшчәнлеген яктырткан материаллар: шигырьләр, тәрҗемә әсәрләр кертелде.

Өченче бүлектә Г. Шәрәфнең тормышына һәм иҗатына караган документлар, хатлар, төрле бәяләмәләр бирелде. Аның тоткынлыктан гаиләсенә, туганнарына язган хатлары аеруча кызыклы. Шигъри юллар белән язылган хатларын ул сагынмалык дип атый. Сагынмалыкларның да кайберләре укучылар игътибарына тәкъдим ителде.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең әлеге чыгарылышы Г. Шәрәф мирасын туплау һәм өйрәнү юлындагы фәнни тикшеренүләрнең дәвамы булып тора. Китапта урын алган текстлар, аңлатмалар Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәрләре Э.М. Галимҗанова, Г.Н. Зәйниева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.А. Хөснетдиновалар тарафыннан әзерләнде.

*Ф.Г. Фәйзуллина*

# I бүлек

# ГАЛИМҖАН ШӘРӘФНЕҢ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

# ТЕЛ ӨЛКӘСЕНӘ КАРАГАН ХЕЗМӘТЛӘРЕ

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ФОНЕТИКАСЫ

Тел коллективы[1] эчендә аңлашуда, эш процессларында, сыйнфый көрәшне оештыруда, социализм төзүдә, төрле тел коллективларының бер-беренә мөнәсәбәт-катнашуларында һәм җәмгыять тормышының бөтен башка тармакларында чиксез зур роль уйнаган тел – ул бик катлаулы бер хәдис.

Мисал өчен шагыйрь Һ. Такташ шигырьләреннән бер өземтә алыйк:

Бүгенге көн ул сыйнфый катламнарның
Соңгы каты көрәш заманы,
Без искене җимереп,
Планетада
Тигез тормыш,
Матур, яңаны
Төзү юлы белән янабыз.
Һәрбер планетаны сыйныфлардан
Тазартуга таба барабыз...

Бу өземтә зур бер шигырьнең кечкенә бер кисәге генә булуына карамастан, тирән мәгънәне аңлата. Өземтәгә кергән җөмләләр, юллар, аерым сүзләр, хәтта «сыйныф-сыйнфый (сыйнф-и), сыйныфлардан (сыйныф-лар-дан), катлауларның (кат-ла-у-лар-ның) сүзләрендәге кебек, сүзләрнең аерым кисәкләре дә барысы бергәләп мәгънәләр аңлатуга, бөтен шигырь биргән мәгънәне төрлечә, төрле рәвештә тулыландыра.

Телнең төп вазифасы тел коллективы әгъзалары практикасында бер-беренә төрле мәгънә, фикер, фигыльләрне аңлатуда хезмәт

[1] Аваз (фонетика), форма (морфология, синтаксис) һәм мәгънә (лексика, семантика) якларыннан билгеле кануннар һәм нормалар буенча төзелгән һәм яшәгән уртак телдә сөйләшүче, аңлашучыларны бергә җыеп алганда тел коллективы дип атыйбыз. *(Г. Шәрәф иск.)*

итү булганга, телнең мәгънә (аң) ягы аңардан төп максатны тәшкил итә. Шуңа күрә Карл Маркс телне «практик, реаль аң» дип тәкбир дә итә. Шуның белән бергә безнең телебез – аваз теле. Без төрле мәгънәләрне аңлату, чагылдыру сүзләре җөмләләр төзү, аларның мәгънәләренә төрле төсмерләр өчен, төп материал буларак, аваз материалы белән файдаланабыз. Без аваз материалы белән бөтен тел коллективы әгъзаларына таныш, уртак булган шартлы билгеләр, символлар мәйданга китереп, шулар белән практик реаль аңда объектив барлыкны сыйнфый карашлар белән сугарып чагылдырабыз, тәкбир итәбез.

Югарыда шагыйрь Такташтан китерелгән мисалда без:

1) һәрбер сүзне бирү өчен сөйләү аппаратының төрлечә хезмәтләре белән мәйданга китерелгән *«б, у, г, н, е, л, с, ф...»* кебек аерылмалы /..../[1] авазлары белән;

2) аларның мәгълүм формада бер-беренә кушылуыннан гыйбарәт булган «бү-ген-ге, сый-ныф-лар, ке-реш» дигәндәге кебек иҗекләр белән;

3) аваз һәм иҗекләрнең көе, интонация, ритм һәм башка яклардан төрләнүләре белән файдаланабыз. Болар барысы да сүзләрнең төрле кулланышларында мәгънәле сүзләрне, аларның тезмәләренең, җөмләләрен һәм аларның комплексларын мәйданга китерүдә тел коллективында яшәгән нормалар буенча кулланыла торган үзенә бертөрле төзү материалы булып хезмәт итәләр. Рәсемнәр, картиналар мәйданга китерүдә буяулар, аларның төрле төс һәм төсмерләре нинди роль «уйнаса, сүз һәм җөмләләр төзүдә аваз материалы да үзенең төрләнешләре белән шуйдыйрак роль» уйнады.

Монда ләкин аерма да бар. Буяуны турыдан-туры табигатьтән алсак, мондагы авыр материал – катлаулы социаль тормыш процессында һәм нәтиҗәсендә кешелек җәмгыятенең үзе тарафыннан мәйданга китерелгән материал.

Төрле аваз комплексларыннан төзелгән сүз һәм җөмләләрнең шартлы билгеләр буларак, катлаулы һәм катлаусыз мәгънәләрне чагылдыру, бердән, бу тел коллективы һәм, гомумән, кешелек җәмгыятенең чиксез озактан башланган тарихы һәм тарихка кадәр тормыш тәҗрибәләренең, сөйләшү һәм тыңлаучының тел коллекти-

[1] Чыганакта шулай бирелгән.

вында үткән хәят һәм хезмәт практикасына, сыйнфый аңына таянса, икенчедән, сөйләү-тыңлау, язу-уку процессы барган конкрет реаль барлыкка, дөресрәге, шул барлыкның тел белән файдаланучыларның аңында чагылуына таяна.

Сүзләр, җөмләләр төзүдә файдалана торган авазлар системында, ул авазларны төрләндерү һәм язуда күрсәтү юлларында һәрбер телнең үзенә күрә аермалыклары бар. Бу аермалыклар һәм, гомумән, телнең аваз ягы тел гыйлеменең фонетика бүлегендә тикшерелә.

Димәк, бер телнең фонетикасында шул телдә сүзләр төзүдә кулланыла торган авазлар, ул авазларның тел коллективында уртак файдаланылган төрләнешләрне, үзгәрешләре, сүзләр төзү өчен нинди комбинацияләргә керүләре һәм телне язуда ничек бирү мәсьәләләре тикшерелә.

Телнең идеология, фикер, мәгънә яклары, форма яклары, аваз яклары, хәтта сөйләү барган социаль урталык һәм, гомумән, конкрет барлык мохит шартлары безнең тел белән файдалануыбыз вакытында аерылмаслык берлек тәшкил итәләр. Без бары тикшерү, җентекләү уңайлыклары ягыннан карап кына, башка фәннәрдәгечә боларны бер-береннән аерыбрак, үз эчләрендә дә бүлгәләштереп, бер үк хадисәнең[1] төрле яклары итеп кенә аерым-аерым бүлгәләп тикшерә алабыз. Болай итеп тикшерү аерым якларны тирәнрәк, җентекләбрәк, системныерак рәвештә өйрәнүгә ярдәм итә. Фонетикада телнең аваз ягын аерыбрак алып тикшерү дә шуңа таяна. Шуның белән бергә бервакытта да тикшергән ягыбызны бөтен комплексның бер генә кисәге, бер генә ягы икәнен онытмаска, аның бөтен комплекста җәмгыять формасында ничек үзгәреп торуын һәрвакытта хәтердә тотарга тиешбез. Соңгы моментны хәтердә тоту гына безгә бөтеннән кисәккә йә кисәктән бөтенгә күчеп тикшерү мәсьәләсен җентекләү уңайлыгы ягыннан чыгып хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Телнең аваз ягын тикшерүнең әһәмияте түбәндәге моментларга кайтып кала: 1) телнең аваз ягын да тикшерү, телнең гомуми табигатен тикшерүнең бер кыйсеме булып килә; бу ягын да тикшермичә, бер телнең гомуми табигатен тулы белә алмыйбыз; 2) без киләчәктә халыкара масштабта уртак бер телгә омтылабыз; бу тел-

[1] Хадисәнең – күренешнең, вакыйганың.

не без хәзерге аваз теле итеп алдыбызга китерә алганга, хәзерге телнең аваз якларын да җентекләп кенә без киләчәк телнең бу ягы турында планлы хәзерлекләр алып бара алачакбыз; 3) аерым телнең үзлекләре, телләрнең бер-беренә мөнәсәбәте аларның аваз якларына да караганга, бу үзлекләрне без аларның аваз якларын да тулы тикшереп кенә белә алабыз; 4) һәр телнең язу-орфография мәсьәләләре, морфология, синтаксисына һәм телнең тарихына караган бик күп мәсьәләләр телнең аваз ягын да җентекләп тикшергәндә генә ачыла алалар; 5) тасвирлаучы, стандарт әдәби әйтеш (орфоэпия), сәлпелекләрне (әйтеш техникасы җитешсезлекләрен) төзәтү, уку-язу таныту, чит тел өйрәнү һ.б. шундый процессларны телнең аваз ягын да ныклап тикшерү аркасында гына конкрет калыплы һәм аңлаулы /.../[1] рәвештә тормышка ашырырга мөмкин. Бу моментларның күбесе тел белгечләре өчен генә түгел, һәрбер аңлы граждан өчен дә әһәмиятле булуы телнең теориясен тикшерүдә аның фонетикасына да урын бирергә тиешлекне күрсәтә.

Ф. Энгельс «Табигать диалектикасы» дигән әсәрендә түбәндәге сүзләрне яза: «Кул һәм хезмәтнең үсеше белән бергә башланган табигатькә хакимлек, һәр яңа адым саен кешенең күз күремен киңәйтә барган. Табигать әйберләрендә ул торганнан торган, яңа, моңа кадәр билгеле булмаган хасиятләрне ача барган. Икенче яктан, хезмәт аркасында бергә эшләүдән, бер-береңә булышкан чаклар ешланып, җәмгыятьнең аерым членнары өчен болай бергәләп эш күрүнең файдасы аңлана барганда, хезмәтнең үсеше җәмгыять әгъзаларының бер-беренә якынаячак, берегүләренә сәбәпче булган. Кыскача әйткәндә, формалашкан кешеләр бер-беренә нәрсәдер әйтеп, кирәксенүгә барып җиткәннәр. Ихтыяҗ үзенә органны тудырган: тәдриҗи[2] рәвештә көчәя барган модуляцияләр (*тон-интонацияләр үзгәртүләр. – Г.Ш.*) аркасында маймылның примитив бугазы акрынлап, ләкин тайпылусыз яңа рәвешкә керә барган һәм авыздагы органнар акрынлап аермалы (членораздельные звуки) авазларны бере артыннан икенчесен әйтеп белә башлаганнар».

«Телнең үсеше хезмәт процессыннан, шуның белән бергә килеп чыккан карашының бердәнбер дөрес аңлау булуы хайваннар белән чагыштырудан күренә. Соңгыларының, хәтта иң алга

[1] Чыганакта шулай бирелгән.
[2] Тәдриҗи – эволюцион.

киткәннәренең дә бер береңә аңлатасы аз-маз нәрсәләре – аерылмалы сөйләм, башка да аңлатылырлык нәрсәләр генә...»

«Иң элек хезмәт, аннан соң һәм аның белән берлектә аерылмалы сөйләм (членораздельная речь) – маймыл миенең, төп төзелеше ошау белән бергә, зурлыгы һәм бөтәюе өстен булган кеше миенә әйләнә алуына тәэсир итүче иң төп стимуллар булганнар», – ди.

1) Тел җәмгыять тормышында хезмәт процесслары кысрыклавы белән кешеләр шул процессларда аңлашуны кирәксенүләре нәтиҗәсендә туган[1] хезмәт, сәнгать һәм аң белән бергә үскән; 2) аермалы (членораздельный) аваз теле, хезмәттән кала һәм хезмәт белән бергә, кешелек дөньясының башка хайваннар дөньясыннан аерып, кешеләргә өстенлек бирүче төп сәбәп булган; 3) хезмәт белән тел, кешенең аңын өзлексез рәвештә үстереп барып, хайваннар белән кеше арасындагы аерманы торганнан тора тирәнәйтә барган; 4) хайваннарның да бер-беренә аңлатасы аз-маз нәрсәләре булса да, аларның иң өстеннәрендә дә бу хәл аермалы авазлар белән аңлашуны кирәксенү дәрәҗәсенә барып җитми, хайваннарда да аз-маз инстинктив аңлашулар булса да, бу аермалы авазлар, аерым сөйләм белән эшләнми; 5) аермалы авазлар белән файдалана башлауга кадәр һәм шуңа хәзерлек баскычы булып, кешелек дөньясында бугазда (гырылдыкта тавыш төрләндерүдән гыйбарәт булган интонация модуляцияләренең аңлашу өчен әһәмиятле булган, аерылмалы аваз теленә якынаю дәверендә болар белән файдалану арткан, модуляцияләр көчәйгән; 6) телдә аваз – фонемнарның туу һәм формалашу процессы сөйләү аппаратының да бөтәюе белән бәйләнеп барган; 7) телнең башлангыч баскычларында кешеләр җәмгыятьтә, хезмәттә, үсеш процессында авазларның бере артыннан икенчесен тудырганнар, кешеләрнең сөйләү аппараты бу үсеш процессында авазларны төрләндерүгә барган.

Карл Маркс «Фейербах турында» дигән әсәрендә аңның тел рәвешендә мәйданга чыгуы һәм хәрәкәтләреннән гыйбарәт булган аваз дулкыннарына таянуын «материя белән авазлануы» дип тәкбир итә, шуның белән Маркс телнең аваз ягы аның иң материал (матди)

[1] Кешелек җәмгыятенең мәйданга килешендә, үсешендә шул җөмләдән телнең туыш һәм үсешендә хезмәтнең әһәмиятен тагын бер кат күрсәтеп китү өчен, Энгельснең шул ук әсәренең башындагы хезмәт турындагы өземтәсен китерәм. (*Г. Шәрәф иск.)*

ягы икәнен ачып китә;[1] яктылык дулкыннары фотография кәгазенә төшереп алырлык, электр дулкыннары зур машиналарны әйләндерерлек, поездлар йөртерлек материаль нәрсәләр булган кебек, аваз дулкыннары да – колак белән ишетү генә түгел, машиналар белән яздырып, «тотып» алырлык шундый юллар белән күз белән дә күрерлек материаль нәрсә. Радио белән файдаланып, без аваз дулкыннарын теләгәнчә еракка җибәрә алабыз. Фонограф, граммафон белән без бер мәйданга килгән аваз дулкыннарын беркетеп, теләгән кадәр кабатлап, мәйданга китерә алабыз. Эксперементаль фонетикада аваз дулкыннарын шулай тотып алып тикшерәләр дә. Каты шартлау вакытында аваз дулкыны белән ватылулар булу, аваз дулкыннарының материаль булуы өстенә шактый «көчле» дә булуларын күрсәтәләр.

Телнең аваз ягы – материализм нигезендә турыдан-туры тикшерелә ала торган ягы. Телдәге мәгънәләр, формалар исә, аваз дулкыннары нәкыше белән бирелгән шартлы билгеләр ярдәме белән генә конкрет ачыла, шул материал аркылы гына тел теориясендә тикшерелә ала. Без югарыда сөйләгәннәргә таянып, телнең башка якларын тикшерү белән бергә, аның аваз ягы да тикшерелергә, кирәгенчә җентекләнергә тиеш, дип таныйбыз. Кайберәүләр куйганча, тел тикшерүдә аның аваз ягын бөтеннән бер читтә калдыру – нигезсез бер караш;[2] шуның белән бергә, югарыда әйтелгәнчә, телнең аваз ягы, коллективта аңлашу вакытында булганча, аны (телнең аваз ягын) тикшерү телнең тагын да әһәмиятлерәк булган мәгънә (семантика), лөгать (лексика), якларын һәм мәгънә ягы белән нык бәйләнгән форма (морфология, синтаксис) якларын тикшерү өчен

[1] Башлангыч дәвердәге аңлашуда интонация төрләндерүләр белән беррәттән бик зур урын тоткан кул изәү, чырай үзгәртүләрдән торган хәрәкәт (кинетика) теле мәсьәләсе генә бу өземтәдә кузгатылмаган. Кинетика, бигрәк, кул теле мәсьәләләре бездә Октябрь революциясеннән соң академик Марр тарафыннан киң итеп куелды. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Мондый карашка мисал итеп марксистик критика тарафыннан меньшевиклanучы идеалистлыгы ачылган Волошинның «Марксизм һәм тел фәлсәфәсе» (М., 1929) дигән әсәрен күрсәтергә мөмкин. Материалистик диалектикага каршы булган ялгыш карашлар белән тулган бу әсәрдә фонетикага, бигрәк тә эксперименталь фонетикага каршы көрәш алып барыла, аны тел белеменнән чыгарып ташлап, физика бәхәсе итеп кенә калдырырга тәкъдим ителә (В.С.). Бу мәсьәләдә һәм башка кайбер мәсьәләләрдә Волошинчылык белән авыручылар безнең телчеләр арасында да юк түгел. *(Г. Шәрәф иск.)*

ярдәмче момент булып калганын, шуңар күрә тел тикшерүне, кайбер һинд-европачылар куйганча, аваз ягынарак кына кайтарып калдыруда бөтенләй ялгыш икәнне хәтердә тотарга кирәк[1].

Телнең фонетикасын тикшергәндә, нигез итеп, әдәби сөйләш, «әдәби әйтеш» алына. Әдәби сөйләш әдәби телнең аваздан сөйләнү, әйтелү формасын тәшкил итә. Әдәби сөйләш язма әдәби телдән төрле халыкларда төрле дәрәҗәдә аерыла. Татарның Октябрь революциясе биргән җимеш уңышларыннан булган яңалиф орфографиясе зур күпчелек шартларда фонетикага нигезләнгәнгә, безнең хәзерге язма әдәби-телебез әдәби сөйләшкә бик якын. Алай да кайбер аермалар бар: без *«барганмы, барганда*, *русча, язсам, ашый, күп иде, барган иде, ак ат, кара урман һ.б.»* дип язабыз, *«бардыммы, барганга, руччa, яссам, аши, күбийе, барганыйым, агат, карурман»,* дип сөйлибез. Безнең болай сөйләвебез – индивидуаль сөйләш йә «ялгыш сөйләшү» түгел, бәлки татар әдәби сөйләше өчен гомуми уртак булган норматив (телдәге нормага туры килгән), димәк, дөрес әйтеш. Әдәби сөйләш белән язмадагы аермалар, бердән, язу орфографиядәге төрле уңайлыкларга карап алынган нигезләрдән, икенчедән, инглиз, француз, немец, руслардагы кебек язу теле һәм орфографиянең тарихи үзгәреше, сөйләү теленең үзгәрешенә караганда акрынрак баруыннан килә.

Язма тел белән әдәби сөйләш арасындагы аермалар да фонетикада тикшерелә. Искедән мәдәниятле халыкларда әдәби сөйләшне орфоэпия исеме астында системный кагыйдәләр белән дә бирәләр.

Орфографиядә бөтен тел коллективы өчен уртак стандарт дөрес язу өчен кагыйдәләр куелып, язуның сөйләү, әйтештән аермалары билгеләгәнчә, орфографиядә шулай ук коллектив өчен уртак стандарт булган дөрес сөйләү, әйтеш кагыйдәләре билгеләнә һәм язылганча укылмый. Татар теленең орфоэпиясе дә, әйтешне тагын да киңрәк масштабта тикшерә торган дикциясе дә әлегә ныклы кагыйдәләр белән беркетелмәгән.

Әдәби сөйләшнең ана телендә культурасы күтәрелү белән бергә бәйләнеп бара, шуның белән бергә үсә. Буржуа хакимлеге шартларында артта калган халыкларда, мәхкүм[2] милләтләрдә шивә сөй-

[1] Билгеле, моннан тел тикшерүдә эш бүлешү – аерым мәсьәләләрне аерып алып тикшерү ярамый, дигән сүз чыкмый. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Мәхкүм – хөкем ителгән.

ләшләре генә хөкем сөрә, әдәби сөйләш ясалу, аның массалашуы өчен кирәкле шартлар булмыш. Татар әдәби сөйләше дә татар әдәби теле таралган һәммә җирләрдә, уртак сөйләш формасы буларак, Октябрь революциясеннән соң гына урнаша, массалаша алды. Октябрьдән башлап нык үскән татар театры, радио, мәктәпләр, җыелышлар, съездлар һәм гомумән җәмәгатьчелек тормышы (әдәби язма тел, матбугат белән бергә) әдәби сөйләшне таратучы, массалаштыручы төп факторлар булдылар.

Татар әдәби сөйләшнең нигезендә Казан шәһәре һәм аның тирәсендәге сөйләшләр ята; ул икътисади, сәяси, иҗтимагый, мәдәни тормышта татар теленең башка сөйләшләренең дә тәэсире астында формалашкан, башка телләр белән дә очрашу нәтиҗәсе дә халыкара элементларны да җыйган.

Шивә сөйләшләренең әдәби сөйләштән аермасы кайвакытларда сүз, мәгънә башкалыгы *(этәч – кусак, чүмеч – тустаган – тустак – саблы аяк, баскыч-болдыр – күтәрмә һ.б.),* йә форма башкалыгы *(бар-барган, кил-килгән, барасым килә – баргым кели, барасыз – барасыгыз, барган да – барган дагын)* рәвешендә килсәләр, күбрәк вакытларда бу аерма, әдәби сөйләштәге бер аваз урынына шивәдә икенче аваз сөйләнү, аерым авазларның төсмере башкару рәвешендә килә. «Мишәр» сөйләшләрендә *с* урынына *тс, тч, к-г* урынына калын *к-г* килүе, *«сөйлә, көйлә, көя, кайтам, койрык, бүген, түгел, шулай, болар һ.б.»* урынына *сүлә, күлә, күя, катьам, корьык, беген, тегел, шулай, блай* рәвешендә сөйләүләр, Касыйм шивәсендә *«каткан, киткән, бирәләр»* һ.б. урынына *«айтьан, итьин, бирилир»* рәвешендәрәк сөйләүләр, Минзәлә тирәләрендәге *д-з* авазларын алмаштырулар, Казан артында *«баргаллар, килгәлләр, пысак, песән»* рәвешендә, төньягының кайбер авылларында *«алай-болай»* урынына *«алай-блай»* рәвешендә сөйләүләр болар барысы да әдәби сөйләш һәм шивә сөйләшләренең аваз (фонетика) ягыннан булган аермаларына кайтып калдылар. Димәк, шивәләрне тикшерү, тел коллективы әгъзаларының сөйләшүдәге шивәчелек белән аңлы рәвештә көрәш алып бару, телнең аваз ягында җентекләү нигезендә генә алып барыла ала.

Татар шивәләре арасында әдәби сөйләштән күбрәк аермалы булганы – Касыйм татарлары шивәсе.

Нижгар, Саратов, Пенза, Тамбов мишәрләре исеме астында йөргән шиваләрнең һәм Минзәлә, Казан арты шиваләренең дә кайбер моментларда әдәби сөйләштән күренерлек аермалары бар.

Тарих агышында бу мөнәсәбәтләр үзгәрә дә торалар. Бу мәсьәләләр киңрәк тел-сөйләшнең тарихында һәм диалектология (шиваләрнең җентекләү турындагы фәндә генә тикшерелә алалар. Тарихи агышта аерым шиваләр (диалект) сөйләшләр бетеп, әдәби сөйләш тарафыннан «йотылуга» таба баралар. Гомумән, телләр бер-беренә якынаюга, интернациональләшүгә йөз тоткан кебек, әдәби сөйләш тә халыкара формалар алуга йөз тота.

Октябрьгә кадәрле әдәби тел, гомумән, динчелек, гарәпчелек, төрекчелек кебек буржуа йогынтылары астында барган булса, әдәби сөйләш тә шуларның ук сөремтәләре астында бара иде. Мәктәп-мәдрәсәләрдә иске гарәп теле орфоэпиясе булган «тәҗвид»не биклэтәләр[1], массалаштырырга тырышалар, татарчага ул дәвердә күп санда кергән гарәп сүзләрен «тәҗвидчә» әйттерергә, татарчага да тәэсир иттерергә тырышалар иде. Ул дәвернең мулла-мунтагае, шәкерт, зыялы, бай кулак тирәләре үз сөйләшендә шулар белән куллана, кулыннан килгән, хәтта «китапча» (тәҗвидчә) сөйләшергә дә тырыша иде. Октябрьдән соң хакимият пролетариатка күчкәч, әдәби телдәге гомуми революцион борылыш әдәби сөйләшкә дә тәэсир итә. Гарәпчәләтеп, һәм «укимыз, укыдыгыз, укымыш...» дип, төрекчәләтеп сөйләргә, сөйләтергә тырышучы сыйныфлар, революция агымы белән әдәби телгә, әдәби сөйләшкә тәэсирдән читкә алып ташланалар. Хакимияткә килгән пролетариат сыйныфы бар сөремтеләр урынына интернациональләшү юнәлешен кертә. Формасы белән милли, эчтәлеге белән пролетариатча культураны, шуның бер кисәге булган телне, сөйләшне дә формасы белән дә, эчтәлеге белән дә пролетариатча, интернациональ булган рәвештә кертүгә, социализм төзелешенең бүгенге шәраиты[2] юл куйган дәрәҗәдә хәзерлек алып бара.

Әдәби тел кебек әдәби сөйләш тә сыйнфый хадисә һәм һәр дәвердә сәяси өстен сыйныфлар тәэсире астында яши.

Тарихи дәверләр, хакимияттәге сыйныфлар бер-беренә механик рәвештә генә алмаштырмый, үз калдыкларын, йогынтыларын көрәш

[1] Биклэтәләр – ятлаталар.
[2] Шәраиты – шартлары.

йә килешү юлларында соңгыларына да тапшырып барганнары кебек, хәзерге әдәби сөйләштә дә элекке дәвернең калдыклары очраштыргалый. Мәсәлән, «һ, ф» авазлары татарчага гарәп, фарсы телләре тәэсире астында килеп кергәннәр. Ләкин бу авазлар гарәпчәдән, фарсычадан һәм башка телләрдән кереп, телдә урнашкан бик күп сүзләрдә очрап, татарчадагы башка авазлар белән җиңел алмаштырыла алмаганга, алар Октябрьдән соң да, гарәпчәдән кергән башка хәрефләр белән бергә, әдәби телдән, язудан чыгып ташланмаганнар. Шулай ук «галәм, гарәп, табигый, карар» кебек гарәпчәдән кергән, шуларга ияртеп, татарча «карындаш, багрым»нан шул ук дәвердә ясалган «карендәш (кардәш), бәгърем» кебек сүзләр дә татарчадагы аваз төзелешенә туры килмәсәләр дә, анахронизм уларак, башка кайбер гарәп, фарсы, сүзләре белән бергә әдәби телдә, сөйләштә дә урнашып калганнар. Октябрьдән соңгы дәвер, тарих күзлеге белән караганда, бик кыска бер дәвер булуына карамастан, ул телнең аваз ягында буржуа дәвереннән калган гарәпчелекләрне чистарту белән генә калмады, безнең әдәби сөйләшкә, халыкара сүзләрдә нык таралган фонемнарны (авазларны) да кертеп өлгерде. Шулай ук бу дәвер бездә халыкара сүзләрнең җиңел урнашуына, дөрес сөйләнүенә, язылуына комачау булып килгән сингармонизмчылык тенденциясен дә җимерде.

Төрекчелек һәм милли шовинизм йогынтысы астындагы сингармонизмчылык татарчада сүзләр йә калын авазлардан гына, йә нечкә авазлардан гына торырга тиеш, чит телләрдән кергән халыкара сүзләрдә безнең телгә шул күзлектән карап алынырга тиеш дип бара, һәм шул юл белән халыкара сүзләрнең безнең телгә кереп, интернациональлек сызыгында баетуына матавыч[1] язарга маташа иде. Татар теле фонетикасын тикшерүдә без пролетариат диктатурасы шартларында, бер яктан, динчелек, туранчылык, шивәчелек һәм җирле милләтчелеккә каршы, икенче яктан, великодержав шовинизмга каршы көрәш белән формалашкан, һәм халыкарачылыкка юнәлеш юлы белән барган хәзерге татар әдәби сөйләшен нигез итеп алабыз.

Сәяси, иҗтимагый моментлар һәм аларны тудырган җитештерү көчләренең һәм мөнәсәбәтләренең, экономика базасының үзгәреп

---

[1] Матавыч – буталчык.

торуы белән әдәби тел үзгәреп торганы кебек, әдәби сөйләш тә үзгәреп тора.

Без моның кайбер мисалларын югарыда әдәби сөйләш турында сөйләгәндә күреп үттек. Төрле телләрдә сөйләшүче халыкларның икътисади, иҗтимагый һәм мәдәни мөнәсәбәттә булуы, шул мөнәсәбәтләрдә аваз материалы белән бирелгән сүзләренең телләрнең бер-беренә катнашуы, «скрещениесе» әдәби телнең тарихи үзгәрүендә иң зур урынны тота. «Чит» телләрдән кергән аваз элементлары, алынган сүзләр, формалар белән бергә телдә «үзләшәләр», телдә электән килгән авазлар белән очрашып, аларның табигатенә тәэсир итәләр, үзгәртәләр. Читтән алынган авазлар үзләре дә, кайбер шартларда төрле дәрәҗәдә үзгәреп, шул телдәге авазларга ярашалар. Тарих агышында әдәби сөйләш белән аерым шивә сөйләшләренең дә мөнәсәбәте бер хәлдә генә калмый. Икътисади, мәдәни, сәяси үзәкләр, «кыйблалар», хакимияттәге сыйныфлар, гомумән, икътисади-иҗтимагый факторлар үзгәрү белән тәэсир итә торган, катнаша торган «чит» телләр дә бер-берен алыштыра. Шуңа күрә, турыдан-туры йә башка халыклар васитачылыгы белән, башка телләр кебек, татар әдәби һәм шивә сөйләшләре ничә мең еллар буенча бик күп телләр белән катнашып, үзгәреп килгән. Хәзер дә бу хәл дәвам итә. Шуңа күрә телнең аваз ягында да «читлек», «үзлек» төшенчәләрен шартлы һәм нисби рәвештә генә кулланырга мөмкин.

Коллективның тарихи тормышында, аңлашу практикасында әдәби тел һәм сөйләш, башка телләр тәэсире астында гына түгел, үз эчендә дә һәммә якларыннан үзгәреп тора. Без яшәгән дәвердә дә телдәге авазларның бер-беренә күчүләре бара. Бик күп гаиләләрдә картрак буыннарның *«акрын, ач, ачлык, аз-маз, ачы, ачкыч, яшь, арчыдым, килә алмадым (килалмадым)»* һ.б. рәвешендә, яшьрәк буыннарның шул ук сүзләре *«әкрен, әч, әчлек, әз-мәз, әче, әчкеч, яшь, әрчедем, киләлмәдем»* рәвешендә сөйләүләрен соңгыларның, яшь буынның үсүе белән бөтен коллектив өчен уртакка, әдәби сөйләшкә дә әйләнә баруын күрәбез, *«ашамыйлар, карамыйлар»* кебек формалар да *«ашамилар, карамилар»* рәвешендәрәк сөйләнүгә таба баралар.

*«Барган иде, барган идек, килгән идек»* һәм башкаларның хәзерге әдәби сөйләштә *«барганыйы, барганыйык, килгәнийек»*кә әйләнүләре, *«бара алмадым, килә алмадым, килә алмыйм»* кебек тезмәләрнең *«баралмадым, киләлмәдем, киләлмим»* рәвешендә бер сүзгә әйләнеп

сөйләнгәли башлавы, телнең бу формаларда аваз ягы үзгәрүгә таба баруын күрсәтү белән бергә, *«иде, идек, алмадым, алмыйм»* кебек аерым сүзләрдән аларның аваз ягы үзгәреп, төрләнеп, *«ыйы-ийе, ыйык-ийек, алмадым-әлмәдем, алмыйм-әлмим»* кебек кушымчалар ясалуын күрсәтәләр. Телнең тарихын тикшергәндә *«язгы, җәйге, эчке, тышкы, алган, тапкан, биргән, үткән»* сүзләрдә кушымча башындагы *«гъ, къ, г, к»*ләр һәм бу бөтен кушымчалары бер авазның, бер сүзнең аваз ягыннан үзгәрүе, төрләнүе нәтиҗәсендә мәйданга килгәннәр. *«Ак ат, күп иде, кирәк иде»* кебек сүзләрнең *«агат, күбийе, кирәгийе»* рәвешендә сөйләве *«агара, күгәрә, агыза, ага, күбрәк»* кебек сүзләрнең дә *«ак, күп, күк»* тамырларыннан *«къ, к, п»* берлән *«гъ, г, б»* авазларына үзгәреше белән ясалганнарын күрсәтәләр.

*«Сигез, тугыз, егерме, мәче, дүрт, бишле, бүген»* сүзләренең дә *«сикез, тукыз, екерме, мачы, түрт, бу ел, бу көн»* сүзләреннән үзгәртелгән булулары, *«елады, туды, куды»* сүзләренең *«еглады, тугыз, кугды»*дан кыскартылган булулары, *«баглау, бәйләү, биләү»* һ.б.ларның бер үк тамырдан үзгәртелеп ясалулары, боларның да тел коллективының икътисади, иҗтимагый үсешендә төрләнүләре – телдәге төрле сүзләрне, формаларны, искедән калма язылмаларны, төрле шивә, сөйләшләрне чагыштырып тикшергәндә ачык күренә, шул ук сүзләрнең «тамырларының» башка телләрдә нинди формада сакланып калуларын тикшерү белән дә беркетелә. Монда китерелгән үзгәрү, төрләнүләренең дә кайберләре телләр, шивәләр катнашу белән ачыкланса, бик күбесе катлаулана барган икътисади, иҗтимагый тормыш кысрыклавы аркасында сүзләрне, формаларны күбәйтү өчен, аларның аваз якларын да төрләндерү мәҗбүрияте белән һәм коллектив әгъзаларының, димәк, бөтен тел коллективының сөйләү техникасы уңайлыкка бару кебек моментлар белән билгеләнә. Телләрнең катнашу процессы, икътисади, иҗтимагый, сәяси тормышның катлауланувы төрле тарихи дәверләрдә төрле темп белән барганга, шуларга карата телнең аваз ягы үзгәрү дә төрле темалар, эволюция һәм революция юллары белән бара.

Димәк, тел аркылы аңда чагылган объектив барлыкның, җитештерү көчләре һәм мөнәсәбәтләренең, хакимияттәге сыйныфларның төрле халыклар арасындагы бәйләнешләрнең һәм, гомумән, бөтен җәмгыять тормышының туктаусыз үзгәреп торуы аркасында әдәби сөйләштә акрынлык – эволюция һәм нисби тизлек-революция,

сикереш юллары белән үзгәреп тора. Шуның белән бергә, тел коллективы, хәтта төрле телләр өчен уртаклык, коллектив әгъзаларының буыннан-буынга күчеп килгән озаклы күнегүләре аркасында, телдә кулланыла торган авазлар, аларның төрләнеш кануннары һәм, гомумән, әдәби сөйләш һәр кыска дәвер өчен нисби стабильлек (нисби үзгәрешсезлек) хәлендә кала.

Бүгенге практик файдалану (уку-язу тану, таныту, орфография, орфоэпия, грамматика, тасвирлы уку, чит телләр өйрәнү һ.б.) өчен телнең шул дәвердәге нисби стабиль нормалары әһәмиятле булганга, җентекләүдә, бигрәк тә фонетикадагы башлангыч тикшерүләрдә әдәби сөйләшнең нисби стабиль (статика) моментларына төп әһәмият бирелә. Шуның белән бергә киләчәккә юллар сызу, телгә актив тәэсир күрсәтү, хәзерге практик мәсьәләләрне дә планлы рәвештә хәл итү өчен, тел һәм сөйләшнең тарихи үзгәреш якларына бигрәк тә фәнни тикшерүләрдә ныклы әһәмият бирергә кирәк. Фонетиканың аерым мәсьәләләренә күчүдән элек, авазның гомуми үзлекләрен искә төшереп үтик.

Без физикадан аваз бирәр җисемнең тибрәнүе нәтиҗәсендә һава кисәкчәләренең дә хәрәкәткә килүеннән һәм шул һава тибрәнүләренең колак аркылы мигә тапшырылуыннан гыйбарәт икәнен беләбез. Берничә бердәй тибрәнмәләрдән торган авазны тон дип атыйлар. Хәрәкәтләнгән җисемнең, димәк, һаваның да тибрәнүләре ешрак (һәр секундта тибрәнмәләр саны күбрәк) булган саен, без күтәренкерәк (нечкәрәк) тоннар, тибрәнүләр сирәгәйгән саен, төшенкерәк (калынрак) тоннарны хасил итәбез. Авазларның күтәренкелеге, төшенкелеге дәрәҗәсе тонның биеклеге дип атала. Авазның көче төрлечә булырга мөмкин: тибрәнү дулкыннары тирәнрәк (амплитудалары зуррак) булган саен, көчлерәк (куәтлерәк) авазлар хасил була, амплитудалар кечерәйсә, аваз да көчсезләнә, акрыная. Төп тибрәнүләргә өстәмә тибрәнүләр кушылганда аваз беркадәр үзгәреп ишетелә. Моны авазга тембр тоннары кушылу диләр. Берүк рәвештәге аваз дулкыннары, тон билгеле бервакыт дәвам итүе мөмкин. Бу моментның озынлыгы авазның сузылышы дип атала. Беркадәр сузылышы булган, биеклеге колак белән билгеләнә алган һәм, музыка кораллары авазы кебек, әйләнмәле (периодик) тибрәнүләрдән торган авазларны музыкаль тон дип атыйлар. Шартлау, бәрелү, пышылдау авазлары кебек биеклеген колак билгели алмаган, әй-

ләнмәле тибрәнүләрдән тормаган авазларны шавылдаулы авазлар, шавылдаулар (шумнар) дип атыйлар. Һәр мохитта (мәсәлән, һавада, суда һ.б.) аваз дулкыннары, авазның биеклегенә, көченә, шавылдаулы йә музыкаль булуына карамастан, шул мохит өчен уртак һәм үзгәрешсез булган бер тизлек белән, туры сызыклар буенча һәммә якларда тигез, концентрик (үзәктәш) рәвештә таралалар[1].

Авазның югарыда күрсәтелгән гомуми үзлекләре һәммәсе дә сөйләү авазларына да карыйлар. Без сөйләгәндә биеклек, көч, тембр, сузылыш, музыкаль һәм шавылдаулы булу якларыннан бик күптөрле, һәм сөйләү процессында чиксез зур тизлек белән туктаусыз үзгәреп, төрләнеп тора торган авазлар һәм аларның комплекслары белән файдаланабыз. Тел коллетивында тумыштан диярлек башланып, гомер буена дәвам иткән көндәлек аңлашу практикасы аркасында, без бу аваз төрләнүләрен иң нечкәләренә кадәр бер-береннән аерырга, аларны сөйләү һәм тоннан да кануни формада кулланырга һәм шундый аваз рәвеше белән бирелгән шартлы билге аркылы чиксез күптөрле фикер, мәгънә, тойгы һәм боларның аерым төсмерләрен аңларга, аңлатырга өйрәнәбез һәм өйрәнгәнбез.

Телдә авазларның төрләнүләре һәм алардан тел коллективында ничек файдалану телнең аваз ягын тикшерүдә бик зур урын тотканга һәм бу мәсьәләләр бездә генә түгел, русларның һәм башкаларның да тел турындагы матбугатында гадәттә җитәрлек ачылмый киткәндә, без монда аларга киңрәк тукталабыз.

Авазларның биеклек ягыннан төрләнүләреннән башлыйк. Безнең колагыбыз бер секунтта 16 тибрәнүдән башлап 20 000 тибрәнүләргә чаклы авазларны ишетә ала[2]. Тибрәнү саны бер-береннән беркадәр аерылганнарын чагыштырып, биеклек ягыннан да аера ала. Колак боларның барын да ишетсә дә, кешенең сөйләү органнары боларның барын да мәйданга китерә алмаганда, бер сөйләшкән вакытта, гадәттә, бу тоннарның бөтенесе белән файдаланмыйбыз, бары секундка 150 белән 4000 арасындагы тибрәнүле тоннар белән генә

[1] Аваз дулкыннары 0 температуралы һавада һәр секунтта 332 метр чамасы тизлек белән таралалар. Суда аваз тизлеге – 1435 метр, чуенда – 3500 метр чамасы. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Кайбер тәҗрибәләр буенча, колак секундка 40 000 тибрәнүгә чаклы авазларны ишетә. Моннан азрак тибрәнүләр һәм 16 дан ким тибрәнүләрне колак ишетә алмый. *(Г. Шәрәф иск.)*

файдаланабыз. Ләкин бу ике арада да бик күптөрле биеклектәге тоннар урнаша. Моның өстенә без сөйләгәндә бер вакытта да бер генә төрле тибрәнүдән торган гади тоннар белән файдаланмыйбыз, һәрбер вакытта да бик күптөрле өстәмә тембр тоннары кушылган катлаулы тоннар белән файдаланабыз. Һәрбер төп тоннан, өстәмә тоннары төрле була алганда, файдаланырга мөмкин булган катлаулы тоннар санап бетергесез күп санга җитә.

Без сөйләгәндә катлаулы музыкаль тоннар белән генә файдаланмыйбыз, аларда һәрбер вакытта төрле шавылдаулар да өстәлә. Сөйләү аппараты мәйданга китерә ала торган шавылдаулар шактый күп булып, алар музыкаль тоннарның төрлесе белән кушыла. Шуның белән тагы да чиксез күп яңа төрләр бирә алалар. Без шавылдауларны, музыкаль тоннардан башка, үзләрен генә дә ишетәбез. Телдә файдаланыла торган тавышлар, шулай ук пышылдап сөйләү бөтенләйгә шавылдаулардан гына тора. Димәк, шавылдаулар үзләре генә дә авазларны төрләндерүдә зур урын тоталар.

Югарыда сөйләгәннәр өстенә, бу төрләнгән авазларның һәркайсын диярлек без көч ягыннан, сузылыш ягыннан тагын да бик күп формада төрләндерә алабыз.

Боларның барын бергә алганда һичбер төрле санап бетергесез күп аваз төрләре мәйданга килә. Безнең күзләребез – төсе йә формасы белән бик үк аерылган нәрсәләрне дә береннән аерган кебек колак та, биеклек, тембр, көч, сузылыш, шавылдау кебек төзүче элементларының бер генә ягы белән беркадәр аерылган авазларны да бер-бере белән бутамауны булдыра[1]. Шуңа күрә югарыда күрсәтелгән аваз төрләреннән сөйләү органнары мәйданга китерә ала торганнарын бөтенесен, гомумән алганда, без сөйләү, тыңлау процессында да файдалана беләбез.

Берәү килеп ишек какса, «кем» дип сораганда, «мин» йә «ач» дип җавап биргәннең үк (төрле кешеләрнең сөйләвендә аваз элементлары төрлечәрәк җыелганга), бер таныш кешене 1/2 секундтан да кимрәк дәвам иткән тавышыннан кем икәнен танып алабыз.

Ишек кагучының кыска җавабындагы аваз элементларын икегә бүлеп карарга мөмкин: боларның кайберләре – сөйләүченең әйтү органнары төзелешендәге шәхси үзлекләреннән килгән индивидуаль

[1] Колак белән күзнең абсолют сизгерлеге бердәй булу турында Ч.Х. /…/ *(чыганакта күпнокталар куелган. – Ф.Г. иск.)* дигән әсәрләрне кара.

элементлар[1], калганнары – бөтен тел коллективы өчен уртак нормалы аңлашу билгеләре булган норматив элементлар, соңгылар «мин», «ач» дигәндәге «м, и, н, а, ч» авазларын тудырган, аларның тәртиптәге комплексыннан аерым мәгънә һәм эмоцияләр аңлаткан «ач», «мин» сүзләрен мәйданга китерүгә хезмәт итәләр. Болар бер ишек кагучы өчен тел индивидуаль түгел, тел коллективы өчен уртак.

«Ач» дигән сүзне бер татарчада *тук* һәм *яп* сүзләренең киресе итеп, сыйфат һәм фигыль мәгънәләрендә кулланабыз. Ике кулланышта бу сүзләрне ике төрле интонация белән әйтәләр. Бер үк «открой» мәгънәсендәге «ач» сүзләрен дә, бер гади, ачулы, коры, үтенү, сорау, назланып әйтүне һ.б. аңлатырга теләгәндә, төрле интонацияләр белән әйтәбез. «Тук»ның киресе булган «ач»ны да «ач кеше» дигәндә бер интонация белән әйтсәк, «буржуа дөньясында ач-ялангач, эшсез калулар» дигән җөмләдә икенче төрле итеп, сыйфатларны санау һәм аларның аерым-аерымнарына әһәмият бирдерергә теләү интонацияләрен катнаштырып әйтәбез. Боларның һәммәсендә дә «ач» сүзендә бер үк «ач» авазлары кала. Ләкин алар кушу, үтенү, сорау һ.б. алып төрләнәләр. Монда аерым эмоцияләрне бирү өчен кулланылган ике интонация элементлары бер «ач» сүзенә генә дә, ишек кагучыга гына да хас түгел. Алар бөтен тел коллективы тарафыннан башка сүзләрне дә кулланалар. Бер телдә сөйләшүчеләр боларны, үзләре дә искәрмәстән, морфология, синтаксис кагыйдәләрне дөрес кулланган кебек кулланалар[2]. Шуның аркасында гына бер сүз, җөмләләрдән аларның лөгать, морфология, синтаксис буенча биргән мәгънәләрен генә түгел, интонация биргән мәгънә төсмерләрен дә аңлыйбыз. Соңгыларда да сыйнфый эмоция һәм

[1] Монда индивидуаль элементларның төп вазифасы тыңлаучыларга сөйләүченең кем икәнен күрсәтүгә, димәк коллективның аерым әгъзасын аңлашу процессында коллективка бәйләүдә. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Мондый интонация элементлары сүзләргә караганда халыкара уртаграк булганда, без кайвакытта чит телдә сөйләүченең сүзләрен аңламасак та, интонациясен аңлыйбыз. Кеше белән катнашып яши торган эт, мәче кебек йорт хайваннарының да гадиерәк интонацияләрне «аңлаулары», башка хайваннар бер-беренә аз-маз аңлатасы әйберләрендә интонация үзгәртү белән файдаланулары билгеле. Шуңа күрә, хәлнең башлангыч дәверендә зур роль уйнаган кул (хәрәкәт), тел телсез саңгыраулардагыча кинетика нигезенә генә карамый. Аваз-интонация үзгәртүләр белән янәшә барган булырга тиеш. Интонация төрләндерү (модуляцияләрне), инглиз куйганча, аермалы аваз теленең хайванчылык дәвереннән үк башланган хезмәт, җәмгыять белән үскән алдынгы дип карарга кирәк. *(Г. Шәрәф иск.)*

сыйнфый аң чагыла. Икенчедән, «ач, ача, ачалар, ачмагың, ачмасыннар, ач ат, ат ашата» сүзләрендә басымлы йә басымсыз иҗекләрдә, сүзнең, иҗекнең башында, уртасында йә актыгында, ачык иҗек йә ябык иҗек килү, нинди авазлар белән күрше булуына карап, бер үк «а» авазы сузылыш, көч һәм, гомумән, әйтелү, ишетелүякларыннан үзгәрә, төрле вариантлар ала. Башка сузык һәм тартык авазларда да шундый төрләнү бар. Мондый вариантларга да сөйләүче индивидуаль элементларын да кертүенә карамастан, аларда иҗекләр төзелеше, басым кагыйдәләре, сөйләшнең ритм ягы турында тел коллективындагы нормалар, билгеле кагыйдәләр эчендә нисби даимилек саклау нигезендә сөйләү техникасын конкрет күнегүләр буенча куллана алуыбызга безгә авазлардан иҗекләр, алардан сүзләр, тезмәләр һәм җөмләләр ясау, алардан коммуникация, аңлашуда файдаланырга мөмкинлек бирә. Бу вариантлар эластик булып, аерым авазларның абсолют көч сузылышларыннан да бигрәк, нисби көч сузылышлары безнең аңлашуыбыздан зур роль уйный.

Шулай итеп, бер үк *а* авазы (йә башка аваз) тон, көч, сузылыш һәм шавылдау элементларын төрләндереп, безнең практик аңлашуыбызда роль уйнаган бик күп норматив һәм индивидуаль вариантлар бирә. Без шулар белән аңлашу практикасында файдаланабыз. Һәммәсе өчен уртак булган кайбер әһәмиятле аваз элементлары да саклану аркасында, бу вариантлар безнең практикабызда, димәк, аңыбызда да, уртак ассоциация дә саклыйлар. Шулар аркасында *а* йә башка аваз, телдә бик күп норматив һәм индивидуаль вариантлары булган, мәгънәле сүзләр тезүгә хезмәт иткән бер аваз тибы – фонем булып урнаша. Вариантларда уртак элементның булуы, бергәләп безнең аңыбызда бер тип булып танылуыбыз боларның (вариантларның) гадәттә язуда бер үк хәреф (графем)[1] белән бирелүеннән дә күренә.

Димәк, фонем дип, үзенең вариантлары белән тел коллективында мәгънәле сүзләр тезүгә хезмәт иткән төп аваз типларын атыйбыз.

[1] Бер үк хәрефнең «А, а» типография шрифтларында, аерым кешеләрнең кульязмаларында, зурлык, сызылыш һәм башка яклардан бик күп шәкелләре булырга мөмкин. Болар һәммәсе бер авазны күрсәткәнгә, шәкелләре төрләнүгә карамастан, безнең практикабызда һәм аңыбызда уртак ассоциация белән бер хәреф тибына әйләнәләр. Сүзләр язуга хезмәт иткән шундый хәреф типлары «графем» дип атала. *(Г. Шәрәф иск.)*

Фонем – үзенең иҗекләр, сүзләр, җөмләләр төзүгә һәм төрле интонация төсмерләре бирүгә хезмәт иткән бөтен вариантлар белән җәмгыять (тел коллективы) аңнары өчен әһәмиятле булган социаль хадисә.

Фонем телдәге сүзләр. Морфология, синтаксис формалары кебек, бер үк вакытта үзендә конкретлыкны да, нисбилекне дә җыя. Югарыда җентекләнгәнчә, чиксез күптөрле норматив һәм индивидуаль вариантлар алуы белән фонем – нисби нәрсә, боларның уртак элементлары да саклану, безнең читенлексез аның бөтен вариантларын гадәттә бер үк хәреф (графем) белән бирә алуыбызга караганда, ул конкрет нәрсә – фонемның һәрбер төрләнеше, әйтелеше дә экспериментал фонетика приборлары белән язып, «татып» алынырлык, теләгәнчә җентекләнерлек конкрет материал хадисә. Телдәге фонемнарны тип уларак тикшереп чыгу һәм аларны төркемләү, фонемнарның иҗекләргә җыелуын, басым, интонацияләр һәм күрше авазлар тәэсире белән аларның төрләнү, үзгәрү кануннарын тикшерү – фонетиканың төп вазифаларыннан. Фонемнарның сүз төзелешендә вариантлашуы кайбер шартларда бик еракка китеп, ике фонем, хәтта ике төркем фонемнар арасында күпер булган күчмә авазлар язылуын бер фонемның билгеле урыннарда йә бөтен телдә икенче фонемга әйләнүен кайбер фонемнарның югалуын, алар урынына коллектив практикасында яңа фонемнар тууын һ.б. китереп чыгарганда, фонемнарны бигрәк тә аларның төрләнү шартларын, төрләнүләрен тикшерү, телнең аваз ягыннан булган тарихын тикшерү шуңа карата киләчәген билгеләүдә, аңа планны кем актив тәэсир итүдә тиешле урынын тотарга тиеш.

Без югарыда сөйләгәннәрдән, телнең башка яклары кебек аваз ягы да беренче караштa килештермәслек каршылыкларны – коллектив өчен уртаклык (нормативлык) белән аерым коллектив әгъзалар өчен хаслыкны (индивидуальлек) җыюын күрәбез. Һәр коллектив әгъзасының үзенең сөйләү органнары үзлекчәләренә һәм сыйныфларга, эш төркемнәренә бүленгән җәмгыять эчендә яшәү, көнегүнең үзлекләренә карап, тавышында, телдәге аваз кануннары белән файдалануында үзенчәлекләре була. Ләкин коллектив эчендә озак еллар буенча аңлашу практикасы бу индивидуаль аерымлыкларны коллектив өчен уртак норматив рамкаларга салып, аларны норманың аерым күренеш кенә итеп калдыра. Приматлык

(өстенлек) сөйләүнең коллектив өчен уртак норматив элементларында саклана. Социализм җәмгыятендә коллектив интереслары өстенлеге нигезендә, аерым коллектив әгъзаларының индивидуаль интереслары да үзләренә урын табып, гармонияле рәвештә берләшкәне, диалектик берлек алганы кебек, телдә дә (аерым алганда, аның аваз ягында да) норматив һәм индивидуаль элементлар гармонияле берлек тәшкил итәләр. Фонетика – субъектив һәм объектив (эксперименталь) методлар белән коллектив әгъзаларының индивидуаль сөйләшләреннән файдаланып, тел коллективы өчен уртак булган һәм төп интерес тәшкил иткән норматив аваз кануннарын ачу өстендә эшли.

Югарыда язылганнардан без түбәндәге нәтиҗәләргә киләбез: 1) телнең аваз ягы – турыдан-туры аның һәм объектив методлар белән тикшерелә алырлык материал хадисә, аны тикшерү эзлекле рәвештә материализм әсасында куелган күзәтүләр, аның экспериментлар (тәҗрибә) нигезендә булырга тиеш. Шул шартларда гына без телнең аваз ягыннан булган табигатен дөрес, анык ачу өчен кирәкле материалга таяна алабыз; 2) без монда әдәби сөйләш һәм, гомумән, телнең аваз ягы үзгәрүчәнлек белән нисби үзгәрешсезлек, социаль нормативлык белән индивидуальлек, конкретлык белән нисбилек кебек капма-каршылыкларны үзендә җыюы, фонемнарның көч, сузылыш һәм башка яклардан үзгәреп, санның сыйфатка, бер сыйфатның микъдары үзгәреп, икенче сыйфатка әйләнүе нигезендә икенче фонемга әверелүе һ.б. кебек диалектика кануннары буенча төзелешен һәм яшәвен күрдек. Димәк, аны тикшерү дорфа (тупас) материализмга гына каралмый, диалектик материализм методологиясе белән ачыкланып барганда гына дөрес, анык нәтиҗәләр бирә ала; 3) Без монда телнең аваз ягы да җәмгыять (тел коллективы) формасы белән бәйләнгән, шунда туган, үскән, яшәгән социаль хадисә икәнен, аның тарихи үзгәрешләре җәмгыять тормышындагы, тарихындагы икътисади, сәяси үзгәрешләр белән исемсез бәйләнеп, таянып баруын күрдек. Соңгы үзгәрешләр пролетариат идеологиясенә муафыйк рәвештә марксизм-ленинизм тудырган тарихи материализм нигезендә, оппортунизмга илтә торган тайпылышлар белән каты көрәш юлыннан барганда гына дөрес ачыла ала. Димәк, шуларга бәйләнгән, таянган тел һәм аның аваз ягына фонетикада шул нигезләрдә, шул юллар белән тикшерелергә тиеш.

Идеализм нигезендә килгән иске буржуа тел гыйлеме югарыда күрсәтелгән нигезләргә корылган фонетиканы бирмәгән, бирә дә алмаган. Төрле телләр өстендә әлегә чаклы җыелган факт материаллары да фонетиканы тулы рәвештә бу нигезләргә яңадан тулылап карау өчен җитәрлек түгел. Һинд-европачы телчеләренең үк телләре һәм якын телләр тирәсендәрәк кенә чуалып, буржуа дәвере дә артта калган халыкларның телләрен тикшерүгә җитәрлек әһәмият бирмәгән булуы бу турыдагы артталыкны тудырган сәбәпләрнең берсе булса, телнең аваз ягын тикшерүдә бик зур урын тоткан экспериментале фонетиканың[1] соңрак дәверләрендә генә туган фән булып, иске телчеләрнең генә түгел, хәзерге телчеләрнең дә күбесе аның белән коралланмаган булуы, шуңа күрә файдалана алмавы – бу артталыкның төп сәбәпләреннән. Телнең аваз ягы аның башка яклары белән өземсез берлек тәшкил иткәнгә, гомумән тел гыйлеменең һәм аның башка аерым тармакларының да марксизм-ленинизм нигезендә җитәрлек тикшерелмәгән булуы, Маркс, Энгельс, Сталиннарның тел турында югарыда сөйләнгәннәре дә соңгы елларда гына җыелып, ныклап өйрәнелә башлавы, фонетика мәсьәләләренең күп моментларын тикшергәндә комачаулый. Шуңар күрә монда татар теле фонетикасын тикшергәндә дә, аны һәммә якларыннан тулы ачып биреп булмый. Киләчәк тикшерүләр ачыклыкларны тутырырга, җитешсезлекләрне төзәтергә тиеш булыр.

Методологиянең югарыда тикшерелгән төп мәсьәләләре – әдәби телнең, бигрәк аның аваз һәм форма ягыннан шартлы чагылышы булган язуга да карыйлар.

Язу да – җәмгыятьтә специфик форма аңлашу ихтыяҗыннан туган, җәмгыять белән бергә икътисади, иҗтимагый, сәяси факторлар тәэсире астында үскән, яшәгән социаль хадисә.

Монда да аерым кешеләрнең кул язышларында (рәсми хат) коллектив өчен уртак социаль-норматив элементлар саклану белән бергә, индивидуаль элементлар да күп була. Социаль нормативлык белән индивидуальлек гармонияле рәвештә берлек тәшкил итә. Сөйләштә фонемның төрләнүләренә каршы, язуда, басмада графемның,

[1] Экспериментале фонетика – тел гыйлеменең сөйләгәндә хасил булган аваз дулкыннарын, сөйләү аппаратының хәрәкәтләрен төрле машина-приборлар белән һәм башка ысуллар белән беркетергә, язып алырга һәм аларны җентекләп тикшерергә мөмкинлек бирә торган ярдәмче бүлекләреннән. *(Г. Шәрәф иск.)*

бердән, *«А-а»* кебек социаль-норматив вариантлары, икенчедән, аерым кул язышлардагы индивидуаль вариантларын күрәбез. Монда да норматив элементлар өстеннән (приматлык) саклап, чиксез күп индивидуаль төрләнешләрне, системны рамкалар эчендә калдыралар. Шулар нәтиҗәсендә язуда берәү язганы һәркем диярлек аңларлык конкретлык белән чиксез күп төрләнүне эченә алган нисбилек җыела. Язу да һәр дәвердәге нисби стабильлеге белән бергә, бертуктаусыз үзгәреп торучанлыкны үзендә җыя. Аның үзгәрешендә дә орфография традиция һәм кагыйдәләре, аерым хәрефләр, кул язышлары, матбага шрифты төрләре акрынлап үзгәреп торуы кебек эволюция үзгәрешләре дә бер орфография системыннан икенчесенә, бер графемнар системыннан (бер әлифбадан) икенчесенә күчү кебек, революцион үзгәрешләр дә очрый. Тышкы караштa язу сыйныфлар өчен уртак шартлы билгеләр кебек күренсә дә, һәр дәвердәге икътисади, иҗтимагый, сәяси шартларга карата язуның төрле эволюцион һәм революцион үзгәрешләренә төрле иҗтимагый сыйныфларның карашлары төрле булып, хакимияттәге сыйныфлар һәм башка шартлар алмашыну белән бу турыдагы тенденцияләрнең дә үзгәреп баруы язуның да сыйныфлылык белән сугарылуын күрсәтә.

Язуда чагылган телнең һәм аның аваз ягының тарихи үзгәреше интернациональләшүгә таба барганда, һәм сыйныфлар көрәше, интернациональ тенденцияле пролетариат сыйныфының актык нәтиҗәдә бөтен дөньяда җиңүе белән йомгаклануга таба барганда, язуның тарихи үзгәрешләрдән дә төп тенденция интернациональләшүгә таба барудан гыйбарәт. Пролетариат хакимияте шартларында бу тенденциянең көчәюен, катгый җиңүен, бер татар һәм башка бик күп СССР халыкларының язуында Октябрь революциясеннән соң яңалиф урнашу тарихында да күрәбез. Бу турыдагы көрәшләр шул көнге вакытлы комачауларны гына күреп, перспектив уңайлыкларны һәм мәсьәләнең гомуми барышы тенденциясен хисапка ала алмаучыларның, сизеп йә сизми реакцион сыйныфларның карашын җиткерүчеләрнең өзек рәвештә җиңелүе белән тәмамлана барды.

*1930*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 20 ф., 1 тасв., 42 сакл. бер.*

*Мәкалә «Г. Шәрәф» имзасы белән 1930 елда язылган. Латин графикасында, машинкада басылган. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр дөнья күрә.*

# ЯҢА ИМЛЯ ӘСАСЛАРЫ

Яңа татар имлясы турысындагы декретлар бик кысылып, рәсми тел белән язылган һәм басылганда бик күп ялгышлар белән басылган булганга, аның кагыйдәләрен ачык һәм халык, гаммә[1] җиңел аңларлык рәвештә яңадан искә төшереп чыгуга вә кертелгән үзгәрешләрнең сәбәпләрен ачып китүгә ихтыяҗ бар.

***Революция дәверендә татар имлясы***

Иң элек артка күз салыйк. Без имля мәсьәләсендә революция башыннан бирле түбәндәге яңалыкларны кабул иттек:

1. Электә бездә йөргән һәм урнашкан дүрт мәд хәрефе[2] و , ا, ی, ه янына, революциягә кадәр матбугатка гомуми рәвештә кереп җитә алмаган ۇ хәрефен вакытлы һәм даими матбугатка керттек.

(و *– озын уау, өтерсез уау: кузак, бүкән, бул, бүл, булу, бүлү, калу, тау, тәүлек* дигәндәге кебек *тулы уау* ишетелгән урыннарда языла; ۇ *– кыска уау, өтерле уау: борын, бозау, төймә, йөрәк* кебек сүзләрдәге кыска, иреннәр ачыграк көенчә әйтелә торган авазга языла).

2. Электә *миннән, алдан, алга, килгәч, баралар, киләләр, барып, килеп, барсын, килсен, барыр, килер, русча, барса, алса* кебек сүзләр *миндн, алдн, алгә, килгач, баралр, киләлр, баруб, килүб, барсун, килсүн, барур, килүр, русчә, барсә, алсә* рәвешендә языла иделәр. Язуның тизлеге, уңайлыгы өчен бер дә файдасы булмаган, уку эшендә саташтырудан башкага бармаган бу кагыйдәләрне бетереп, югарыдагыча, ишетелгәнчә язу әсасын[3] кабул иттек; матбугатта һәм шул урнашты.

3. Гарәпчәдән, фарсычадан кергән сүзләребез дә электә гарәпчәдә ничек язылып килгән булса, шулай ук мәд хәрефләреннән башка һәм гарәп авызыннан гына ишеткәнчә чыга ала торган, тәҗвид укытмаган кеше әйтә алмый торган ث, ذ, ص, ض, ط, ظ хәрефләре белән яза идек.

Иске чыгтайча һәм татарча язылырга хилаф булса да[4] бу хәрефләрдән ظ, ط, ص татарчада кайбер сүзләргә кертелгәннәр иде.

Революция вакытында иң элек гарәпчә, фарсыча сүзләр, ишетелгәнчә мәд хәрефләре белән языла башладылар; татарча сүзләрдән

[1] Гаммә – халык массасы.
[2] Мәд хәрефе – сузык авазны белдерүче хәреф.
[3] Әсасын – нигезен, фундаментын.
[4] Хилаф булса да – каршы булса да.

ظ, ط, ص хәрефләре чыгарыла. Алар урынына калын сүзләрдә дә нечкә сүзләрдә дә س, ز, ت хәрефләре язылa башлады. Тора-бара ظ, ط, ص хәрефләре һәм ث, ذ хәрефләре гарәпчә сүзләрдән дә чыгарылып ташлап, гарәп сүзләре дә татарчада йөртелгән хәрефләр белән генә татар халык сөйләвенчә язылa башладылар.

ذ, ث, ض, ظ, ط, ص хәрефләренә ияртеп, خ, غ хәрефләре дә ташланып, татарчада да, читтән кергән сүзләрдә дә болар урынына язуы уңайрак булган ноктасыз ح, ع лар йөртелә башлады.

*4. Урак* / ئورەق *, өрәк* / ئوراق *, ыргак* / ئرعاق *, эш* / ئش кебек сүзләр элек тә اوراق / *урак,* اورە ق / *өрәк,* ارغاق / *ыргак,* اش / *эш* рәвешендә ا / *әлиф* белән язылалар иде. Әлифнең сүз уртасында ا /*әлиф* авазына йөрүе, сүз башында тулы аваз булмаган һәмзә урынына йөрүе сәбәпле, балаларга бер үк хәрефне ике төрле укырга туры килгәнлектән, укылу ягыннан уңайсызлыклары бар иде.

Без сүз башындагы һәмзәләрне ئ хәрефенә әйләндереп, әлифне *бара, аза* сүзләрендәге кебек ا авазына гына калдырырга карар бирдек һәм иң элек бу ягындагы нечкә сүзләргә кертеп, *ил, иләк, эш, үзәк, өләшү* кебек нечкә сүзләр алдындагы әлифләрне һәмзә белән язуны керттек. Аннан соң әкренләп *ыргак, урак, озак* кебек калын сүзләр алдындагы әлифне дә ئ белән алыштырдык.

Казанда имляда кертелгән үзгәрешләр бер Казанда гына калмый Эчке Русия һәм Себер вә башка җирләрдәге татар матбугатына да керә барды. Хәтта Русиянең төрле мөселман-төрек җөмһүриятләре дә безнең арттан ияրделәр. Инде югарыда 1, 2, 3 кыйсемен 4 нче рәкымнар белән күрсәтелгән үзгәрешләр бөтен Эчке Русия вә Себердәге татар матбугатына кереп җиткәннәр.

Башкортстан, Казакъстан, Төркестан җөмһүриятләрендә бу үзгәрешләр көтелгәннәр һәм аларның хәзерге гәзитәләрнең кулланган имлялары саналган үзгәрешләргә муафыйктыр.

Бохара, Хивада революция соңрак башлану һәм аларның ераграк, азрак хәзерлекле булулары аркасында аларга әле үзгәрешләрнең баштагы икесе генә барып җиткән. Бохара белән Хива әле гарәпчә сүзләрне мәдләр кертеп язуга карышмаганнар; алай да инде аларда бу мәсьәлә өстендә мөзакәрә[1] бара. Азәрбайҗан һәм Кырымда революциягә кадәр һаи рәсмия дә[2] кермәгән иде. Хәзер ул аларда ур-

[1] Мөзакәрә – фикер алышу.
[2] Һаи рәсмия дә – сүз ахырындагы «һ» хәрефе дә.

нашып бара. Алар *-лар, -ләр, -дан, -дән, -мак, -мәк, -чык, -чек* язудан алар да әкренләп бездәге кебек ишетелгәнчә язуга күчеп баралар.

Соңгы көннәрдә Азәрбайҗан гәзитәләрендәге озын-озын фельетоннар ишетелгәнчә язуны тагын тирәнәйтү мәсьәләсен күтәрәләр, аларда да гарәпчә сүзләрне истигъмальдан[1] куып, алар урынына мәхәлли[2] телдән сүзләр табарга омтылу, калган гарәпчә сүзләрне мәд хәрефләре белән һәм азәрбайҗанчага буйсындырып язу кирәклеген берничә кеше яздылар.

Бу мәкаләләр аларда да мәсьәлә өлгереп барганны һәм Казанның имля мәсьәләсендә тоткан юлы туры булып, башка Шәрык халыклары да шул юлга юнәлгәннәрен күрсәтә.

Инде имлябызның бу көннәрдә генә аңлаган адымнарын тикшереп карыйк:

***Алтынчы мәд хәрефен арттыру***

Элек тә бездә *а* / ا , *ә* / ە авазларына аерым хәрефләр, *у* / ئو , *ү* / ئو авазларына икәвенә бер, *и* / ئي , *е* / ئي авазларына икәвенә бер, *о* / ئوُ , *ө* / ئوُ авазларына икәвенә бер хәреф булса да, *кыска йай* дип аталган ئي , ئي авазлары өчен аерым бер хәреф юк иде. Бу җитешсезлек *килде, алды, китте, ачы, чәйни, килделәр, ике* кебек сүзләрнең *килде, алды, китте, ачы, чәйни, килделәр, ике* рәвешендә язылуына сәбәп була; балалар, язылганча, ялгыш итеп укыйлар, артистларыбыз да сәхнәдә кайчакта ялгыш язылганча сөйләп җибәрәләр, хәтта мәшһүр шагыйрьләребез дә: «Кәҗә әйтә: “Микикики, микикики, капчыктагы бүре башы бит унике”» дигәндәге кебек, язылганчага карап, ялгыш кафияләр[3] ясыйлар иде, тел бозылуга сәбәп була иде.

Аннан бигрәк, телдә бу (ـٔ) авазының кайбер урыннарда *барды, килде, килделәр* дигәндәге кебек ى белән язылу да кайбер урыннарда *баруб, килүб, булсун, булур, карлугач* дигәндәге кебек و белән язылуы һәм нинди урыннарда و нинди урыннарда ى белән язып, нинди урыннарда бөтенләй төшерелеп калуын аз, кыска, ачык кагыйдәләр белән күрсәтеп бирергә мөмкин түгел иде; шуның аркасында әдәби тел өчен бу төрле гомуми булган имля утыра алмавы,

[1] Истигъмальдан – кулланудан.
[2] Мәхәлли – җирле.
[3] Кафияләр – рифмалар.

(ڭ) авазлары өчен аерым бер хәреф алу ихтыяҗын тудырдылар вә бу авазлар өчен (ئ) хәрефе алынды.

(ڭ) авазы татарчада иң күп очрый торган авазлардан башка хәрефләр белән дә күрсәтелеп килмәгән. Кайбер урыннарда язылмаса да, барлыгын җиңел аңлап була. Мәсәлән: *бер, кер, кыр, сере, сыры,чыбык* кебек сүзләрнең беренче иҗегендә *бардым, килдем, бүлем, башың* кебек сүзләрнең актык иҗекләрендә (ڭ) авазы ачык ишетелсә һәм сөйләнсә дә, аны язмагач та, укырга мөмкин. Боларның барысында да язсак, (ڭ)ләр безнең язуыбызны, белгечләрнең тәфтише[1] күрсәткәнчә, 8 процент белән 10 процент арасында озынайтырга тиеш иде. Димәк, (ئ, ڭ)не һәммә урында язсак, 100 бит чыга торган китап шул ук форматта 110 бит чамасы чыгарга тиеш иде. Бу язуда да, укуда да китапны басуда да 10 процент кадәр вакытны һәм мәсарифларны[2] артыграк алуга сәбәп булачак иде. Шуңа күрә (ڭ) хәрефе һәммә ишетелгән урында да язмаска тиеш табылды.

Ләкин кайда язу, кайда язмау һәркем аңларлык җиңел ике кагыйдә белән билгеләнде: 1) (ڭ) хәрефе беренче иҗекләрдә бөтенләй язылмый *кер* /كر/, *кыр* / قر /, *бер* / بر /, *бере* /برى /, *куй* /قوى /, *белә* / بله /, *керә* / كره /, *чыга* / چغا / кебек һәм 2) (ڭ) хәрефе калган иҗекләрнең ачыкларында языла, ябыкларында язылмый[3]. (*Бер, бере, чыга, беленә, күренә, ачыграк, карыгач, тешсез, белештек, күрештеләр, күрдегез, белегез, йылылык* кебек.)

Быелгы уку елы өчен басылган һәммә мәктәп китаплары инде бу алтынчы мәд хәрефе һәм югарыда күрсәтелгән имля үзгәрешләре кертелеп басылган иде. (Сүз туры килгәндә имля белән туры мөнәсәбәте булмаса да, шуны да әйтеп китәргә кирәк, быел яз, җәй, көз буенча ашыгып-ашыгып төрле коллективлар тарафыннан эш мәктәпләре әсасына эшләнгән йөзәр, икешәр йөз мең басылган әлифба, кыйраәт, хисап, табигать китаплары вә башка дәреслекләр инде кыш уртасы җитсә дә, һаман хөкүмәт нәшрият складларында

[1] Тәфтише – тикшеренүе.

[2] Мәсарифларны – чыгымнарны.

[3] Ачык иҗек дип мәд хәрефе белән тәмам булган иҗеккә (слухка) әйтәләр; ябык иҗек дип мәдсез аваз белән тәмам булган иҗеккә әйтәләр: *бара, кала, килә, керә, төшә* сүзләре икешәр ачык иҗекле; *киңәшә, керешә, белешә, бәрелә, килере* сүзләре – өчәр ачык иҗекле сүзләр; *чыпчык, керсен, алсын, бирсен, кайнап, шаулап, аршынлап, керсеннәр* сүзләре – һәммә иҗекләре дә ябык иҗекләр булган сүзләр. *(Г. Шәрәф иск.)*

яталар; нә татар җөмһүрияте кантоннарына, нә татар торган башка губерналарга җибәрелгәннәре юк; шулай итеп, мәктәпләрдәге ачлык, кәгазь, карасызлык, мөгаллим хәзерсезлек өстенә, әз генә энергия белән дә төзәлергә мөмкин булган китапсызлык авыруы да арта. Мәгариф, мәдәният якларыннан артта калган татар халкының мәгариф, мәдәниятләрен күтәрү өчен төзелгән татар җөмһүрияте һәм аның бу эшне карарга куелган мөәссәсәләре[1] кайчан бу мәсьәләләргә җитәрлек әһәмият бирә башларлар икән?).

***Калынлык тамгасы***

Татарча сүзләр, йә *кул, бала, була, тал, булды* сүзләре кебек калын авазлардан гына, йә *көлә, бәлеш, бил, бер, бүләк, тиле, бүлде* сүзләре кебек нечкә авазлардан гына төзелгән була.

Бездә элеккедән төрле имлячыларыбыз тарафыннан калын сүзләрне нечкә сүзләрдән аерыр өчен ике юлның берсе тәкъдим ителеп килә:

Беренче юл – һәммә мәд хәрефләрен калынга берне, нечкәгә берне алып, барысы 10 мәд хәрефе итәргә; калын сүзләрдә калын мәд хәрефләрен йөртеп, мәдсез хәрефләрнең калынлыгын, нечкәлеген алар янындагы мәд хәрефләре күрсәтә; бөтен сүзнең калынлык-нечкәлеге дә шул мәд хәрефләреннән карап беленә.

Икенче юл – мәдсез хәрефләрне дә, мәдле хәрефләрне дә берәрне генә алып, бөтен сүзнең алдында аның калынлык-нечкәлеген күрсәтә торган бер галәмәт(тамга) куярга.

Беренче юлның тарафдарлары белән барганда, безгә югарыда күрсәтелгән 6 мәд ا, ه, و, ى, ۇ, ـٔ янына тагы 4 мәд хәрефе, و, ى ләрне *мәдсез уау* белән *йай*ларга калдырганда, яңадан тагын 6 мәд хәрефе арттырырга туры киләчәк иде.

Икенче юл белән барганда, кабул ителгән алты мәд хәрефе белән калып, калын сүзләрне нечкәләреннән аерыр өчен бары бер калынлык тамгасы алырга туры киләчәк иде.

Һәрбер яңа мәд хәрефенең хәятка нинди авырлык белән керүен, һәр арткан хәрефнең матбага, хәреф кую якларыннан ясаган җайсызлыкларын һәм сүзләрнең калынлык, нечкәлекләрен күрсәтүне мәд хәрефләренә йөкләтеп, аларны әсас итеп алуның фәнни яктан тууы булмавын һәм татар теленең иң күзгә бәрелә торган аерымлы-

[1] Мөәссәсәләре – оешмалары.

гы булган аһәң канунының беренче тәкъдимне алганда тиешенчә истифадә ителмәвен[1] вә барыннан бигрәк катылык тамгасы керү белән яңадан 6 мәд хәрефе арттырырга һичбер төрле гамәли ихтыяҗ калмавы хәтергә алынып, югарыда күрсәтелгән юллардан татар имлясын юлга салуда икенче юл кабул ителде. Калынлык тамгасы итеп кечкенә әлиф (каимә) галәмәте алынды һәм аны сүзнең алдында түбәнгә куярга карар бирелде. Татарчада ق , ع, ا хәрефләре гадәттә калын сүзләрдә генә очрыйлар; аларның бер сүздә булуы сүзнең калынлыгын күрсәтергә җитә. Шуңа күрә бу өч хәрефтән берсе булган сүзләрнең алдында калынлык тамгасы куелмый. (*Була, булдык, булды, тулы, тула, мылтык, югы, булмый, зур* кебек.)

**ۇ / *кыска уау* мәсьәләсе**

Татарчада вә башка кайбер төрек телләрендә ۇ / *кыска уау* авазының бер хасияте бар: бу аваз үзеннән соң килгән (ىٔ) авазын ۇ / *о,* ۇ / *ө* гә якын итеп сөйләтә; бу тәэсир ۇ / *о,* ۇ / *ө* артыннан ук килгән иҗектә бик куәтле, аннан соң иҗекләр арткан саен кими бара. *Кот, котым, котыбыз, котыбызны, комсызлыгыгызны* сүзләре *кот, котом,котобоз, котобозно, комсозлогогозно* кебегрәк сөйләнә. Шул тәэсирне язуда күрсәтү, күрсәтмәү мәсьәләсе дә татар имлясының низаглы мәсьәләләреннән иде. Күрше халыклардан кыргызлар бу мәсьәләдә беренче (тәэсир күрсәтелми торган) имляны, керәшеннәр икенче *котобозно* кебек имляны алганнар. Бу тәэсир һәммә иҗекләрдә бертигез булмавы һәм аны күрсәтү сарыф «грамматика» мәсьәләләренә зур чубалчыклар кертүе һәм бездә әлегә чаклы булган гадәткә муафыйграк булуы татар имлясында тәэсирнең ялгауларда күрсәтелмәвен әсас итеп алуга мәҗбүр итте.

Аннан соң *бөтен* сүзе *бөтәйтү, төтен* сүзе *төтәгән*, *озын* сүзе *озак*, *үзәк* сүзе *өзә*, *болыт, болын* сүзләре *бөлә* сүзе белән бу төпләрдән булуы, сүзнең никадәресе ялгау, никадәресе сүзнең төбе икәнен аеру бик читен икәнен күрсәтә. Шуңа күрә бу ۇ турысындагы кагыйдәне, ۇ ның тәэсире ялгауларда күрсәтелмәс дию урынына, ۇ хәрефе беренче иҗекләрдә генә язылыр; башка аның артыннан килгән иҗекләрдә дә ۇ га ошаган авазлар ишетелсә дә, ул урыннарда (ىٔ) ишетелгән кебек итеп каралып, ачык иҗекләр дә (ىٔ) язылыр,

[1] Истифадә ителмәвен – кулланылмавын.

ябык иҗекләрдә мәд хәрефе язылмас, дигән рәвештә кагыйдәгә салу, тагын муафыйграк табылды.

Яңа татар имлясының әсасы мәсьәләләре шуның белән тәмам була, боларны мәктәп вә гамәлият өчен уңайлы кагыйдәләр рәвешенә китерү һәм тәфсыйлатны күрсәтү киләчәк мәкаләгә кала.

*Мәкалә «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1921 елгы 27 декабрь санында «Галимҗан Шәрәф» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр басыла.*

## УФАДА ЯҢА ТАТАР ИМЛЯСЫ

«Белем» журналының март аенда чыккан 2–3 саннарында Уфада шәһәр укытучыларының, җыелып, бер комиссия сайлап, тагын җыелып, татар имлясын үзгәртү турында карарлар чыгаруы турында белдерелә һәм чыгарган карарлары игълан ителә. «Белем» журналы татар телендә язылган кайбер мәкаләләрендә бу карарларның кайберләрен гамәлгә куя башлаган. Карарлар «Татар имлясындагы истисналарны бетерү» дип аталса да, монда сүз истисналар (кагыйдәгә буйсындырылмый торган моментлар) турында түгел, бәлки хәзерге урнашкан татар имлясы әсасын[1] үзгәртү турында бара. Бу карарлар 11 пункттан гыйбарәт булып, алар түбәндәге мәсьәләләргә кайтып калалар:

1) татар имлясындагы хәзерге 6 мәд хәрефе урынына 10 мәд хәрефе алырга;

2) *ватык, тау, ярлы, ай* кебек сүзләрдәге мәдсез و /*уау,* ی / *йай* хәрефләренә мәдле و /*уау,* ی /*йай* ларныкына башка булган тагын аерым ике галәмәт арттырырга;

3) *ат, аш, әкрен, ут, урак, өч* кебек сүзләрдә сүз башындагы һәмзәне ташларга, бу сүзләр боларча *«ат, аш, әкрен, ут, урак, өч»* рәвешендә язылырга тиеш була.

4) ـنـ / *е* авазын һәммә ишетелгән урынында, ябык иҗекләрдә дә калдырмыйча язарга: *телсез, белемсез бер кеше* дигән сүзләр боларча *телсез, белемсез бер кеше* рәвешендә язылырга тиеш.

---

[1] Әсасын – нигезен.

5) ۈ / *о, ө* хәрефе төп сүзләрдә һәммә ишетелгән урынында язылырга: *төлке, сөлге, солы, кое* рәвешендә язылырга тиеш.

6) *гъ* белән *г* , *къ* белән *к* хәрефләрен бер үк авазның калын һәм нечкә әйтелешләрен генә күрсәтә торган галәмәтләр итеп карап, боларның һәр парына берәр генә хәреф калдырырга. Димәк, *калган, килгән* сүзләрен, имляда йә *къ* белән *гъ* ны гына калдырып, *калган, килгән* рәвештә язарга, йә *к* белән *г* генә калдырып, *калган, килгән* рәвешендә язылырга тиеш була.

7) татар имлясында *күп кабып, аштан кайтты, шомны әдәмнәр* диебрәк сөйләнгән сүзләр, сарыф берлеге әсасыннан һәм уку өчен җиңеллек ягыннан чыгып, *күб кабыб, ашдан кайтды, шомлы әдәмләр* рәвешендә язылалар;

Бу карарларда соңгы рәвештә язылуны «истисна кертү»[1] дип карап, моның урынына «ишетелгәнчә»: *күп кабып, аштан кайтты, шомны адәмнәр* дип язарга, шулай өйрәтергә карар бирелгән.

Бердән, бу карарлар «Сәнәк» журналында басылмый, Башкортстан Мәгариф халык комиссариатының җитди рәсми журналы «Белем»дә басылганга һәм кайбер пунктлары гамәлгә дә куела башлаганга, икенчедән, шундый ук тәкъдимнәрне тулы рәвештә йә бүлгәләп, әледән әле күтәреп торучылар Казан имлячылары арасында да булганга, башка Шәрык җөмһүриятләрендә дә төрле имля агымнары арасында чарпышулар барганга, без бу карарларны кыска-кыска, җитди рәвештә тикшереп чыгабыз.

***Ун мәд хәрефе мәсьәләсе***

Ун мәд мәсьәләсе – бездә Каюм Насыйридан башланып, 15–20 еллар тикшерү, аңлашулардан һәм кайбер адымнардан соң архивка тапшырылган мәсьәлә. «Алтымы? Унмы?» мәсьәләсе – гамәли уңайлык ягыннан карап хәл ителгән мәсьәлә. Татар теленең төзелешен, гамәли уку агымы кануннарын хәтергә алганда, хәзерге имля буенча туры язганда, татарча сүзләрне анык һәм бертөрле генә язар өчен дә, укыр өчен дә алты мәд хәрефе кирәк һәм җитә. Шуңа күрә, татар матбугаты моны кабул иткән, Татарстан хөкүмәте шуны декретлаштырган. Чит телләрдән кергән һәммә сүзләрне төп, шул телдә язылганча йә сөйләнгәнчә тәҗвиденә туры китереп язу өчен исә 12 мәд тә, 15 мәд тә җитми. Хәрефләрне, имляны аерым сүзләре

[1] Истисна кертү – чыгарма ясау.

әҗәткә алынган һәммә телләргә туры китереп бетерү һичбер тел өчен мәҗбүри түгел. Бик күп татар сүзләрен, татар авазларын урыс, немец, француз, гарәп йә башка бер телнең гамәли имлясы һәм аның хәрефләре белән аерым галәмәтләр арттырмыйча язарга мөмкин булмау, ул телләр, ул имлялар өчен кимчелек булмаган шикелле, урыс, гарәп, фарсы, немец сүзләрен тәҗвидләрен[1] саклап, татар имлясы белән язып булмау татар имлясында гаеп түгел. Ун мәд кирәк, дигән карарны нигезләү өчен китерелгән «Татар сарыфларының калын йә нечкә укылулары сузынкы (мәд) авазларына гына карап йөрми», дигән сүз фәнни яктан ялгыш. Авазларны тикшерү өчен ясалган кораллар һәм машиналар белән тәҗрибәләрдә, гади тәҗрибәләрдә татар сүзләрендә мәд авазларының гына түгел, мәдсез авазларның да үз башына калын һәм нечкә булуларын күрсәтәләр. Телдәге һәр авазга бер хәреф булырга тиеш дигән тәкъдим буенча, төп татарча сүзләрне генә алганда да, безгә хәзерге әлифбабыздагы 31 хәрефебез урынына мәдле һәм мәдсезләре белән кимендә 60 лап төрле хәреф алырга тиеш булыр иде. Гыйльми транскрипцияләрдә һәр авазга бер хәреф алына, ләкин моңарга карап алар буенча укуда, язуда, уку-язу таныту да җиңелрәк түгел, бәлки авыррак, гамәли имляларга караганда бик күп җайсызрак.

Хәзерге имляга тагын дүрт мәд хәрефе арттыру, бер дә кирәкмәгәнгә хәреф күбәйтү, язуны яңа галәмәтләр белән чуарлату, бөтен укучы-язучы халыкны яңа күнегүләр ясарга ирексезләү, бабайларча әйткәндә, бердә кычытмаган җирне канга батырып кашу булыр иде[2].

Имляда унчылык агымы татар теленең үз төзелешеннән, үз кирәгеннән килеп чыкмыйча, безгә бары урыс язуы сөремтесе[3] белән генә килеп кергән. Гадәттә мәдәни тәэсирләр аллары, яхшы яклары белән генә түгел, артлары, начар яклары белән дә күп вакытта бергә керә баралар. Арттарак халыкларның тышкы күренеш тәэсиренә ныграк бирелә торган кайбер гөруһларына күршедәге алдынрак халыкларның начар һәм зарарлы гореф-гадәтләре дә алдынгылык сыйфаты, мәдәниятлелек хаҗәте асыл иясе булып күренә. Мәсьәлә-

[1] Тәҗвидләрен – дөрес укуларын.

[2] Урыс мөстәшрикълары тарафыннан төрек-татар телләре фәнни имлясы өчен мәдләрнең әсас *(нигез)* итеп алынуы да – фәнни транскрипцияләрдә алынган бәйнәлмиләл *(халыкара)* әсасларга хилаф бер юл. *(Г. Шәрәф иск.)*

[3] Сөремтесе – монда: «тәэсир, йогынты» мәгънәсендә.

не тикшерү мәд хәрефләре турындагы урыс сөремтесенең дә бик күп яхшы сөремтеләр арасында шундый арт як сөремтесерәк икәнен күрсәтә. Фән академиясе һәм тел галимнәре тануы буенча, урыс телендә фонетика ягыннан мәдсез (согласный) авазлар гына калын да, нечкә дә була алалар, мәд авазлары урысчада парлы түгел. Шуңа күрә урыс теленең үз табигатенә, гарәп теле имлясындагы йә безнең иске орхон төрекләре язуындагы кебек мәдсез хәрефләрне парлы итеп алып, мәдлеләрне берәрне генә алу муафыйграк[1] булыр иде. Урысның фән академиясе тарафыннан төзелгән гыйльми имлясында бу шулай ителгән дә. Ләкин урысның төрле, күптәнге тарихи сөремтеләр астында төзелгән гамәли имлясында шул ук урысның гыйльми имлясының киресе алынган: монда мәдсез хәрефләр берәр генә алынып, мәдле хәрефләр парлы итеп алынган. Урыс сүзләрендә *о, у, а* авазларының нечкәсе бөтенләй булмаса да, аерым, *ё, ю, я* хәрефләре кертелгән һәм шул хәрефләргә бердән *йо, йу, йа* мәгънәсе бирелеп, сүз башында булганда, бу хәрефләр бердән ике авазны күрсәтүләре *взял, трюк, вел* сүзләрендәге кебек сүз уртасында булганда, бу *я, ю, ё* хәрефләре үзләре *а, у, о* дип укылу белән бергә, үзләрендә булган *в, т* кебек мәдсез авазларның нечкәлеген дә күрсәтү бурычы йөкләнгән. Бу юл *большой, парь, конь, объём*[2] кебек сүз һәм иҗек актыгында килгән мәдсез авазлардан соң, аларның калынлык, нечкәлеген күрсәтер өчен, *ь, ъ* лар куярга мәҗбүр иткән. Икешәр, өчәр мәдсез авазлар бергә юлыкканда, кайда *ь* кую-куймаулар турында бик буталчык кагыйдәләр төзергә туры килгән. Бу парлы-парсыз хәрефләрне тиешенчә алмау чыгарган җайсызлыкларга, урысчада *вода, городской* [3]дип язылып та, *вада, гърадской*[4] дип басым тәэсире белән мәдләрне бөтенләй үзгәртеп уку мәҗбүриятләре туган. Башта алынган ялгыш юл, шулай итеп, урысның сөйләшү теле белән язу теле арасында фонетика ягыннан зур аерма тудырган. Тел белән язу арасындагы аермалар буталчык һәм аларны ачып салулар, халыкта урыс язуына «хөрмәтне киметәчәк» булганга, гадәттә урыс мәктәпләрендә укытыла торган имля-сарыф китапларына бу төп мәсьәләләрнең берсен дә кертмәгәннәр. Хәтта «Мәктәп грамматика-

[1] Муафыйграк – яраклырак, урынлы.
[2] Кириллицада бирелгән.
[3] Кириллицада бирелгән
[4] Кириллицада бирелгән.

сы» һәм «Фәнни грамматика» исемендә бер үк урыс теле өчен икесе ике, бер-беренә каршы әсаслардагы грамматикалар төзелгән. Фәнни грамматиканы бары тел гыйлеме белгечләре җитештерә торган гали мәктәпләрдә генә укытканнар; телнең табигате, әсасы, фонетика кануннары, имляның нигезләре кебек мәсьәләләрне күпчелеккә укытыла торган мәктәп грамматикасына кертмәгәннәр. Хәзер дә әле урыс мәктәпләрендә бу күбесенчә шул хәлдә бара. Урыс имлясы фәнни яктан никадәр буталчык булсын, уку-язу ягыннан һәм тиешле ысуллар тотылганда үз халкына өйрәтү өчен артык зур гамәли җайсызлыклар ясамаганга, шул килеш барган. Революция башында ясалган урыс имля реформасында да бу әсаси буталчыкларга һич кагылмадылар, бары вак-төяк гамәли җиңеллекләр кертә торган төзәтмәләр кертү белән генә калдылар.

Урыс имлясының үзе өчен дә җайсыз һәм нигезсез булган, безнең өчен һичбер гамәли кирәге булмаган мәдләрне калын һәм нечкә парлы итеп алу юлы безнең имлябызга да керергә омтылып караган. Бу сөремте вакытында, телче, имлячыларыбыз арасыннан үзенә кайбер яклаучылар да тапкан иде. Татар теленең авазлары фәнни рәвештә тикшерелмәгән бер дәвердә, урыс теленең һәм имлясының фәнни яктан төзелү кануннарын тикшерергә алар белән якыннан танышырга хәзерлеге һәм имкяне[1] булмаган Каюм Насыйри өчен бу сөремтегә бирелүне гаептән санамаска мөмкин; ләкин татар теленең авазлары тикшерелгән һәм тагын да ныклабрак тикшерергә мөмкин бер дәвердә, тәрбия техникумнарында һәм кайбер башка урта мәктәпләрдә дә урыс теле һәм имлясының фәнни яктан төзелеше таныштырылып үтә торган бер дәвердә, мондый үзе файдасыз, файдалылары белән турыдан-туры бәйләнмәгән сөремтеләргә бирелү урынсыз һәм гаеп саналырга тиеш.

***و /уау, ی /йай ларның мәдле һәм мәдсез хәлләре***

*Тау, тай* дигәндәге мәдсез و /*уау,* ی /*йай*лар өчен, *туган, тыйган* дигәндәге мәдле و / *уау,* ی / *йай*ларга алынган хәрефләргә башка булган, аерым хәрефләр алу-алмау мәсьәләсе дә – гамәли мәсьәлә. Фәнни тәҗрибәләр «тау – туган» сүзләрендәге و / *уау* авазлары икәве дә авазлык (мәхрәҗләре) һәм төзелешләре ягыннан бер үк авазлар икәнен күрсәтәләр; бу ике و / *уау* бер-береннән бары иҗек

[1] Имкяне – мөмкинлеге.

ясау, ясамау белән генә аерылалар. *Бар, кара* фигыльләреннән эш исемнәре булган *бару, карау* сүзләренең сарыф ягыннан төзелешен карасак, бу урында боларның берсе урынына берсе килгәнен күрәбез. Татар теле фонетикасының төп кануннарыннан берсе – сарфи үзгәрүләрдә ике иҗек ясый торган авазның бергә була алмавы канунылыр. Бу төп канун буенча сарфи үзгәрүләрдә ике иҗек ясый торган авазның бергә була алмавы – кануннардыр. Бу төп канун буенча сарфи үзгәрүләрдә ике иҗек ясый торган аваз бергә килсәләр, йә икәве кушылып, берсе берсен йота *казый, казу,* йә икәвенең кушылуыннан өченче бер аваз ясала *аша – ашый,* йә *сулый – сулышы* кебек ике арага өченче бер аваз кертелә, йә *бару – баруы* кебек ике мәдле аваз саклана. Ләкин арага беренче аваз мәдсезләнеп, тәкрар[1] керә; йә инде, «кара» фигыленнән «карау» ясалган кебек, ике иҗек ясый торган (мәдле) аваздан берсе, иҗек ясау көчен югалтып, шул ук авазның иҗек ясамый торганына (мәдсезенә) әйләнә. (Безнең «Мәктәп сарыфларында» бу мәсьәләләрне төп тел кануныннан чыкмый төрле ясалма кагыйдәләр белән генә аңлатырга тырышылган). Тел гыйлемендә мондый бер мәдле авазның икенче мәдле аваз янына килү сәбәпле, берсенең иҗек ясау хасиятен югалтуыннан хасил булган ярты мәд авазларына дифтонг диләр. Мондый дифтонглар күп Аурупа телләрендә дә бар. Аваз ягыннан бер булганга, гадәттә аларда да мондый дифтонглардагы иҗек ясамый торган мәд авазларына аерым галәмәтләр йөртмиләр. Дөрес, урысларда *мой* кебек сүзләрдә языла торган *и* дән үзгәртелгән һәм «ярты гласный» дип аталып йөртелгән аерым *й* бар; ләкин урысларда бердән күп урыннарда *и* һәм *й* ларның авазлыгы безнеке кебек бер түгел, аннан бигрәк урысларның көндәлек имлясында *возьми* сүзендәге *и* белән *мои слова* сүзендәге *и* авазларына икәвенә дә шул ук *и* хәрефе алынган; шуның аркасында аерым *й* хәрефе алмаганда, мәгънә һәм сөйләнеш ягыннан бер-беренә башка булган *мой, мои* сүзләрен ачык укырга мөмкинлек калмаган; урысларда элеккедән *мои* дигәнне, татар имлясында алынган әсас буенча, *маии* дип язылу кереп киткән булса, гамәли имляда аларда да аерым *й* алмаска мөмкин булыр иде. Бер халыкка урнашкан, кагыйдәләшкән булганга, урыслар бу *йи* мәсьәләсен, шулай ук *йа, йу, ио* дифтонглары уры-

---

[1] Тәкрар – кабат.

нына иҗек язуы әсасында булган *я, ю, ё* ларын саклыйлар. Һәрбер авазның иҗек ясый һәм ясамый торган төрләренә аерым хәрефләр алганда, татарчада сирәк булса да очрый торган *«кырт кисте, пылт итте»* кебек сүзләрдә *р, л* авазларының да иҗек ясый торган чаклары була. (*Крт, плт* сүзләренең *кылт, пылт* булмавы, бу сүзләрне, гади рәвештә әйткәндә, фәнни тикшерүләр *ы* мәхрәҗенең[1] бөтенләй ясалмавын күрсәтәләр; әйтелештә мәхрәҗе булмагач, сүздә авазы да була алмый.) Татар телендә иҗек ясамый торган و / *уау,* ى / *йай* ларның, иҗек ясый торган авазлар алдыннан йә артыннан гына килү кануннарын һәм гомуми уку агымы кануннарын хәтергә алганда, татар имлясы төзелешендә иҗек ясый һәм ясамый торган و / *уау,* ى / *йай* ларга аерым-аерым хәрефләр алуның гамәли кирәге юк. Без укыганда да, язганда да моңа ихтыяҗ сизмибез. «Ысулы саутия»-нең бик искергән балталама[2] белән бармаганда моның укыту, язу таныту өчен дә кирәклеге юк. Фәнни транскрипцияләр мәсьәләсе исә – гамәли имляга мөнәсәбәтсез аерым бер мәсьәлә.

***Һәмзә мәаләсе***[3]

*«Маэмай, мәсьәлә, мәсьүл»* сүзләрендәге (ءَ) авазының татарчада *«әтәч, ат, ут, ит, эт»* сүзләренең башында, мәд авазлары алдында, фонетика ягыннан караганда, булуы-булмавы турында фәнни мөзакәрә ясарга мөмкин; татарчада аерым алынган сүзләрнең башында һәмзәнең барлыгы фәнни яктан дәлилләр белән ачыкланган тәкъдирдә дә, ул анык һәмзәнең дә гарәпчә йә грекчадагы кебек гамәли имляда аерым хәреф белән күрсәтелүе йә немецчадагы кебек фәнни яктан бар дип табылганда да бары гыйльми имляда гына күрсәтелеп, көндәлек имляда күрсәтелмәскә тиешлеге турында сүз булу мөмкин. Ләкин бу аңлашуларда да урыслар язмый, йә гарәпләр яза, дип карамыйча, татар теленең һәм имлясының үз төзелеше һәм үз көндәлек уңайлыгы ягыннан карарга мәҗбүр булачакбыз. Бу аңлашулар нинди нәтиҗәләр генә бирмәсеннәр, һәрхәлдә *аш, ат, ак, ал, ил* кебек сүзләр *аш, ат, ак, ал, ил* рәвешендә язылса, боларны *эш, эт, эк, эл, и* дип укудан күпчелек котылып бетмәгән бер дәвердә мондый «реформа»ны, «истисна бетерү»не караарлаштыру урынсыз.

[1] Мәхрәҗ – авазның ясалып чыга торган урыны, артикуляция базасы.
[2] Балталама – җимерү.
[3] Мәаләсе – мәгънәсе, эчтәлеге.

***Ябык иҗекләрдә ۤ /ы, е/ мәсьәләсе***

ۤ хәрефенең беренче иҗекләрдә һәм һәммә ябык иҗекләрдә язуда күрсәтелмәве, татар теленең төзелеш кануннарын хәтергә алганда, фәнгә, фонетикага хилаф[1] диярлек бер эш түгел. Гамәли яктан караганда, *тлсз, блмсез бр кше* дигән җөмләне шул хәлдә укуы да, язуы да матбагада хәреф җыю өчен дә *телсез белемсез бер кеше* рәвешендәге имляга караганда җиңелрәк. ۤ нең кайда язылуы, кайда төшереп калдырылуы һәрбер теләгән кеше аңларлык икеюллык бер кагыйдәгә кереп беткән. ۤ авазы – татар телендә иң күп кабатлана торган аваз. Бер үк текстны хәзерге имлядагыча, беренче һәм ябык иҗекләрдә ۤ не төшереп, һәм Уфа комиссиясе карарынча, төшермичә, хәреф җыйдырып, икәвен чагыштырып карасак, без соңгысында бөтен текстның беренчесенә караганда 9–10 процент кадәр озынрак чыгуын, шул чамада урын күбрәк алуын күрербез. Тәҗрибәләр безнең бу кагыйдә аркасында урын алу ягыннан иткән файдабызның, сүз башында бөтен мәдләр алдына куя торган һәмзәләребезнең алган урыннарын бер ярым мәртәбә каплаганын күрсәтәләр. Бу икеюллык кагыйдәгә балаларны өйрәтү, бигрәк тә күнектерү, укытучыдан үз урынында аерым әһәмият биреп китүне, берничә сәгать, бәлки артык вакыт бирүне мәҗбүр итә икән, бу күнегү сәгатьләре, бер өйрәнгәч, билгеле процентка язу-уку вакытын кыскартып бару, укырга ала торган һәр китабын шул ук процентка арзанайту, укый торган гәзитендә материал арттыру формаларында гомер буена дивидент (табыш) биреп торуы, бу кагыйдәнең гомердә бер була торган өйрәнү дәверендәге берничә сәгать артык вакыт алуына борчылмаска мәҗбүр итә. Гомумән, мәктәп тормыш өчен булып, аның бөтен вазифасы баланың киләчәк тормышын җиңеләйтү, уңайлатуга кайтып кала. Өйрәтүе җиңелрәк булсын дип, хисап, җәбер, һәндәсәне[2] ватып булмаганы кебек, язу танытудагы бик вак җиңеллекләр өчен имляны да ватып, гомерлек тормыш йә бөтен язу таныган кешеләр өчен җайсызрак бер хәлгә куярга туры килми. Бу турыда укытучы һәм тәрбия белгечләребезнең бурычы – боларны тормыш өчен авырлатуга калкынмыйча, бар кагыйдәләр нигезендә, урнашкан имляны балалар һәм үзләре өчен җиңелрәк өйрәнү-өйрәтү юлларын эзләнү һәм тотудадыр.

[1] Хилаф – каршы.
[2] Җәбер, һәндәсәне – алгебра, геометрияне.

***وُ /о, ө/ мәсьәләсе***

Төрек-татар телләрендәге وُ авазының кайбер хасиятләре бар. Ул аваз сүзнең беренче иҗегендә булмаса, башка иҗекләрендә һич очрамый. Инде сүзнең беренче иҗегендә булса, бу وُ шул сүздәге үзеннән соң килгән һәммә авазларның төсен берникадәр үзгәртә, аларның ишетелүенә (акустикасына) وُ сөремтесе бирә. Әйтелеше кыска, авазлык (мәхрәҗ[1]) ягыннан төзелеше зәгыйфь булган ـُ авазында бу сөремте башка авазларга караганда ныграк күренә. *Алб, башм* / *алыб, башым* сүзләрендәге *-ыб, -ым* сарфы ялгаулары, «*тотб, кошм*» сүзләрендә «*тотыб, кошым*» рәвешендәрәк сөйләнүе шушы сөремте аркасында бу сөремте وُ гә якын иҗекләрдә көчлерәк, ерак киткән саен кими бара. Сөремтенең көче кимүгә ике арага нинди мәдсез хәрефләр керүе дә тәэсир итә. Бу сөремтенең сәбәбе – безнең ирен әйләнәсендәге итсәләрнең (мышца) төзелеше һәм аларның وُ авазын әйткәндәге куелышындадыр. Бу сөремте тигезсез һәм төрле булганга, гамәли имляда бу сөремтене күрсәтү-күрсәтмәү мәсьәләсендә түбәндәге ике юлның берсен генә тотарга мөмкин. Йә беренче иҗектә وُ булганда, аның артыннан килгән һәммә ـُ авазларын وُ гә әйләнә дип карарга, бу урыннарда ـُ урынына وُ хәрефе язу; йә وُ хәрефен беренче иҗектә генә язып, башка иҗекләрдә һәммәсендә ـُ язу. Соңгы юл сарыфы берлек әсасын саклаганга, татар гамәли имлясында шул юл тотылган. Шул юл белән татар имлясында *оныттырды, өметсезлек, төпсезлек* рәвешендә язылырга тиеш (болай язу керәшен имлясында, урыс мөстәшрикъларының төрек-татар телләре өчен төзелгән «фәнни» транскрипцияләрендә азәрбайҗаннарның латин әсасындагы имляларында алынган). Сөремтенең төрле сүзләрдә тигезсез булуы, фонетика ягыннан бу юлның һәр икәве белән файдаланырга юл куя. Ләкин сарыф берлеге әсасы гамәли имляда татар имлясында алынган юлны алга куя. Төрле төрек телләрендә бу сөремтенең төрле юлларда булуы, мәсәлән, татарчадагы ـُو урынында *о* авазы булган телләрдә бу аваздан соң да шундый ук сөремтенең булуы төрле төрек телләре имляларының якынлыгын саклау өчен дә бу сөремтенең гамәли имляларда күрсәтелмәвен алга сөрә.

Уфа карарларына килсәк, анда وُ нең беренче иҗектә генә язылу кагыйдәсе бозылып, төп сүзнең һәрбер ишетелгән иҗегендә

[1] Мәхрәҗ – авазның ясалып чыга торган урыны, артикуляция базасы.

язылыр, бары ялгауларда гына күпчелеккә каралыр, диелә. Ләкин карарда төп сүз белән ялгауны ничек аеруны күрсәтмиләр. Уку-язу массага керсен өчен, имля кагыйдәләре һәркем җиңел аңларлык, тиз өйрәнерлек һәм бертөрле рәвештә язарлык булырга тиеш. *Озн, борн, бөтн, төтн, өзк, тәзк, бозк* сүзләренең *озак, бормак, бөтәйтмәк, тотамәк, өзмәк, төзмәк, бозмак* сүзләре белән бер төптән булуын хәтта *болн, болт* сүзләренең *болан, була, бук* сүзләре белән бер төптән булу ихтималын хәтергә алганда, мондый сүзләрнең төбе белән ялгавын аерыр өчен, бер тел галиме кадәр тел белгече булырга кирәклеге күренеп тора. Уфа комиссиясе рәисе имзасы белән язылып, бу яктан «яңа имля» белән басылган бу карарларда: *төрле, төрлечә, йөрдекендән, йөртелә* рәвешендә язылган сүзләр белән беррәттән үк *төзергә, бөтен, борын* сүзләре очравы, нәрсә ялгау, нәрсә төп икәнен, яңа имляны төзүче һәм аны доклад ясап кабул иттерүче комиссия үзе дә аерып бетерә алмаганын һәм бу аеру өчен ныклы бер нигезләре булмаганын күрсәтә.

***«гъ-г, къ-к» мәсьәләсе***

Татар имлясында калынлы-нечкәле дип карарлык өч пар: *а-ә, гъ-г, къ-к* хәрефләре бар. Ләкин *а, гъ, къ* ларның *ә, г, к* аермасы *булды* сүзендәге калын *б, у, л, д, ы* авазларының *булды* дигәндәге ничә *б, у, л, д, ы* авазларының аермасы рәвешендә түгел. *Булды-булды* сүзләрендәге һәммә аерым авазларның төп авазлыклары (мәхрәҗләре): *б, у, ы* ларда иреннәрнең ачылу-йомылу дәрәҗәсе *л, д* ларда тел очының алгы аңкауга тию урыны һәм тию рәвеше, калыннарында да, нечкәләрендә дә бер үк. Боларның мәдле һәм мәдсезләренең барында да калыннарының нечкәләреннән аермасы бары, авазга һәм сүзгә калынлык йә нечкелек бирә торган телнең урта бер кыйсеменең нечкә сүзләрдә алгарак килеп, калын сүзләрдә арткарак китүендә генә. Тел уртасының бу алга йә артка таба хәрәкәте, авыз эче күләмен зур итеп кечерәйтеп, авазның калын йә нечкә ишетелүенә сәбәпче булган яңгыравыкның (резонатор) күләмен үзгәртә. Без физикадан, бер зур, бер кечкенә шар алып, икәвенә дә тигез зурлыкта тишекләр ясап, икәвен дә ирен алдына китереп, *өреп* карасак, зур шарны *өргәндә* – калын тавыш, кечкенә шарны *өргәндә* нечкә тавыш чыкканны күрәбез. *Булды-булды* сүзләрендәге аерым мәдле һәм мәдсез калын авазларның нечкә төрләреннән аермасы төбе шул яңгыравык зурлыгы

аермаларында. *А, къ, гъ* ның, *ә, к, г* ләрдән төп аермасы яңгыравыкта түгел. Боларның аермасы бер-береннән авазлыклары да башка булуында. Фәнни тәҗрибәләр татарчадагы *у-ү, о-ө, ы-е* авазларының һәр парында иреннәрнең бер-береннән ераклык-якынлыклары бер рәвештә калган кебек, болардан һәр парның ачык, ябык, басымлы, басымсыз иҗекләрдәге әйтелеш дәвамы да (озынлык-кыскалыгы) бертигез. *А-ә* авазларында исә болар өчен төп авазлык булган иреннәрнең бер-беренә якынлык ераклыклары башка булган кебек, боларның әйтелеш дәвамнары да төрлечә. *Ә* үзенең әйтелеш дәвамы ягыннан татарча да *и* ләр белән бертигез. *Ә* дә иреннәрнең *а* га караганда якыная һәм җәелә төшүе дә *ә* авазын *и* гә якынайта. Башка байтак төрек телләрендә *кәрәк, кәл, әки, бәш* рәвешендә сөйләнгән сүзләрдә Идел буе татарчасында *кирәк, кил, ике, биш* рәвешендә *ә* нең *и* гә әйләнүенә бу авазларның кайбер якынлыклары юл куйган. *«Къ, гъ»* ларның да аңкаудагы авазлыклары «к, г» авазлыкларыннан башка, алардан арттарак. Бу дүрт аваздан һәркайсының: *«гәрәбә – гармун, багана – гарәб, каләм, кәләм, калуш – кәвеш»* кебек сүзләрдә калыннары да, нечкәләре дә аерым-аерым булганлыклары күренә. Бу сүзләрне *гъ-к* не имлядан чыгарып *гәрәбә, гармун, калуш, кәвеш* дип язуга йә *къ, гъ* не имлядан чыгарып: *багана-гәрәб, кәләм-кәләм* рәвешендә язуга нә фәнни, нә гамәли бер әсас та юк. Уфа комиссиясенең бу карары да файдасыз сөремте белән эшләнгән, фәнгә хилаф һәм гамәлгә җайсыз бер ватма ясаудан гыйбарәт.

***Имлядагы сарыф моментлары***

Татар имлясында *таб, күб, китде, ашдан, таңдан* кебек сүзләрдә *п, т, н* кебек ишетелгән авазлар урынына *б, д* язылуы *табы, күбесе, килде, алдан, яздан* кебек сүзләргә ияртелеп, сарыф берлегеn саклау өчен ясалган. Гамәли имляда сарыф әсасында кирәкле җирләрендә алуның уку агымын тизләтү, телнең сарыфын өйрәтү-өйрәнү өчен һәм төрле якын шивәләрне берләштерү өчен уңайлыклары бар. Урыс һәм Аурупа халыклары гамәли имлясында да шуңар күрә сарыф берлеге әсасына киң урын бирелгән. Имляның җиңел аңлаешлы кагыйдәгә каратылган, уку-язу өйрәтү өчен зур авырлык китерми, әдәби телнең имля нигезләрен бозмый һәм матбугатта вә халык арасында җитәрлек урнашканнарын вату өчен дә нә гыйльми, нә гамәли әсаслар юк.

***Мәсьәләнең куелышы***

Инде мәсьәләнең куелу формасы вә тактика ягына килик. Башкортстанда 1925 елны «Башкорт имляһы» дип югарыдагы әсасларда ук тәкъдимнәр белән бер китапчык чыгарганнар икән. Бу китапчык күбрәк мөзакәрә рәвешендә басылганга, бигрәк тә китапчыкларыннан аңлашылганча, алар «Башкорт теленең имляһы» татар имлясы белән санашмаска мөмкин һәм тиеш, дип караганга, без алар кузгаткан мәсьәләнең мөзакәрәсенә катнашмый калдык. Ләкин соңгы карарлар шул ук Башкортстанның Уфа каласында булса да, татар имлясын әсасан үзгәртү турында булганга, без бу карарларга туктамый китә алмыйбыз. Татарстан, Казакъстан вә башка милли совет җөмһүрият вә өлкәләренең төзелү әсасларыннан берсе – бу милләтнең зур бер кыйсеме торган һәм үзе күпчелек тоткан бер даирәне алып, шунда киң халык массасының көндәлек тормышына һәм әдәбиятына бәйләнгән мәсьәләләр өчен автоном бер идарә төзеп, шул милләтнең бу даирәгә кергән һәм кермәгән кисәкләре өчен мәдәният мәсьәләләрендә турыдан йә кыеклап юлбашчылык итү, таралган көчләрен шунда җыеп, нәфис сәнгать, матбугат, әдәбият, тел, сәяси, иҗтимагый, фәнни мәсьәләләрнең шул телдә эшләнүен тәэмин итү, гомумән артта калган, мәдәнияте киңәеп, бәллүрләнеп (кристаллашып) җитмәгән халыклар өчен шул тел һәм шул халыкның яхшы якка булган хосусиятләре даирәсендә мәдәниятләрен бәллүрләндерү үзәге булу вазифасыдыр. Имля мәсьәләсе дә – бөтен халыкның мәдәниятенә һәм мәгарифенә бәйләнгән мәсьәлә булганлыктан, мәдәни бәллүрләнүнең төп нигезләреннәндер. Башкортстан кебек татарлар азчылык милләт санала торган бер өлкәдә, йә Саратов, Пенза, Нижгород кебек бер губернада биш кеше җыелып, комиссия ясап, кайбер шәһәр учительләрен җыеп, татар имлясының әсасларын үзгәртү турында карарлар чыгарту, бигрәк тә шуларны съездларда һәм төп милли җөмһүриятнең шундый эшләр өчен ясалган мөәссәсәләре[1] белән хәбәрләшмичә матбугат һәм мәктәптә гамәлгә куя башлау, башбаштаклык һәм мәдәни дисциплинасызлык дип кенә атала ала. Билгеле һәр җирдә мөзакәрә юлы белән, тар даирәдә башлау тәҗрибәләре рәвешендә һәр нәрсәне эшләргә мөмкин, ләкин мондый тиешле тикшерүсез, шартсыз карарлар, тәҗрибә

[1] Мөәссәсәләре – оешмалары, учреждениеләре.

рәвешендә генә булмаган гамәлгә куюлар булмаска тиеш. Юк исә, төрле төрек телләренең дә бер-бере матбугатыннан файдалануны җиңеләйтү өчен, имляларын мөмкин кадәр якынайту мәсьәләләре алда торган бер вакытта, мондый карар һәм гамәлгә куюлар белән без төрле губерна һәм өлкәләрдә бер үк татар телендә язылган һәм басылган нәрсәләрне дә укый һәм аңлаша алмау хәленә килербез.

Мәсьәлә белән гомумән таныш булмаганнар, мәсьәләнең эшләнүенә катышмыйча, үзләренә эшләнгән нәрсәләргә тавыш бирү бурычын гына алырга тиешләр. Итек ясар өчен итек кия белү генә җитми, итекче булу да кирәк булса, имля-язу мәсьәләләрендә һәркем хәзерләнми хәл итәргә керешергә тиеш түгел; юк исә урыс һәм азәрбайҗан матбугатындагы мәкаләләрендә «татарчада “оч, өч, уч, үч” сүзләре бар да бертөрле “өч” рәвешендә языла» дип язган Шамил Госманов хәленә төшәргә мөмкин.

Кайбер иптәшләрнең янгын (ут) чыккан кебек күп үлчәп, сөйләп, күп уйлап тормыйча гарәп әсасындагы язуны ничек булса алай тизрәк «ислах» итәргә, нәтиҗә ягы белән, латинның хәрефен алмасак, һич булмаса имлясын алырга кирәк, юк исә латин керә, дип куркытып кабык кагучыларга, андый янгын булмаганын, ут дип күрсәтелгән нәрсә мираж гына булуын әйтеп, мәсьәләләрнең кызулыксыз, кабык кагусыз, үзләренең салмак юллары белән барырга тиешлеген белдерәбез.

Хәзерге татар имлясы – «әлифче, өч-мәдче, сад-че» гарәп имлясы сөремтесе белән «һәмзәсез, ун мәдче, “й” чы» урыс имлясы сөремтеләренең ун еллар буенча көрәшләре, татар теленең үз хосусиятләреннән чыгып эшләнгән тикшерүләр, бу турыдагы матбугатта, съезд, киңәшмә һәм комиссияләрдә килеп чыккан фикерләрне хисапка алып, һәм шуларны сөземтәсе (нәтиҗә) булып чыккан, моннан дүрт-биш ел элек ныклап декретлаштырылган бер имля. Бу имля – бөтен төзелеше, кагыйдәләре китап бите белән бер ярым биткә кереп бетә торган һәм әлифба өйрәткәндә үк төшендереп бетерергә мөмкин булган сөйләшкә (фонетиклыкка) якын булган бер имля. Аңа кадәр 15 еллар буенча безнең имля мәсьәләләре белән чуалуыбыз – бездә электән һәркем бертөрле яза торган ныкланган бер имляның булмавы, һәрбер нык нигезле мәдәният өчен моның төп кирәкләреннән булуыдыр. Миллионлап укый-яза белүчесе булган бер халык арасында ата-бабадан килгән беренче яратылыш

һәм төрле сөремтеләр нәтиҗәсе булган имля буталчыклыгы эчендә хәзерге татар имлясы кебек җиңел, садә[1] бер имляны да тәмам гамләштереп[2] бетерү вазифасы 4–5 ел эчендә генә эшләнеп бетә торган вазифа түгел. Хәзер бөтен татар матбугатының һәм татар халык мәктәпләренең 80–90 проценты, түбән совет мөәссәсәләрендә[3] татар телен ныклап гамәлгә куючы татар эшчеләренең 70–75 проценты шушы имля белән бара. Йә шуның белән барырга тырыша, имля мәсьәләсендә безнең хәзерге дәвердәге бурычыбыз – яңа мөгезләр чыгару булмаенча, матбугат, мәктәп һәм мөәссәсәләрдә имля дисциплинын 100 процентка җиткерү, һәм киң укучы гаммәнең күнегүләрен шул юлга салып бетерү вазифасыдыр. Билгеле, безнең имляда әле ныклап кагыйдәгә алынып бетмәгән ялгауларның кайсын кушып, кайсын аерым язу, чит телләрдән кергән сүзләрнең татарчада язылышын ныклап бер юлга кую, тыныш тамгалары йөртелешен билгеләп бетерү кебек мәсьәләләр бар. Бу мәсьәләләрнең урнашкан әсасларны бозмыйча, салмак рәвештә хәлле якын килүдәге – мәсьәләләребездәндер.

Гомумән алганда, имля мәсьәләсен бездә инде җитәрлек бәллүрләшкән бер мәсьәлә итеп карарга һәм якын дәвердә төп әһәмиятне хәреф ислахы, әдәби телдәге истыйлях[4] вә гыйбарәләрне бер калыпка салу мәсьәләләрен бәллүрләштерүгә таба юнәлдерергә тиешбез. Билгеле, болардан бик күп әһәмиятлерәк һәм нигезрәк булган татар киң гаммәсен икътисади, иҗтимагый яклардан күтәрүне тизләттерү мәсьәләләре бар; бу мәсьәләләр башка мәүзугълар[5] булганга, без монда аларга кагылмыйбыз.

*Мәкалә «Мәгариф» журналының 1926 елгы 5 санында «Галимҗан Шәрәф» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр басыла.*

---

[1] Садә – гади.
[2] Гамләштереп – массалаштырып.
[3] Мөәссәсәләрендә – оешмаларында.
[4] Истыйлях – атама, термин.
[5] Мәүзугълар – темалар.

# ЛАТИН ХӘРЕФЛӘРЕН АЛЫРГАМЫ? ГАРӘП ХӘРЕФЛӘРЕН ИСЛАХ ИТӘРГӘМЕ?[1]

***I – Имля[2] һәм хәреф мәсьәләләре.***

Хәреф вә имля ислахы мәсьәләләре – бөтен төрек-татар дөньясы матбугатында күптәннән зур урын алып килә торган, бу көндә дә тавышлы моназарәләргә[3] сәбәпче булган бер мәсьәлә. Татарстан, Төркестан, Азәрбайҗан, Төркия, Кыргызстан, хәтта Хива, Бохара, Кырым кебек өлкәләрдә дә бу мәсьәләләрдә төрле ноктада торган төркемнәр бар, бу төркемнәр арасында көрәшләр бара. Бу өлкәләрнең һәммәсендә дә хәреф ислахы мәсьәләсе дә, имля ислахы мәсьәләсе дә мөзакәрә ителә. Бер-беренә мөнәсәбәтле, шуның белән бергә бер-береннән бөтенләй аерым булган бу ике мәсьәләне бик күп кешеләр, вә шул җөмләдән азәрбайҗан латинчылары да катыштырып йөрткәнлектән[4] бу мәсьәләләрне бер-береннән аерып китәргә ихтыяҗ бар.

Имля мәсьәләсе сүзнең нинди авазга йөргән хәрефләр белән язылуын-басылуын һәм шул хәрефләр кайбер авазларга җитмәслек булса, шуларны арттыруны гына тикшерә: гомумән алганда, хәрефләргә нинди шәкел, вә бу шәкелләргә нинди әсаслар[5] алынуда имляның эше юк. Хәреф мәсьәләсе исә аерым сүзләрнең ничек һәм нинди авазларга йөргән хәрефләр белән язылуын-басылуын тикшерми, ул бары аерым алынган авазларга нинди шәкелдәге хәрефләр алынырга тиешлеген вә бу шәкелләрнең рәсемнәрендә нинди гомуми әсаслар алынырга тиешлеген генә тикшерә. Мәсәлән, *күренделәр* дигән сүзне *күрнделәр, күрнделр, күрндиләр, күрүндиләр, күрндиләр, күренделәр, күриндләр* рәвешендә бер үк әсастагы хәрефләр белән бик күптөрле итеп язарга мөмкин. Болар арасыннан кайсын сайлап алуны имля (орфография) мәсьәләсе тикшерә. Инде бу сүзләрнең

[1] Мөнакашә *(җентекләп тикшерү)* рәвешендә басыла – Идарә. *(«Мәгариф» журналы иск.)*

[2] Имля – орфография, дөрес язу кагыйдәләре.

[3] Моназарәләргә – бәхәсләшүгә.

[4] Азәрбайҗан латинчыларының әсаси декларацияләрендә латин хәрефләрен кабул итү турында 6 маддә китерелә: бу маддәләр барысы да диярлек имля мәсьәләсенә кайтып калалар. «Безнең (азәрбайҗанлыларның) имлябыз начар, димәк хәрефләрне алмаштырырга кирәк» дигән нәтиҗәгә киләләр. *(Г. Шәрәф иск.)*

[5] Әсаслар – нигезләр.

кайсы имлясы гына алынмасын. Анда ه, ل, ىُ, ى, وُ, ر, و ك авазларына нинди әсастагы, нинди шәкелләрдәге хәрефләр алуны (мәсәлән, *күренделәр* имлясын алсак, аны *күрнделәр, күрнделәр, кюрндиләр, кюрнделяр*[1]*, kurndeler*[2]*«* шәкелләреннән кайсы белән язуны хәреф (шрифт) мәсьәләсе тикшерә.

Без имлябыз өчен урыс йә латин хәрефләрен алырга карар бирәбез икән, безнең алдыбызда хәзер гарәп хәрефләрен истигъмаль иткәндә нинди имля мәсьәләләре булса, урыс йә латин хәрефләрен кабул иткәндә дә бу мәсьәләләр шулай ук кала. Мәсәлән: بر – كيتدىُ – مائماى – مه سئه له – كييم – ئوُتدردق / *бер, китте, маэмай, мәсьәлә, кием, оттырдык* сүзләрен алсак, боларны урыс хәрефләре белән: *бр – бэр – бер, киттэ – китте – китдэ – китде – кейтде, мясьэля – мяс'эля – мяс'аля – мяс'яля, булганлар – булганнар, ма'май – макмай – макмай, кием – кейем – кеем – кэйэм – кийем, отдордок – отдырдык – оттордок – оттырдык – отдрдк*[3] шәкелләреннән кайсы белән язарга? кебек сөальләр, хәрефләр һәйәтен[4] алмаштыру белән генә хәл ителмәгән кебек, бу мәсьәләләрне хәл итәр өчен хәрефләр һәйәтен алмаштыруга да ихтыяҗ юк. Латин йә урыс хәрефләрен берсе урынына берсен йөртеп, кайсын йөзтүбән куеп, кайсына койрыклар, билгеләр арттырып, телебезнең авазларына яраарлык ясарга мөмкин булса, гарәп хәрефләрен дә шул ук юллар белән дөньядагы һәрбер телне язарлык хәлгә китерергә мөмкин. Латин йә урыс хәрефләрен кабул итсәк, бөтен имля мәсьәләләре дә үз-үзеннән хәл ителә, яңа хәрефләр белән бергә, мәгълүм бер әсастагы яңа имля үз-үзеннән сизелмичә кереп китә дип уйлаучылар ялгышалар.

Латин хәрефләре кабул итү белән имля мәсьәләсе хәл ителгән булмый, бәлки ике мәсьәлә бергә буталып, халык өчен ике яңалыкны (яңа хәреф һәм яңа имляны) өйрәнү бер үк вакытта бирелгән була. Гамми[5] әһәмияте булган бу ике зур яңалыкның бергә кертелүе, боларның һәр икесенең хәятка керүен җиңеләйтми, бәлки һәр икәвенең хәятка керүенә авырлык кына китерә, йә берсенең дә кермәвенә сәбәпче була.

[1] Кириллицада бирелгән.
[2] Латин графикасында бирелгән.
[3] Әлеге мисаллар кириллицада бирелгән.
[4] Һәйәтен – сурәтен, күренешен.
[5] Гамми – гомуми, күмәк.

Югарыда күрсәтелгән сәбәпләрдән, без имля мәсьәләсен хәреф мәсьәләсеннән аерып йөртәбез, һәм бу мәкаләдә хәреф мәсьәләсен генә карыйбыз.

***Хәреф ислахы мәсьәләсе ник күтәрелде?***

Безнең әлегә чаклы килгән хәрефләребез ب / *сүз башы, сүз уртасы, сүз ахыры, аерым хәреф* кебек дүртәр шәкелле булып йөриләр. Бу: 1) матбага техникасы (хәреф кисү, кую, җыю эшләре) өчен зур җайсызлык ясый; 2) балаларга хәреф таныту эшен авырайта; 3) ج, م , ا, ک / *җим, мим, әлиф, кәф* кебек өсткә-астка сузылган хәрефләр юл арасын киңәйтеп һәр сәхифәгә юллар (сәтырлар) саны аз керүгә, шул сәбәпле бер үк зурлыктагы китапның кыйбаткарак төшүенә сәбәпче була; 4) гарәп хәрефләре техника ягыннан әз эшләнгән, мәсәлән, язу машиналарына куелмаган, телеграф вә гайреләргә куеп каралмаган кебек сәбәпләр. Болар өстенә, гарәп хәрефләрендәге нокталар ысулы уку, күз өчен авыр, гарәп хәрефләренең гомуми әсаслары латин йә урыс хәрефләренә караганда тигезсез, ямьсез, латин йә урыс хәрефләрен алу безне Русиядәге гарби Аурупадагы башка халыклар белән якынлаштырачак кебек карашларда булган кешеләр дә бар. Шул сәбәпләрнең барысын бергә алып, хәреф ислахы йә аларны бөтенләй алмаштыру мәсьәләсе алга сөрелә.

***Хәреф ислахы мәсьәләсендә бездәге агымнар[1]***

Мәсьәләдәге агымнарны ике төркемгә бүләргә мөмкин. Берсе – гарәп хәрефләренең төп шәкелләрен саклау, тик аларны төрле юллар белән кирәгенчә ислах итеп, мөкәммәл бер хәлгә китерү; икенчесе – гарәп хәрефләрен бөтенләй ташлап, алар урынына латин йә урыс хәрефләрен кабул итү. Мәсьәләнең тәфсыйлатын[2] читкә ташлаганда, бу ике төркемдәге агымнар биш әсаси тәкъдимгә кайтып калалар:

1. Басма һәм язу өчен әлегә чаклы йөргән гарәп хәрефләренең дүрт шәкеленнән бары баш хәрефләрне генә саклап, сүзнең һәммә урынында шул хәрефләрне йөртү (Мәннан Рахманкулов[3],

---

[1] Журнал сәхифәләренең тарлыгы сәбәпле мәсьәләнең тарихына күп туктала алмыйбыз. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Тәфсыйлатын – җентекләүләрен, аңлатуларын.

[3] Габделмәннан Әхмәтҗан улы Рахманкулов (1858–1908)–мөгаллим, 1890–1908 елларда Казанда «Борадәран Кәримовлар» типографиясендә конторщик, идарәче була, җиңеләйтелгән татар хәрефләре проектының авторы.

Г. Алпаров[1], Һади Максуди[2], Г. Шәрәф вә башкалар тәкъдимнәре. Бу әсас хәзер Татарстанда рәсми уларак кабул ителгән һәм гамәлгә куелып ята). Мисаллары – басмада: *Татарстан хөкүмәте хәрефләрне дүртдән бергә калдырырга карар бирде.* Язмада: *Татарстан хөкүмәте хәрефләрен дүртдән бергә калдырырга карар бирде*[3].

2. Гарәп хәрефләренең ялгыз шәкелләрен алып, шуларны гына калдыру (Әхмәджан Мостафа, Гыймад Нугайбәк[4], Шаһтәхтинский[5], Истанбул «нәшере – мәгариф җәмгыяте» тәкъдимнәре). Мисал – басмада:

ت ا ت ا ر س ت ا ن ح و ک و م ه ت ئ / *Татарстан хөкүмәте* кебек.

Бу тәкъдим тарафдарларыннан кайсылары язуда да шулай язарга тәкъдим итәләр. Кайсылары язуны бөтенләй элеккечә саклыйлар.

3. Гарәп хәрефләренең төп сызыкларын калдырып, шәкел ягыннан аларны латинлаштыру, урыс, латин хәрефләре кебек асты-өсте тигез һәндәси[6] шәкелләргә ошату (Харитонов[7], борадәран Рәмиевләр[8], Мостафа Собхи[9] тәкъдимнәре).

---

[1] Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров (1888–1936) – профессор, күренекле тел галиме, хәзерге татар грамматикасына нигез салучыларның берсе.

[2] Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди (1868–1941) – күренекле татар мөгаллиме, җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм нашир.

[3] Язуда рокга язуы алга сөрелә. Аның хәрефләре матбагада булмаганга, без яңа хәрефләрнең язуда ни рәвештә булачагын күрсәтер өчен, аерым ялгыз шәкелләрен генә ташлап, иске матбага хәрефләре белән генә файдаланабыз, гомумән язуның үзгәрүе сүз актыгындагы хәрефләрендә генә булачак; чөнки безнең элекке язуыбызда да баш хәрефләр белән урта хәрефләрнең аермасы урта хәрефләрнең язуны тизләтү өчен булган алдагы ялгау сызыгында гына иде. Тиз язуда бу мондан соң да шулай сакланачак. *(Г. Шәрәф иск.)*

[4] Гыймадетдин Шәрифҗан улы Нугайбәк (1881–1943) – тел галиме, журналист.

[5] Шаһтәхтинский Мөхәммәд Солтан улы, – кавказлы җәмәгать эшлеклесе, Тифлистә 1903–1904 елларда азәрбайҗан телендә чыккан «Шәркы рус» газетасы мөхәррире.

[6] Һәндәси – геометрик.

[7] Иван Николай улы Харитонов (1859–1927), матбагачы, нашир, Харитонов матбагасы басмаханәсенең оештыручысы һәм хуҗасы; татар китапларын нәшер итүгә, татар (гарәп) шрифтларын камилләштерүгә зур өлеш кертә.

[8] Татар тарихында зур урын тоткан, сәүдәгәрләр нәселеннән булган бертуган Мөхәммәтшакир (1857–1914) һәм Мөхәммәтзакир (1858–1921) Рәмиевләр.

[9] Мостафа Собхи (1882–1921) – төрек революционеры, 1915 елда – большевиклар партиясендә, Октябрь инкыйлабыннан соң – Мәскәүдә, Казанда, Кырымда, Ташкентта партия эшендә, Үзәк мөселман комиссариаты эшчәнлегендә актив катнашкан.

Боларның хәрефләре матбагада булмаганга мисал китерә алмыйбыз[1].

4. Керәшеннәрдәгечә урыс хәрефләрен кабул итү тәкъдиме (иске хөкүмәтнең 31 март кагыйдәләре, үз арабыздан кайбер тәкъдимнәр, кыргызларда Алтынсарин[2] вә башкалар). Мисаллар – басмада: Татарстан Хокюмяте, язмада: *Татарстан Хокюмяте[3]*.

5. Латин хәрефләрен кабул итү тәкъдиме (Төркия, Азәрбайҗандагы электән килгән кайбер тәкъдимнәр, бездә Сәгыйд Рәмиев[4], Н.Хәким[5] вә гайреләренең тәкъдиме Азәрбайҗан хөкүмәте тарафыннан ним[6] – рәсми уларак танылган һәм бәгъзе бер әсәрләрдә аларда гамәлгә куела башлаган тәкъдим).

Мисаллар – басмада: *Tatarstan Hokuməte hərflərе[7]*.

Хәрефләрне сайлауда нинди әсаслар алынырга тиеш?

Хәрефләрне сайлауда һәм аларны ислахта төрле агымнардан кайсын алда тотуны билгеләргә уңай булсын өчен, бу мәсьәләдә нинди әсаслардан чыгып һәм нинди уңайлашуларны күздә тотып тикшерергә кирәк икәнен әйтеп үтик.

Хәрефләр – бер кешенең фикерен башкаларга кәгазь аркылы авазларның шартый[8] сурәтләрен төшерү ысулы белән белдертү өчен бер васита – бер корал гына.

Коралларга уңайлык, яраклылык ягыннан бәһа куюда «хезмәтне фәнни әсаста оештыру» методлары истигъмаль ителә. Бу методның әсасы – бер эшне эшләү, йә бер корал белән файдалану ысулларын тикшергәндә, гамми әһәмияте булган моментларга гына тукталудадыр: кечкенә генә бер хәрәкәт, миллионнарча кешеләр тарафыннан,

[1] Теләгән кешеләр Рәмиевләрнең, Харитоновның бу тугрыдагы махсус нәшер иткән әсәрләренә мөрәҗәгать итәрләр. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Ибрай Алтынсарин (1841–1889) – язучы, педагог-мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, рус графикасы нигезендә казакъ текстларын язу өчен әлифба вариантларын уйлап табучы.

[3] Кириллицада бирелгән.

[4] Сәгыйть Рәмиев (1880–1926) – күренекле татар шагыйре, мөгаллим, публицист.

[5] Нигъмәтулла Гыйниятулла улы Хәкимов (Нигъмәт Хәким, 1899–1937) – тюрколог, тел белгече.

[6] Ним – ярты, ярым.

[7] Латин графикасында бирелгән.

[8] Шартый – шартлы.

миллионнар мәртәбә тәкрар[1] ысулы белән бик күпкә җыелганга, шундый гамми әһәмияте булган хәрәкәт, уңайлык йә уңайсызлыкларга бу методта зур әһәмият бирелә; гамми булмаган йә күп мәртәбә тәкрарлануына ихтыяҗ булмаган моментларга әһәмият бирелми. Без дә бу уку-язу коралын (хәрефләрне) сайлаганда, аларга бәһа куйганда шушы хезмәтне фәнни рәвештә төзү әсасларыннан караячакбыз. Соң бу корал нинди таләпләргә җавап бирергә тиеш? Хәреф – уку-язу, матбугатны мәйданга китерү коралы. Бу коралның нинди системадагысы тизрәк уку, тизрәк язу өчен уңайлырак булса, нинди системадагысы гамми табигатьтәге матбугатны күбрәк вә арзанрак таратырга имкян бирсә, шул системадагы коралны без алдарак күрергә тиешбез. Хәрефләргә булган таләпләрне тәфсилләп карыйк:

1. Хәяттә, кемгә генә булмасын, язуга караганда укырга күбрәк туры килә. Шуңа күрә хәрефләр, бигрәк тә алардан төзелгән сүзләр һәм сәтырлар (юллар) – кул белән язган булса да, басылган булса да, иң беренче нәүбәттә уку өчен уңай, мөмкин кадәр тизрәк уку (уку агымын тизләтү) өчен яраклы булырга тиеш.

2. Хәзерге вакытта фикернең иң күбесе матбагада басу юлы белән тарала. Безнең хәрефләр белән иң күп файдалануыбыз гәзит, журнал, китаплар, гомумән, басылган нәрсәләрне уку юлы белән була. Шуңа күрә хәрефләр матбага техникасы (хәреф кую, җыю, басу) якларыннан мөмкин кадәр уңайлырак булырга тиешләр. Шуның белән бергә, басылган сүзләрнең, билгеле, беренче маддәдә күрсәтелгән уку өчен уңайлыкка зарар итмәү шарты белән, мөмкин кадәр әзрәк урын алырлык булулары һәм басылган әсәрләрнең шуның аркасында кәгазь, матбага мәсарифләре[2] ягыннан арзанрак төшәрлек булулары матлуб[3].

3. Матбага ысулыннан тыш безгә хәрефләр белән, язу ысулы белән файдаланырга туры килә. Бердән язу – һәркемнең көндәлек хәяты өчен кирәк булса, гамми әһәмияте булган, мөәссәсәләрдә[4] эш йөртү, тәхрир[5] эшләре өчен дә ул әһәмиятле. Шуңар күрә хәреф

[1] Тәкрар – кабатлау.
[2] Мәсарифләре – чыгымнары.
[3] Матлуб – таләп ителгән.
[4] Мөәссәсәләрдә – оешмаларда.
[5] Тәхрир – рәсми кәгазь, хат.

сайлау эшендә уку, матбага өчен уңай булу белән бергә язу өчен уңай, мөмкин кадәр тиз языла ала торган булуыны да күз алдында тотылырга тиеш.

4. Хәреф сайлау эшендә дүртенче әсас – өйрәнү (укыту) өчен уңайлык мәсьәләседер. Халкыбызның дүрттән берсе дә укый-яза белмәве, яңадан-яңа туып үскән балаларны өйрәтергә мәҗбүрият булуы бу якларның әһәмиятен күрсәтә. Шулай да хәреф таныту, укырга-язарга өйрәтү заманы һәркемнең гомереннән берничә айны гына алып, уку-язу белән шөгыльләнү, файдалану гомер буена барганлыктан, билгеле, өйрәнү өчен тизлекнең әһәмияте, укуязу өчен тизлекнеке кадәр түгел. Кайбер кешеләрнең имля-хәреф мәсьәләләренең хәлендә, өйрәтү өчен тизлеккә югарыда саналган мәсьәләләрдән дә артыграк әһәмият биреп, мәсьәләгә, гарәпләр әйтмешли, «Мөгаллими сыйбьян (Балалар укытучы)» күзлегеннән генә караганлыкларыннан, без бу ноктага туктап үтәбез. Хәрефләр сайлаганда, аның язма хәрефләре басма хәрефләреннән ерак булмау мәсьәләсенә дә әһәмият бирергә кирәк. Бу, бердән, балаларга хәреф таныткканда: басканда болай була, язганда болай була дип, бер үк хәрефнең басма вә язмадагы шәкелләрен аерым-аерым өйрәтергә туры килмәсен өчен, икенчедән, тиз укуга мәләкәләнүдә[1], басылган текстны укуда эшләнгән мәләкә, язылган текстны уку өчен дә ярасын өчен әһәмиятле.

5. Мәдәни яктан бер-берсенә катышуда булган халыкларның, бигрәк тә аларның телләре дә бер-беренекенә якын булса, берендә чыккан матбугат, язмалар белән икенчеләре дә файдалана алсын өчен, хәрефләре дә уртак булуына тырышырга кирәк.

6. Хәрефләр, язу – халыкның хәятында, сәнаигы нәфисәнең төрле бабларында зур урын тотканга, аларның тышкы күренешендә дә мөмкин кадәр матуррак булуы матлуб.

Хәрефләрне сайлауда югарыдагы таләпләр әсас итеп алынырга тиеш. Фикеребезчә, бу әсаслар әһәмият ягыннан шул күрсәтелгән тәртиптә куелырга тиеш.

Бер халыкның әлегә чаклы төпле язуы, әдәбияты, әһәмиятле санда язулы (грамотный) кешеләре булмаса, аңарга, югарыда куелган әсаслардан чыгып, «менә дигән» хәрефләр төзеп бирергә ярый. Ләкин бер халыкның инде урнашып җиткән хәрефләре, шул

[1] Мәләкәләнүдә – өйрәнүдә.

хәрефләр белән язылган, басылган күзгә алырлык әдәбияты, шул хәрефләрне белгән, һәм шулар белән файдаланган әһәмиятле санда язулы халкы булса, ул вакытта мәсьәлә шактый читенләшә һәм үзгәрә. Бу вакытта аларга иске хәрефләре урынына тәкъдим ителә торган хәрефләр элеккеләренә караганда бик зур мадди, мәгънәви уңайлыклар, күзгә алырлык файдалар китерерлек булганда гына кабул ителүе мөмкин. Вак-төяк уңайлыклар, гамми әһәмияте булмаган кечкенә мадди йә мәгънәви файдалар өчен генә, аның әлегә чаклы булган бөтен әдәбиятын сеБереп түгәргә, бөтен язулы халкын, язусыз (неграмотный) итеп, матбугаттан аерырга, бер системадагы хәрефләр белән ясалган уку агымын, тиз уку мәләкәсен юкка чыгарып, яңа системадагы хәрефләр белән язылган сүзләр өчен тиз уку мәләкәсе ясарга керешү кебек эшләр. Яңадан бер кат әйтәбез, кертелгән үзгәрешләрнең гамми файдасы булмаганда, бу эшләр белән шөгыльләнү, хәятка керә алмый торган һәм керергә хаккы да булмаган эшләр белән шөгыльләнү булачак. Алмаштыру, төзәтүләр чыннан да әһәмиятле, кулга-күзгә алырлык файдалары булганда. Билгеле, киреләнеп, консерваторланып торырга туры килми.

Әлегә чаклы язуы, әдәбияты булмаган эскимос, бурятларга хәреф сайлау йә төзү белән язулы, әдәбиятлы бер халык өчен хәреф сайлау-төзәтүдә бер үк юлдан барырга, бу мәсьәләләрне бер баскычка куярга туры килми. Югарыда күрсәтелгән әсасларны хәтердә тотып, без дә хәрефләрне төзәтү йә алмаштыру турысында булган тәкъдимнәрне тикшерергә, чагыштырырга керешәбез.

### ***Хәрефләр ислахы мәсьәләсендәге төрле тәкъдимнәрне чагыштыру***

Югарыда, бездә хәреф сайлау, төзәтү мәсьәләсендәге агымнарның биш әсасын тәкъдимгә кайтып калганын күрсәткән идек:

1) әсасан, гарәп хәрефләрен алып, аларның баш шәкелләрен генә саклау;

2) гарәп хәрефләренең ялгыз шәкелләрен генә саклау;

3) гарәп хәрефләрен латин стилендәге шәкелләргә әйләндерү;

4) латин хәрефләрен кабул итү;

5) урыс хәрефләрен кабул итү.

Бу биш тәкъдимнән хәзерге вакытта гамәли әһәмиятле итеп ике тәкъдимне алырга туры килә. Берсе, Татарстан хөкүмәте та-

рафыннан рәсми танылганы – гарәп хәрефләренең сүз башындагы шәкелләрен әсас итеп алып, басмада хәрефләрне бергә калдыру, язманы да шуңа якын китерү тәкъдиме; икенчесе – бездә дә азмаз тарафдарлары булган, Азәрбайҗан хөкүмәте тарафыннан ним[1] рәсмият дәрәҗәсен алган гарәп хәрефләрен бөтенләй ташлау һәм алар урынына латин хәрефләрен кабул итү тәкъдиме. Түбәндә, без бу ике тәкъдимне һәм аларның әсасларын чагыштыруны нигез итеп, башка тәкъдимнәргә, хәзерге көндә гамәли әһәмиятләре булмаганлыктан, кыскача гына тукталып үтәбез.

**Басма текстны уку өчен тизлек ягыннан** – латин хәрефләре күбесенчә: *m, n, u, k, c, e, a, x, r, s, z, o*[2] кебек асты-өсте тигез сызыклар эчендә торган шәкелләрдән гыйбарәт, кайберләрендә генә *y, p, t, l, h, d, i, b*[3] кебек бу сызыкларның тышына чыгып, йә өсткә күтәрелгән, йә астка төшкән сызыклар, нокталар арттырылган.

Латин хәрефләре әсасына озынча-дүртлек (прямоугольник) шәкеле алынып, гомумән хәрефләрне бер-береннән аерыр өчен шул дүртлек эчендәге сызыкларны төрләндерү, йә аларга *«q, d, d, o»*[4] хәрефләрендәге кебек койрыклар арттыру әсасы алынган: боларда сызыкларның күбрәге туры сызыклар.

Татар хәрефләре ب / *би),* ح / *хи,* ر / *рә,* د / *дәл,* س / *син,* ک / *кәф,* ف / *фи,* ل / *ләм,* ہ /*ә,* ع / *гайн,* و / *waw,* ه / *hи* кебек берничә генә әсаси шәкел алынып, хәрефләрне төрләндерү – шул шәкелләрнең генә, астына, өстенә нокталар, галәмәтләр арттыру юлы белән ясалган (ب, ئ, پ, ت, ن, ى , ئ; ح, ج, چ, ک, گ, ڴ; ر, ز, ژ ; و, ۇ , ۋ кебек). Татар хәрефләренең әсаси шәкелләре дә, арттырылган нокта вә галәмәтләре дә латин хәрефләрендәге кебек ике сызык арасына сыеп тигезләнеп тормыйлар. Берсе күтәрелеп, берсе төшеп тора. Төп шәкелләрдә дә ярдәмче галәмәтләрдә дә латин хәрефләрендәге кебек туры сызыкларгарак корылмый, кәкре (кривой) сызыкларга һәм түгәрәкләнүгә маил[5] сызыкларга корылган.

Уку агымын (процесс чтения) җентекләү күрсәтүе буенча, грамотный кеше сүзләрне укыган чакта, һәрбер хәрефне аерым-аерым

---

[1] Ним – ярым.
[2] Латин графикасында бирелгән.
[3] Латин графикасында бирелгән.
[4] Латин графикасында бирелгән.
[5] Маил – тартым, авыш.

карап, аларның нинди авазга йөргәнен тикшереп, шуларны кушу ысулы белән хәрефләп (по буквам) йә иҗекләп (по слогам) укымый, бәлки бер сүзне тәшкил иткән, беррәттән торган хәрефләрне күрә дә, аларның нинди мәгънәгә, нинди сүзгә йөргәнен бөтен сүзнең гомуми сурәтен күрү белән танып ала. Урамда берәр танышыбызны очрату белән, без аның алдан борынын, күзен, аерым әгъзаларын карап түгел, барысын бергә җыеп, гомуми күренешеннән үк таныганыбыз шикелле, укыганда да بالتا / *балта* йә *топор* дигән сүзнең гомуми сурәтен күреп, без бу сүзне электә дә күп мәртәбәләр шушы төстә язылган итеп күргәнлегебездән, күптәнге танышыбызны очраткан кебек, сүзне күрү белән таныйбыз[1].

Уку агымын төрле кораллар вә тәҗрибәләр белән тикшергән галимнәр бер-бер текстны укыганда аерым-аерым сүзләрне тану өчен, ягъни сүзләрне бер-береннән тизрәк аеру өчен, өсткә йә астка чыгып торган койрыклы йә галәмәтле хәрефләрнең күп файдасы булганын тапканнар. Безгә урамда очраган танышларыбызның сакалы, мыегы зуррак булу, буендагы йә киемендәге күзгә бәрелә торган берәр аерымлык аны башкалар арасындаерактан һәм җиңелрәк танырга ярдәм иткән кебек, сүзне тәшкил иткән хәрефләр арасында да, төрле рәвештәге койрыклы, нокталы, йә башкача, гомуми сызыклардан чыгып тора торган кисәкләре булуы, сүзләрне тануны, ягъни уку агымын тизләтә.

Латин хәрефләре өстендә уку агымы кануннарын тикшергән немец профессоры Мейман[2], латин хәрефләре белән язылган бер сүздә *«i, a, o, t, b, h, p, l»*[3] кебек басма юлының өстенә, астына чыгып торган койрыклы йә галәмәтле, нокталы хәрефләре, *«n, m, o, a, s, x, c»*[4]

[1] Соңгы вакытларда көннән-көн үзенә күбрәк тарафдарлар ала торган әлифба укытудагы «бөтен сүзләр» [Америка] ысулы шушы уку агымы канунына корылган, бу канунны без һәркөн гәзитә укыганда да сизә алабыз. Мәсәлән, без «قول باش» дигән сүзләрне иске хәрефләр белән шул күрсәтелгән шәкелдә күреп өйрәнгәнбез; хәзер гәзиттә без бу сүзләрне яңа хәрефләр белән «قول باش» рәвешендә күргәч, без моның аерым хәрефләрен яхшы танысак та, әлегә чаклы бу сүзләрне «кул, баш» шәкелләрендә генә күреп өйрәнгәнлегебездән, бу «киемен алыштырган» танышларыбызны, тиз генә танып ала алмыйбыз. Шушы сәбәпләрдән күз өйрәнгәнчегә кадәр яңа хәрефләр белән басылганны уку авыррак була. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Эрнст Фридрих Вильгельм Мейман (1862–1915) – немец педагогы һәм психологы, эксперименталь педагогикага нигез салучылардан берсе.

[3] Латин графикасында бирелгән.

[4] Латин графикасында бирелгән.

кебек тигез сызыклар эчендә генә торган хәрефләргә нисбәтән никадәр күбрәк процент тәшкил итсә, бу сүз шул нисбәттә тизрәк укыла, дигән карарга килгән[1].

Мейманның вә башка тәрбия галимнәренең бу тәҗрибәләрен без уку агымы ягыннан хәреф сайлау мәсьәләсенә истифадә итсәк[2], нокталы, тигезсез гарәп-татар хәрефләре белән басылган сүзләр, асты-өсте күбесенчә тигез булган латин йә урыс хәрефләре белән басылган сүзләргә караганда, уку агымы өчен уңайрак, тизрәк булырга тиеш. Тәҗрибәләр дә шуны күрсәтә. Мәсәлән, татарча да, урысча да басканны уку һәм аңлау өчен тигез чамада мәләкәсе (практикасы) булган бер үк кешегә 16 битле урысча һәм татарча китапны, йә бер үк әсәрнең урысча асылын һәм татарчага тәрҗемәсен укып чыгарга бирсәң, ул аның татарчасын 30–35 процент кадәр кимрәк вакыт эчендә укып чыкканын күрербез. Берничә кешеләр өстендә ясап караган тәҗрибәләребез бу әсасны тәэкид иттеләр[3]. (Бу тәҗрибәне һәркем үзе ясап карый ала. Билгеле, татарчаны да, урысчаны да тиз укый алмый торган, йә начар аңлый торган кешеләр, мондый янәшә – параллельный – тәҗрибәләр өчен ярамыйлар).

Тигез торган һәм бер-беренә бик ошаган *и, п, н, ц, д, т, г, ш, щ*[4] кебек хәрефләрнең күп булуы, сүзләрне бер-беренә ошатып, уку агымын авырайтканга, һәм боларга караганда урысның курсивындагы *и, п, н, ц, д, т, г, ш, щ* хәрефләре бер-береннән күбрәк аерымлы булганга, урыс тел-хәреф мөтәхәссисләре[5] арасында басма өчен гомумән курсивны кабул итүне һәм хәзерге урыс басма хәрефләрен бөтенләйгә ташлау тәкъдимен кертүчеләр бар[6]. Язма хәрефләр белән басма хәрефләрне берләштергәнлектән, моның өйрәтү якларыннан да әһәмияте булачак. Немец, француз мөтәхәссисләре арасында да шундый фикерләр булуы Мейманның югарыда күрсәтелгән

[1] Мейманның вә Торндайк үз тәҗрибәләре һәм башка тәрбия галимнәре тәҗрибәләре турында «Лекции по экспериментальной педагогике» дигән әсәренең 3 нче җилдендә 14–15 нче лекцияләрен кара. Урысчага тәрҗемәсе берничә мәртәбәләр басылган. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Истифадә итсәк – файдалансак, куллансак.

[3] Тәэкид иттеләр – расладылар.

[4] Кириллицада бирелгән.

[5] Мөтәхәссисләре – сизүчеләре, хис итүчеләре.

[6] Бу турыда профессор Томсонның түбәндәге әсәрен кара: *Томсон А.И.* К теории правописания. С. 216–217, 228. *(Г. Шәрәф иск.)*

әсәрендә һәм профессор Лазурскийның[1] «Инглизләрдә, французларда һәм немецларда имля мәсьәләсе» дигән әсәрендә күренә.

Латин әсасындагы хәрефләрнең уку өчен гарәп хәрефләренә караганда авыррак булуларын тагын түбәндәге тәҗрибәләрдән дә белергә мөмкин:

1) урысча да, татарча да басылган әсәрләрне күп укырга туры килә торган кешеләргә, урысча басылганны укыганда, татарча басылганны укыгандагыга караганда күз тизрәк арыганын тәҗрибә итәргә мөмкин;

2) урыс хәрефләре белән басылган китап йә гәзитәне укыганда, матбагада әз генә пычрак чыкты исә, бөтенләй сүзләре танылмаслык хәлгә килгәнен күрәбез. (Сугыш һәм бөлгенлек аркасында хәрефләр искереп, басу каралары начарланганга, без моны һәркөн укыган урысча гәзитәләребездә күреп барабыз.) Татар матбагалары хәреф, кара ягыннан урыс матбагаларыннан алда булмаса да, татарча басылган гәзитәләрдә безгә буялудан, кара начарлыктан аерым сүзләрнең укымаслык хәлгә килүен сирәк очратырга туры килә. Моның да сәбәбе – татар (гарәп) хәрефләренең тигез юллар эчендә генә тормыйча, тигезсез һәм нокталы хәрефләрдән гыйбарәт булуында, урысча хәрефләрнең әз генә игътибарсыз басу белән бер-береннән аерылмаслык хәлгә килүләрендәдер. Бу хәл хәрефләрнең шәкелләрендәге әсастан килә. Шуңа күрә бу сүзләрне урыс, латин хәрефләренә кыяс иткән[2] кебек латинлаштырылган гарәп хәрефләренә дә кыяс итәргә мөмкин.

**Язма текстны уку ягыннан** – басма текстны уку турындагы сүзләрне, гарәп һәм латин әсасларындагы язма текстны уку өчен уңайлык турында да әйтергә мөмкин. Урысча язма текстны, хәрефләрнең бер-беренә ошавы сәбәпле, кеше язганны түгел, үзең язганны укыганда да тукталып-тукталып, читенлек белән укырга туры килә. Татарча кульязмаларны укыганда без бу хәлне бик сирәк очратабыз; күбесенчә һәркем язганны җиңел укып була. Һәркем хәятында бик күп тәҗрибә ителгән бу мисал, язма текстны уку ягыннан да, ноктала, тигезсез хәрефләрнең латин әсасындагы хәрефләрдән уңайрак, алдарак икәнен күрсәтә.

---

[1] Александр Федорович Лазурский (1874–1917) – табиб, психолог.
[2] Кыяс иткән – ошаткан.

**Язу тизлеге ягыннан** – латин әсасында булган хәрефләр сулдан уңга таба языла; һәм кул өчен күбрәк «авод»[1]дагы кебек сәгать теле юнәлешенә каршы булган хәрәкәтләрдән, әйләнмәләрдән гыйбарәт. Татар язуы уңнан сулга таба языла һәм күбрәк сәгать теле юнәлеше буенча булган хәрәкәт вә әйләнмәләрдән гыйбарәт. Юлның уңнан сулга йә сулдан уңга булуы язу тизлеге өчен әһәмиятсез. Ләкин язудагы бик күп санда булган вак хәрәкәтләрнең юнәлеше, гомумән алганда, язу тизлегенә тәэсир итә. Безнең кул, беләк сеңерләребез өчен сәгать юнәлеше буенча булган хәрәкәтләр уңайлырак һәм тизрәк. Шуңар күрә кул белән әйләндерә торган төрле машиналарны, винтларны, ачкычларны, сәгать теле юнәлеше белән әйләндерергә ясала; кул белән тегү-чигү дә, баулар-арканнар ишү дә кул хәрәкәте өчен шул сәгать теле юнәлеше алынган[2]. Бу юнәлештәге хәрәкәт адәмнең табигатендә элек-электән уңайрак, тизлеклерәк юнәлеш булып урнашкан. Димәк, гарәп хәрефләре әсасына кул өчен табигыйрәк тизрәк булган хәрәкәт куелган.

Татар язуы – вак кәкреләрдән (кривойлардан), күп вакытта тиз язуда дулкыннардан (зигзаглардан) гыйбарәт; урыс-латин язуы – зур кәкреләрдән, һәркайсын каләм белән сызар өчен күбрәк вакыт һәм энергия ала торган сызыклардан гыйбарәт.

Моның өстенә, бер үк сүзне без латин әсасындагы хәрефләр белән һәм гарәп хәрефләре белән язып карасак, (гарәп хәрефләрендә нокталарны, нокта кую һәм сүз арасындагы өзекләр өчен каләмне кәгазьдән аеруларны аерым хәрәкәтләргә санаганда да) гарәп хәрефләре белән язылган сүздәге хәрәкәтләрнең гомуми саны, латин әсасындагы хәрефләр белән язгандагыга караганда кимрәк булганын күрәбез. Мәсәлән, рокга белән йә латин һәм урыс хәрефләре белән бер үк сүзләрне язу өчен кирәк булган хәрәкәтләрне санап карасак, латин әсасындагы хәрефләрдә хәрәкәт саны, гомумән алганда, 30–40 процент артыграк икәнен табарбыз. Мисалга:

Рокга[3] белән: بالتا, شینبه, بارا ; урысча: *балта, шинбя, бара*; латинча: *balta, sinbə, bara* сүзләрен язып, әсаси кул хәрәкәтләрен (импульсларны) санарга мөмкин. «Балта» сүзен язар өчен рокгада 7 әсаси

[1] Кириллицада бирелгән.

[2] Кул машинасын кирегә әйләндерә башласак, без кулыбыз бик тиз талганны күрербез. (*Г. Шәрәф иск.)*

[3] Рокга – гарәп язуының каллиграфик бер төре.

хәрәкәт, латинда 13 хәрәкәт, урысчада 13 хәрәкәт кирәк икәнен күрәбез. Бу күрсәтелгән әсаслар һәммәсе язуның тизлегенә тәэсир итәләр.

Бу нәзарияләрне түбәндәге тәҗрибә белән, гамәли рәвештә дә тәэкид итәргә[1] мөмкин: мәсәлән, урысча да, татарча да язуга бер чамарак мәләкәсе булган кеше кулына минутлыклы, сәгать алып, ярты минут эчендә, алдан урыс хәрефенең иң тиз язу өчен йөртелгән кыек курсивы белән: *балта, балта, балта; топор, топор, топор*[2] дип бер сүзне язып тора: шулай ук ярты минут эчендә рокга белән: балта بالتا, بالتا, بالتا , йә تاپور, تاپور, تاپور дип язып тора. Аннан соң ярты минут эчендә бер үк сүзне татар хәрефе белән ничә мәртәбә язганын һәм урыс йә латин хәрефе белән ничә мәртәбә язарга өлгергәнен санап карый. Һәр ике әсастагы хәреф белән язарга мәләкә тигез булганда без, татар хәрефләре белән бер үк вакытта язылган сүзләрнең саны, урыс хәрефләре белән язганга караганда 30–40 процент күбрәк булганын күрербез. Латин әсасындагы хәрефле халыкларда да тиз язу өчен сызыклары ягыннан гарәп хәрефләренә ошаган стенография язуларын истигъмаль итү дә моны күрсәтә. Төркиядә һәм Русиядә революция вакытындагы төрле съездларда рокга хәрефләренең үзгәртүсез үк стенограммалар язып бару өчен яравы турысындагы тәҗрибәләр, урыс йә латин хәрефләре турында моны уйларга да мөмкин булмавы да югарыда сөйләнгән сүзләрне тәэкид итә.

Димәк, гарәп әсасындагы хәрефләр, тиз язу ягыннан, латин әсасындагы хәрефләрдән күп югары торалар.

Ялгыз хәрефләр ляихәсе[3] (*җир* / جير сүзен «ج ى ر» рәвешендә язу тәкъдиме), тиз язу ягыннан, тәнкыйтьтән түбән; гарәп хәрефләрен латинлаштыру ляихәсе турында да шуны әйтергә туры килә.

**Матбага техникасы ягыннан** – латин хәрефе системасын алган халыкларда матбага хәрефләре *Aa, Bb, Cc, Dd, Ee* рәвешендә һәр хәреф ике шәкелдә йөри. Боларның олылары – җөмлә, шигырь башларында һәм хосусый исемнәрдә, кечкенәләре – башка һәммә урыннарда йөртелә. Латин системасын тәкъдим итүчеләр безгә дә аны шушы хәлендә, һәр хәрефкә икешәр шәкелле итеп кабул итәргә

[1] Тәэкид итәргә – расларга.
[2] Журналда кириллицада бирелгән.
[3] Ляихәсе – проекты, тәкъдиме.

тәкъдим итәләр. Димәк, без, латин системасын алган сурәттә, дүрт шәкелдән качып, ике шәкелгә күчсәк, Татарстанда кертелмәктә булган татар хәрефләрен алсак, дүрт шәкелдән бер шәкелгә күчәбез. (Һәр хәрефнең шәкеле бер генә булуның әһәмияте мәкалә башында кыскача әйтелгән иде. Бу турыда алда озынрак туктарбыз.) Латин хәрефләрендә баш (заглавный) хәрефләрнең аз истигъмале мәсьәләне үзгәртми, чөнки матбагада хәреф кассасында, язу машинасы бармак басмалары арасында барыбер һәр ике шәкелне булдырырга, балага хәреф танытканда һәр ике шәкелне аерым-аерым танытырга мәҗбүрбез.

**Язу машиналарына кую ягыннан карасак,** хәзерге бер шәкелгә калдырылган татар хәрефләрен шәкел әзлеге аркасында 90 бармаклы машинага ике кегль (мәсәлән 14 нче кегль юка һәм калын хәрефләрне) куярга мөмкин; урыс һәм латин хәрефләрен исә, заглавный шәкелләре булу аркасында, бер генә кегль куярга мөмкин. Соңгы вакытта Мәскәүдә һәм Татар җөмһүриятендә эшләнгән тәҗрибә вә ляихәләр башка яклардан да татар хәрефләрен язу машинасына куярга мөмкинлеге күренде.

**Икътисади яктан** – латин, урыс хәрефләренең уртача киңлеге 6 шпон булып, яңа татар хәрефләренең уртача киңлеге 4 шпоннан кимрәк. Димәк, бер юлга хәрефнең сыешы татар хәрефләрендә 30–40 процент артыграк була. Кегль ягыннан да, яңа татар хәрефләре, ج – م – ع ләрнең койрыклары булмау, ا – ک – گ ләрнең өстке сызыклары кыскартылу аркасында гәзит, китап текстлары өчен йөри торган хәрефләрне 12 нче кегльгә сыйдыруны кабилдер[1] (хәзер шундый хәрефләр эшләнеп яталар). Димәк, хәзер истигъмальгә кергән 14 нче кегль хәрефләр, латин йә урыс хәрефләренә караганда 15–20 процент кадәр кимрәк урын ала торган булса, шул ук 14 нче кегльнең нормалы (ягъни 12 нче кегльгә каратып эшләнгәне) урыс-латин хәрефләренә караганда 35 процентлар кадәр урын әзрәк алачак, шул нисбәттә, һәр басылган китап, кәгазь, кара, басу, төпләү, почта мәсарифе якларыннан арзангарак төшәчәк. 35 процент кадәр аерманы нәшрият вә мәктәп эшләре өчен кечкенә аерма дип карарга туры килми. Бу билгеле микъдарда мәсариф тотып, бер үк зурлыктагы 100 китапмы, 65 китапмы бастыру, дигән сүз була.

[1] Кабилдер – кабул итәчәкләр.

**Өйрәнү-укыту өчен җиңеллек ягыннан** – латин әсасындагы хәрефләрне алсак, аларны таныткандa, һәр хәрефнең басмадагы ике шәкелен *Aa, Bb, Cc, Dd, Ee* һәм язмадагы ике шәкелен *Aa, Bb, Cc, Dd, Ee*, димәк, бер хәрефкә бер-береннән сурәт ягыннан шактый аермалы дүрт шәкел күрсәтергә мәҗбүр булабыз. Язма хәрефләрнең басма хәрефләрдән шактый аермалы булуы урыс һәм гарби Аурупа тәрбиячеләрен, укуны алдан өйрәтергәме, язуны алдан өйрәтергәме, икәвен дә бергә алып барыргамы кебек төрле нәзария вә читенлекләр тудыруы, ибтидаи тәгълим нәзариясе белән шөгыльләнгән кешеләргә мәгълүм. Болар шул әсастан чыгып, югарыда әйтелгәнчә, басма хәрефләрен бөтенләй ташлап, матбага өчен дә курсив алуны тәкъдим итүгә кадәр баралар.

Ислах ителгән татар хәрефләрендә исә без бер хәрефкә бер шәкел танытабыз да, шул басмага да, язмага да ярый. Тиз язуда (рокгада) урта шәкелләр керсә дә, болар латин заглавный хәрефләре кебек шәкел ягыннан баш хәрефләрдән аерылмыйлар, бары тиз язу өчен, арттагы хәрефне алдагы хәрефкә кушудагы каләмнең табигый хәрәкәтеннән генә гыйбарәт. Бу кушу сызыгы латин әсасындагы хәрефләрдә дә бар.

Язма хәрефләр белән басма хәрефләрнең бертөрле булуы, язган һәм баскан текстларга аерым-аерым уку мәләкәләре ясарга ихтыяҗ булмавы өчен дә әһәмиятле. Өйрәтү ягыннан ялгыз хәрефләр (*җир* / جیر урынына басмада да, язмада да ج ی ر язу) ляихәсе яхшы булса да, бу ляихәнең бөтен хасияте шунда гына булып, язу тизлеге һәм икътисади яклардан ляихә тәнкыйтьтән түбән булганга, аңга туктап тормыйбыз.

**Башка халыкларга якынаю мәсьәләсе.** Язуда ике төрле әсас бар. Берсе бөтен мәгънәне бер галәмәт белән күрсәтү (идеография): хисаптагы 1, 2, 3, +, –, ×, % галәмәтләре, һәндәсәдәге (Пи, е, радиус), химиядәге C H галәмәтләре, сәгатьтәге I, II, III цифрлары, язудагы тыныш тамгалары (? ! ; ,), һәйәттәге кояш, ай галәмәтләре кебек. Бу галәмәтләрнең һәрберсе мәгълүм бер мәгънәне аңлата; мәсәлән, сан күрсәткән 2 галәмәтен татар – *ике* дип, урыс – *два*, немец – *цвай*, француз – *ду*, чуаш – *викке* дип укый. Галәмәт авазларны күрсәтми, мәгънәне генә күрсәткәнгә, кем тарафыннан гына язылган булмасын, аны шул галәмәтне белгән һәр халык кешесе мәгънәне үз телендәге авазлар белән әйтеп укый ала. Бу галәмәтләрнең байтагы

акча исәбе, сәгать кебек гамми һәм бәйнәлмиләл[1] гамәли әһәмияте булган нәрсәләрдә истигъмаль ителгәнгә, һәммә халыкларда уртак булуы матлуб да. Шуңа күрә мәдәни халыкларда тел, хәреф аермасына карамый, бу галәмәтләрнең күбесе уртак булып киткән. Бу мәгънә галәмәтләренең[2] язу-укуда, гамәли уңайсызлык китермәгәннәре безнең хәятка дә кертелергә тиеш һәм кертелеп тә баралар.

Язуда икенче әсас – бусы мәгънәләргә әсасланмый, бәлки һәр телдәге сүзләрнең аерым авазларына әсаслана; һәм шул авазларның һәркайсы өчен шул халыкта кабул ителгән хәрефләр белән күрсәтелә. Мондый язуны аваз язуы йә хәреф язуы диләр. Мәсәлән, *2* мәгънәсен *«ике, ду, Deux, Zwei, Ике, Два, Викке»* хәрефләре белән язу кебек. *Ике* / ئیكى سүзе һәм хәрефләре турыдан-туры мәгънәне күрсәтмичә, авазлар җыентыгын гына күрсәткәнгә, шул авазлар җыентыгы бу телдә нинди мәгънәгә йөргәнен белмәгән кеше, хәрефләрен яхшы белсә дә, барыбер мәгънәне аңлый алмый. Шуңа күрә бу *ике* / ئیكى дигән сүзне гарәп, латин, урыс хәрефләреннән кайсы белән язсаң да, аның француз, урыс йә немец өчен аңлаешлылыгы бер дә артмый. Кайбер фәнни истыйляхлар[3], хосусый исемнәр һәм яңарак ихтираглар[4], бәйнәлмиләл исемнәр астында йөртелсә дә, гадәттә болардан да гаммә (масса) арасында истигъмаль ителгәннәре[5] һәм аның хәятында очрый торганнары бик аз сандалар. Шуның өстенә халыкның (бигрәк тә гаммәнең) сөйләшү, уку-язу телендә йөздән берен дә

[1] Бәйнәлмиләл – халыкара, интернациональ.

[2] Мәгънә галәмәтләре арасында R (радиус), h (биеклек), C (күмерләткеч – углерод) I, II, III (Рим цифрлары) кебек латинчадан алынганы да, 1, 2, 3 кебек төптә гарәплрдән алынганнары да, риязияттагы пи, миу, тау, сигма, дельта, альфа галәмәтләре кебек грекчадан алынганлары да, + % ? галәмәтләре кебек шартый рәвештә кулланганнары да бар. Бездә боларны кабул итүне «латинча формулалар кабул итү мәсьәләсе» дип йөртәләр. Бу ислах дөрест түгел; чөнки бердән, боларның h, R, C, %, 1, 2, V кебек формула булмый, аерым мәгънә галәмәте генә булганнары, бер вакытта да формулага керми торганнары күп; формулаларның, бөтен килеш алганда, язылу тәртипләре дә – әле безнең өчен өзелмәгән мәсьәлә; икенчедән, бу галәмәтләр хәрефләрдән генә гыйбарәт түгел, кергән хәрефләре дә латин хәрефләре генә түгел; шуңа күрә бу галәмәтләрне нә кайчандыр булган латин халкына, нәдә хәзерге латин язуына хәсир белән нисбәт бирергә әсас юк. Без бу мәсьәләне бәйнәлмиләл мәгънә билгеләрен (галәмәтләрен) кабул мәсьәләсе дип кенә йөртергә тәкъдим итәбез. *(Г. Шәрәф иск.)*

[3] Истыйляхлар – атамалар, терминнар.

[4] Ихтираглар – уйлап чыгарулар, яңа нәрсә уйлап табу.

[5] Истигъмаль ителгәннәре – кулланылганнары.

тәшкил итмәгән бәйнәлмиләл сүзләрнең төрле телләрдә сөйләнеше һәм имлялары – күбесенчә шулкадәр аермалы ки, хәтта бу халыклар бер хәрефләр истигъмаль итәләр икән, анда да бу йөздән берне тәшкил иткән бәйнәлмиләл сүзләрне, алар бер-берсенең язуларын да танып бетермәячәкләр. Латин хәрефләрен кабул итү татарларга латин, француз, инглиз, итальян, испаньел телләрен өйрәнүдә һәм бу халыклар тарафыннан татар телен өйрәнүдә җиңеллек ясаячак, ягъни әлифбасын яңадан өйрәнергә ихтыяҗ булмаячак. Ләкин бөтен татар гаммәсеннән ничә кешегә шул телләрне өйрәнергә туры килә? Һәм теге халыклардан ничә кеше татарча өйрәнә? Гамми күләмдә алганда, бу өйрәнүләргә күпме ихтыяҗ төшә? Башка бер телнең хәрефләрен танып чыгу ике-өч сабаклык (5–6 сәгатьлек) эш икәнен, бу эшнең телнең үзен өйрәнү өчен кирәк вакытның бик кечкенә бер кисәген генә алуын уйлаганда, бу мәсьәләнең әһәмияте тагын кечерәя. Татарларның җыелып утырган өлкәләрендә генә түгел, Себер, Эчке Русия кебек татарларның таралып утырган бөтен җирләрен алганда да, боларның кайсы кисәгендә латин хәрефе кабул ителгән халык белән татарларга гамми рәвештә катнашырга туры килә? Латин хәрефе гамми рәвештә фактта кабул ителгән җирнең Татарстанга иң якыны – моннан 3 мең чакрымдагы Польшадыр. Сәнәгать вә техникадагы нинди тәрәккыйләр бу 3 мең чакрымның аръягындагы халыклар белән безне гамми (массовой) сурәттә ихтилятка[1] мәҗбүрият йә имкян[2] бирәчәк. Вә бу мәҗбүрият булганда хәреф берлеге генә нинди уңайлыклар бирәчәк? Югарыда сөйләнгән язу-уку һәм икътисади уңайлыкларга рәгъмән[3] бөтен Азия, Африканың һәм Аурупаның Польшадан Шәрыктагы һәммә халыкларына без бу эштә үрнәк булып юл күрсәтик, диюне җитди адым дип карарга мөмкинме?

Татар, башкорт, керәшен кебек уртак телле йә татар, кыргыз, үзбәк, госманлы кебек телләре бер-беренә якын, бер-бере белән мәдәни мөнәсәбәттә булган һәм бер-беренең матбугатлары белән файдаланган халыкларның хәрефләре дә уртак булу – гамәли һәм гамми әһәмияте булганлыктан, билгеле әһәмиятле мәсьәлә. Ләкин бу ноктадан караганда, латин хәрефләрен алудан гарәп-татар хәрефләрен саклау әһәмиятлерәк.

---

[1] Ихтилятка – аралашуга, катнашуга, дуслыкка.
[2] Имкян – мөмкинлек.
[3] Рәгъмән – каршылык итеп.

Хәреф сайлау мәсьәләсендәге башка тәкъдимнәрне бу бәйнәлмиләл ихтилят ягыннан тикшереп карыйк. Урыс хәрефләрен кабул итү тәкъдиме бу яктан латинчылыкка караганда күп алда тора. Чөнки: 1) урыс язуы Русиядә иң күп таралган һәм рәсми язу; моның өстенә татарларның байтак кыйсеменә иҗтимагый, икътисади тормышлары өчен урыс язуын һәм телен өйрәнергә туры килә; 2) татарлар һәммә җирдә урыслар белән катнашып утырганнар; 3) безнең белән катнашып һәм күрше утырган халыклардан чуаш, чирмеш, мордва, вотяк кебек халыклар, бар да урыс хәрефләрен йөртәләр һәм алар арасында татар телен белүчеләр дә күп, үз телләре дә татар теленә кардәшрәк; 4) татарларның үзләренең дә бер кыйсеме (керәшеннәр) татарчаны урыс хәрефе белән язып киләләр. Димәк, урыс хәрефләрен алу бу ике кисәкне матбугат, мәдәният ягыннан берләштерәчәк. Ләкин мәсьәләнең башка яклары: уку-язу өйрәнү, икътисад яклары һәм Шәрык белән мәдәни уртаклык мөнәсәбәтләре хәтергә алынганда, татар хәрефләре өстенрәк булуы һәм 5 миллион ярым татардан биш миллионнан артыграгы гарәп-татар хәрефләренә өйрәнгән булып, урыс хәрефләренә өйрәнгәннәре (керәшеннәр) 3000 (мең) кадәр генә булуы – урыс хәрефләрен кабул итү юлыннан бармаска мәҗбүр итә.

Бер генә шәкелле яңа татар хәрефләре – башта безне берникадәр Шәрыктан аерса да, калган Шәрыкның дә шул юлдан барачаклары күренеп тора. Башкортстан инде рәсми сурәттә бу хәрефләрне кабул итәргә карар бирде. (Инде Татарстаннан байтак микъдарда яңа хәрефләрне алдырды да.) Әстерханнан байтак микъдар яңа хәрефләрнең өлгергән кегльләреннән алдырдылар. Төркестанда рәсми мәгариф съездлары хәрефләрне бергә калдырып, Татарстандагыча баш хәрефләрне әсас итеп алырга карар бирде. Хива, Бохара гадәттә мондый мәсьәләләрдә Төркестан юлыннан баралар. Азәрбайҗанда имля мәсьәләсе белән хәреф мәсьәләсен катнаштырып йөртүчеләр тәшәббесе[1] белән латин хәрефе кертә башлау турында тәҗрибәләр ясалып ята; ләкин соңгы көннәрдә килгән хәбәрләр алар арасында да бу агымнан суына башлау аңлана: бер вакытлар (Аурупа сугышы башларында) Төркиядә дә, Азәрбайҗандагы кебек, кайбер мөтәхәссисләр тарафыннан шундый латинчылык тәҗрибәләре ясалып

[1] Тәшәббесе – инициативасы.

каралып, хәятка керергә зәмин[1] таба алмау сәбәпле ташланган иде, Азәрбайҗанда да латинчылыкның тәкъдире шул булса кирәк.

**Нәфасәт ягыннан** – нәфасәт тойгысы бик шәхси (индивидуальный) нәрсә; кайбер халыкларда – мәсәлән, урысларда вә Аурупа халыкларында күбрәк читле вә гомумән туры сызыкларга корылган шәкелләр үзләшеп киткән; Урал-Алтай, гомумән Азия халыкларында күбрәк түгәрәк вә әйләнмәле спиральле шәкелләр таралган, халык сәнаигы нәфисәсе дә шул әсаска корылган. Хәрефләрдә дә бу әсаслар тәэсир иткәнләр. Безнең арада да латин, урыс хәрефләрен матуррак табучылар бар. Миңа бу турыда сөйләшергә туры килгән урыс рәссам вә әдипләреннән «урыс-латин хәрефләре прозаичный, гарәп хәрефләрендә сызыклар матурлыгы, шигърият вә серлелек күбрәк,» дигән фикерләр ишетергә туры килде. Һәрхәлдә бу мәсьәлә шәхси зәвык мәсьәләсе булганга, моңа күп туктап тормыйбыз.

Кайбер латинчылар, без латин хәрефен алып ничә йөз төрле шәкелләрдә эшләнгән хәрефләргә малик булабыз, бездә матбагачылык сәнгате алга китә, диләр. «Йөз төрле шрифтлар» Аурупада да аристократлар өчен визит карталары вә башка шуларга махсус нәшрият өчен генә йөри, фәнни, гыйльми әсәрләр һәм гаммә өчен булган әсәрләр анда да һәрвакытта иң гади хәрефләр белән басыла. Уку агымының тизлегенә зарар итмәс өчен, бу шулай булырга тиеш тә. Мәсьәләнең башлануы яңалыгына карамастан, инде яңа шәкелдәге татар хәрефләренең 4 кегле тәмам эшләнеп истигъмаль ителә башлады, яңадан 3 төрле кегль озакламый куела башлый. Болар өстенә тагын 2–3 кегль эшләнү белән гамәли әһәмияте булган кегльләр өлгереп беткән була. «Инде йөз төрле шрифтлар телисең икән, моның өчен бер яхшы хәрефханә, бер-ике хаттат һәм гравир гына кирәк. Болар татар арасында электә дә бар иде. Хәзер дә бар, эш гамәли ихтыяҗ булмаудан гына тора.

***Нәтиҗә***

Югарыда сөйләгәннәрдән, уку-язу тизлеге, өйрәтү уңайлыгы, матбага өчен шәкелләр азлыгы, басмада-язмада бер үк шәкелләр йөрүе, әлегә кадәр өйрәнгән шәкелләргә якын булуы, әзрәк урын алу сәбәпле икътисади яктан өстенлеге, телләре, мәдәниятләре уртак булган башка төрек халыклары белән мәдәни уртаклашуларны бозмавы якларыннан – без латин хәрефләрен алуга караганда,

[1] Зәмин – нигез.

гарәп хәрефләреннән үзгәртелеп, бер шәкелгә калдырылган яңа татар хәрефләрен алу күп алда дип табабыз. Бу хәрефләрнең хәзер гарәп хәрефен йөрткән башка халыкларның телләренә дә кертергә ярарлык булуы һәм безгә биргән уңайлыкларын аларга да бирүе, бу яңа хәрефләрнең аларга да керүен тәэмин итә. Бу турыдагы һәммә әсасларны күзгә алып, Татарстан җөмһүрияте, Халык Комиссарлары Советының карары буенча, шул әсасны рәсми итеп кабул итте.

***Иске һәм яңа татар хәрефләре***

Сүз актыгында иске һәм яңа хәрефләребез арасындагы аерманы күрсәтеп үтик:

Уку агымы ягыннан – яңа хәрефләребез генә шәкелле булу аркасында мәгълүм авазлардан гыйбарәт бер сүзнең, сүз кисәгенең һәммә урында бертөрле шәкелдә булуын тәэмин итәләр. Мисал өчен, *баш, башлый, башлыйлар, башлады, башладылар* сүзләрен алсак, без *баш, башлый, башлады* сүзләренең, йә сүз кисәкләренең иске язуда, арттан берәр ялгау кушылу-кушылмавына карап, һәркайсының икешәр төрле *баш* / باش – باشـ /, *башлый* / باشلى – باشليـ /, *башлады* / باشلادى – باشلاديـ / рәвешләрендә язылганын күрәбез. Димәк, *баш* дигән сүзне укыган, йә язган чакта, иске язу буенча, укучы сүзнең ике төрле шәкелен истә тотарга мәҗбүр булса, яңа язу буенча, ул һәммә җирдә бу сүзне (артына берәр ялгау арттырылса да, арттырылмаса да) бер үк шәкелдә күрә һәм ул «баш» дигән авазлар һәйәте[1] өчен бер генә шәкелне истә тотарга мәҗбүр. Моның уку агымы тизрәк эшләнүгә һәм җиңелрәк баруга әһәмияте бар.

Язу агымы ягыннан яңа хәрефләр белән язганда сүз актыгындагы س / *син* /, ش / *шин* /, چ / *ч* /, م / *мим* / кебек хәрефләрнең койрыклары төшеп кала, ى / *йай* /, ک / *кяф* /, ڭ / *ң* / кебек кайбер хәрефләрнең шәкеле кыскара, шулар аркасында татар язуы тагын бераз тизләнә.

Өйрәнү-укыту ягыннан безгә элек тә һәр хәрефне диярлек балаларга дүртәр шәкел белән танытып барырга туры килә иде; хәзер шуның урынына бер генә шәкел өйрәтергә туры килә.

Матбага техникасы ягыннан – иске хәрефләр белән матбагада басу өчен китап җыюда һәр хәрефнең дүрт шәкеле: لا / *аерым, сүз башында, сүз уртасында, сүз ахырында* кебек кушма шәкелләр белән барысы 40 ка якын төрле шәкелдәге хәрефләр йөри иде.

[1] Һәйәте – сурәте.

(Рәкымнар[1] тыныш тамгалары, шпоннар бу исәпкә керми). Хәзер шул шәкел урынына һәр шәкелгә бер хәрефтән татарча өчен шәкел кала.[2] Димәк, матбага өчен хәреф шәкелләре саны элеккегенең дүрттән берсе генә була. Бу исә түбәндәге җәһәтләрдән әһәмиятле:

1. Хәреф кою өчен пуансон, матрицалар хәзерләү 4–5 өлеш җиңеләя; бу исә татар хәрефләрен төрләндерү, аларның техника һәм матурлык якларын күтәрүне җиңеләйтә. (Мәсәлән, элек бер гравюра ел буе өзлексез эшләп, бер кегльнең комплектына кирәкле пуансоннарны корычка кысып өлгерә алмый иде. Яңа татар хәрефләренең исә, бер комплектын һәммә галәмәтләре белән кысу бер гравюра өчен ай ярым чамасы вакыт ала. Моңарга хәрефләрнең саны кимүдән тыш, хәрефләргә кертелгән үзгәрешләрнең хәреф кисүдә технический уңайлыклар кертүгә имкян[3] бирүе дә ярдәм итә.)

2. Шәкелләрнең азлыгы хәрефне койганда озак вакыт алган матрицалар алмаштыру эшен киметеп, хәреф кою машиналарының тик тору вакытларын киметә, эш чыгышын арттыра. Мәсәлән, 20 потлы бер комплект хәрефне корр өчен матрицалар алыштырырга иске татар хәрефләре өчен 115 сәгатьләп вакыт китсә, яңа хәрефләр өчен бары 35 сәгать вакыт китә. Бу эш хәрефханәләрнең эш чыгышын 3–4 мәртәбә арттыра.

Шул 20 потлы бер комплект хәреф белән элек тә бер табак китап җыярга мөмкин була иде. Бердән шәкелнең төре азаюы сәбәпле, икенчедән *ш, с, җ, п* кебек иң авыр хәрефләре булмавы сәбәпле, шул ук 20 пот хәреф белән хәзер бердән 3 табак китап, йә берәр табаклы өч китап җыярга мөмкин була.

3. Хәреф җыя торган кассадагы тартмаларның саны 3 өлеш кими; 240 тартма урынына 80 кала. Шуның аркасында кассаларның гомуми зурлыгын кечерәйтергә һәм аерым тартмаларның күләмен зурайтырга мөмкин була. Бу исә хәреф җыйганда тартмаларны якынайтып һәм уңайландырып, бердән, 25% чамасы хәреф җыючының эшен җиңеләйтә, икенчедән, яңа хәреф җыючыларны өйрәтүне 2–3 өлеш җиңеләйтә. (Хәреф җыярга өйрәтү үзе байтак вакыт ал-

---

[1] Рәкымнар – цифрлар.

[2] Рәкымнар, тынышлар, гарәп хәрефләре һәм шпоннар белән иске хәрефләр барысы 240 лап булалар иде; бу галәмәтләрнең барысын кушканда да, яңа хәрефләр 80 шәкелдән артмый. *(Г. Шәрәф иск.)*

[3] Имкян – мөмкинлек.

ганлыктан, һәм Шәрыкта хәреф җыючылар җитешмәгәнлектән, бу мәсьәләгә дә әһәмият бирергә туры килә.)

5. Шәкелләрнең азлыгы һәм хәрефләрнең аркылылары бер-беренә якын булуы бу хәрефләрне язу машиналарына һәм хәреф җыю машиналарына куярга имкян бирә.

6. Иске хәрефләрдән *а /әлиф/, к /кяф/, җ /җим/, ң* кебек озынаеп өскә, йә аска иткән сызыклары күп иде. Бу сызыклар хәрефнең нигезенә сыймыйлар, шуңа күрә өстән, астан, яннан кисекле (подрезкалы) хәрефләр ясарга туры килә иде. Бу подрезкалы хәрефләр, хәреф койганда хәрефханә эшен 10 % чамасы арттыралар, тиз сыну, эштән чыгу сәбәпле хәрефнең чыдамлы 15–20 % ка киметәләр һәм корректура төзәтү эшләрендә комаучалыйлар иде. Яңа хәрефләрдә бу подрезкаларның булмавы, хәрефханә һәм матбагаларны күрсәтелгән җайсызлыклардан котылдыра.

Икътисади яктан яңа хәрефләрдә әсас итеп кечкенә шәкелле баш хәрефләр алынуы, зур койрыклы *җ, м, п* лар төшерелеп калдырылу һәм *к, ң* ларның өске сызыклары кыскартылу вә гайре яхшыртулар, бердән хәрефнең аркылысын тарайта, уртача алганда, хәрефләрнең бер юлга сыешы 10 % ка кадәр күтәрелә; икенчедән хәрефнең гомуми эрелеген (очкосын) үзгәртми саклап, нигезе киңлеген (кегль исәбен) 20–15 процентка киметергә имкян бирә. Бу исә бер үк сәхифәгә кергән юл исәбен шул нисбәттә арттыра. Шуларның нәтиҗәсендә элек тә бер табак татарча китапка 30 мең хәреф керсә, хәзер шул ук иң эрелектәге хәреф 40 мең чамасы керә. Димәк, бер үк китап электә 10 матбага табагы (160 бит) чыкса, яңа хәрефләр белән ул 7 ярым табак (120 бит) чыгарга тиеш. Димәк, бер үк китапны бастырырга кәгазь, кара, басу, төпләү якларыннан чыккан мәсарифлар[1] 25 % ка кими, китап арзанлана; йә бер үк мәсарифны тотып, шул нисбәттә күбрәк китап бастырырга имкян була. Гәзитә, журналларга, иске күләмен саклаганда, 25 процент материал артыграк кертергә имкян бирә. Әгәр икътисади яктан файда калдыру урынына гаммәми мәгънәви файдалар алырга теләсәк, югарыда күрсәтелгән әсаслар китапта хәрефнең эрелеген (очкосын) күрсәтелгән нисбәттә күтәрергә имкян бирә; бу исә күз саулыгын саклау, уку агымын тизләтү, укуда мәләкәсе аз булган сыйныфлар һәм гомумән балалар өчен китап, матбугат укуны җиңеләйтә.

[1] Мәсарифлар – чыгымнар.

Дөрест, гаммәми (массовой) табигатьтәге һәрбер үзгәреш берникадәр авыру кыяфәтен ала. Яңа хәрефләр дә беренче күрүдә безнең күзебезгә берникадәр яктырак тоелалар. Безнең иске хәрефләргә каратып өйрәнгән уку ягымыбыз, яңа хәрефләр искеләренә бик якын булсалар да, бер дәрәҗәдә үзгәрергә мәҗбүр. Яңа хәрефләргә өйрәнү дә башта иҗекләнебрәк укырга, хәтта кайберләребез яңа хәрефләр белән басылган текстлар очраганда, гәзитәләрнең андый җирләрен укымый да киткәләргә мәҗбүр булалар. Ләкин әкренләп яңа хәрефләргә өйрәнәбез, инде сүз башларының, лозунгларның шул хәрефләр белән булуын ят күрми, җиңел укый башладык; башкаларын да әкренләп өйрәнербез. Шушы көннәрдә өлгерә торган гәзитә һәм журнал текстлары өчен булган эрерәк (очколы) хәрефләр, бу өйрәнүне тагын җиңеләйтә төшсәләр кирәк.

Яңа йорт салу, яңа кием алу һәрвакытта байтак көч куярга, тормышның башка якларын да кыскаларга мәҗбүр итә, ләкин авырлык дәвере үткәннән соң, боларның һәммәсе онытыла. Яңа хәрефләр, өйрәнеп җиткәч, гомуми уку-язу агымын, балалар укытуны берничә процентка җиңеләйтсәләр, тизләтсәләр, матбугат эзләрендә шактый әһәмиятле процентта җиңеллекләр вә икътисади файдалар бирсәләр һәм бу уңайлыклар вә файдалар татар хәрефләре дәвам иткән мөддәттә[1] даими була торган булсалар, күчү дәверендәге берникадәр күз өйрәтүләрен авырсынмый күтәрергә мөмкин. Революция дәверләре төрле яңалыклар кертү өчен һәрвакыт күбрәк юл ача, моның өстенә һәртөрле шәһәрләрдәге татар һәм башка Шәрык матбагаларында сугыш һәм бөлгенлек аркасында элекке хәрефләр искереп, һәр җирдә диярлек хәрефләрне алмаштырырга ихтыяҗ булуы да, матбугатның вә мәктәпләрнең хөкүмәт кулында җыелган булуы да бу юлдагы адымнарны җиңеләйтә. Шуңа күрә без мәсьәләне, өстендә тотып, хәятка урнаштырырга тиеш дип табабыз. Һәм Татарстан Халык Комиссарлары Шурасының һәм Татарстан Гыйльми мәркәзенең бу юлдагы адымнары дөрес, җитди һәм һәркем тарафыннан ярдәм итәлергә тиешле адымнар дип таныйбыз.

*Мәкалә «Мәгариф» журналының 1923 елгы 2–4 саннарында «Галимҗан Шәрәф» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр басыла.*

[1] Мөддәттә – вакытта.

# БӨТЕН СҮЗЛӘР МЕТОДЫНДА СҮЗНЕ ИҖЕКЛӘРГӘ ҺӘМ АВАЗЛАРГА БҮЛҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

Америкада кулланыла торган бөтен сүзләр методының урысларда һәм бездә шул ук исем астында кулланыла торган методлардан байтак аермасы бар. Америкада кулланыла торган метод уку-язуга өйрәтүне китапсыз (әлифбасыз), сүзләрне иҗекләргә, авазларга бүлмичә, бөтен сүзләр укытып, яздырып кына алып бара. Бу метод белән барганда беренче уку елының азагына кадәр сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүздән аерым авазлар чыгару булмый. Шулай ук иҗекләрдән, аерым хәрефләрдән сүзләр ясатып та торылмый. Балалар сүзләрне бөтен көе укыйлар һәм язалар. Бөтен сүзләр белән, әйберләр белән танышкан кебек танышалар. Шуның өчен, башта әңгәмә ясап, әйбернең үзе йә аның рәсеме белән танышкач, сыйныфтагы тактага җөмләләр язалар. Язган җөмләләрдә, танышкан әйбернең исеме берничә мәртәбә кабатлана. Балалар ул сүзне җөмләдә күрә-күрә, кабат-кабат укып үзләштерәләр.

Уку башта кульязма хәрефләре белән алып барыла. Балалар үзләштергән сүзләрен язарга да өйрәнә баралар. Бөтен сүзләр белән таныштыру табигый рәвештә ашыкмыйча гына алып барыла: балалар сүзләрне үз көйләре белән үзләштерәләр. Уку башында көненә икешәр-өчәр сүз белән генә таныштыралар; бирелгән сүзләр санын әкренләп арттыра баралар. Шушы юл белән барып, Америка мәктәпләрендәге балалар, сүзләрне иҗекләргә, авазларга (хәрефләргә) бүлмичә дә, җиңел һәм яхшы укырга-язарга өйрәнәләр.

Бу методның нигезен болай аңларга кирәк. Кечкенә бала, башлап теле ачылганда, сөйләшергә бөтен сүзләрне үзләштерү юлы белән өйрәнә. Берәү дә теле чыга торган балага сүзләрне иҗекләргә, авазларга бүлеп күрсәтми. Теле чыга торган балага сүзләрне бүлеп-бүлеп бирсәк, ул аларны аңламас иде, сөйләшергә дә өйрәнмәс иде. Америкада мәктәпкә укырга кергән баланың үзләштергән сүзләренең күләме өч-дүрт йөзләп була, диләр. Укырга өйрәткәндә баланың үзе үзләштергән сүзләрен нигез итеп алалар: бала сөйләшкәндә бөтен сүзләрне үзләштергән кебек укырга, язарга өйрәнгәндә дә сүзләрне бөтен көе үзләштерә дип уйларга туры килә. Бала тормышта тирә-юнендәге әйберләрне күреп, алар белән бөтен

хәлләрендә танышса, аларның исемнәре белән дә үз тирәсендәге сөйләшүчеләрнең сүзләреннән бөтен көенчә таныша. Шулай ук укыганда да сүзләрне бөтен көе үзләштерә бара, ул үзләштергән сүзләрен укый да, яза да белә.

Америкада сүзләрдән аерым хәрефләр чыгару балаларның үзләренә тапшырыла. Укытучы балаларның сүздән аерым хәрефләр чыгару эшенә катнашмый; балаларга сүздәге аерым хәрефләрне тикшереп барырга гына булыша. Моның өчен ул мәктәп стеналарына (зур такталарга) сүзләрнең хәрефләренә, төзелешенә карап ясалган җәдвәлләр төзеп кенә бара. Җәдвәлдәге сүзләр һәрвакыт балаларның күз алдында була. Балалар аларны укыйлар, тикшерәләр, үз юллары белән инстинктив рәвештә анализ да ясыйлар. Балалар үзләштергән сүзләрен бөтен көе укыйлар, язалар. Аларның күзләре сүзләрнең шәкелләрен күрә, куллары ул шәкелләрне язарга өйрәнә, күнегә, укыганда колаклары сүздәге хәрефләрнең авазларын ишетә. Баланың үз башында анализ ясалганчы, укытучы балаларга аерым хәрефләр күрсәтү, иҗекләргә, авазларга бүлү юлына керми.

Сүзләрне хәрефләргә бүлмәүнең сәбәбе: укыганда берәү дә аерым хәрефләргә туктап, сүзнең аерым хәрефләрен укып тормый, иҗекләргә бүлеп тә укымый. Уку өчен сүздә ничә иҗек, нинди иҗекләр барын белүнең һич кирәге юк. Укучы зурлар сүзнең бөтен шәкелен күреп, укыганда танып, тиз генә әйтеп җибәрәләр. Балалар да белгән сүзләрен өзеп-өзеп укымыйлар, иҗекләренә дә тукталып тормыйлар. Шуңа күрә Америкада бөтен сүзләр методы белән өйрәткәндә, иҗекләрне һәм хәрефләрне аерып-аерып күрсәтүне дә уку өчен кирәкле бер теләк дип куймыйлар.

Ул шулай булырга да тиеш. Бездә дә бөтен сүзләр методы белән укытканда, элек балаларга сүзне бөтен шәкеле белән таныштыралар. Ул сүзләрне бала укый да, яза да белә. Тик бездә бала таныган сүзләрнең күләме биш-унга җиткәч тә, сүзләрне иҗекләргә, хәрефләргә бүлү юлына кереп китәләр. Шуннан соң бездәге бөтен сүзләр методы аваз методына охшашлы бер методка әйләнә.

Бездә сүзләрне иҗекләргә, аерым хәрефләргә бүләргә керешкәндә, баланың үзләштергән сүзләре аз була. Шуңа күрә бала бөтен сүзләрне тикшереп, анализ ясап, сүздәге иҗекләрне күңеленә сеңдереп җиткермәгән була. Аңарга үз юлы белән анализ ясарга вакыт бирмичә, ясалма рәвештә анализга керешәләр, шуның өчен

иҗекләргә бүлүдә дә, иҗекләрдән хәрефләр чыгаруда да бала пассив була. Укытучы сүзләрне иҗекләргә үзе бүлеп күрсәтә. Баланың җитәрлек күп сүзләр белән танышып, аларга үз юлы белән анализ ясаганына кадәр, укытучының болай ясалма анализыннан балага файда юк. Ул аны барыбер ачык аңлый алмый. Төрле сүзләрне укуда практика ясалганчы анализны тыштан аңлаган кебек булса да, моннан гамәлдә барыбер файда булмый.

Уку башыннан ук бала сүзләрне бөтен шәкелләре белән үзләштерә алгач, беренче дәресләрдән үк анализ ясап бару бер дә кирәк түгел. Иҗекләргә бүлү балага язуга тәмам өйрәнеп җиткәннән соң гына, язганда сүзне бер юлдан икенче юлга күчерү өчен генә кирәк.

Хәзер без татар һәм урыс мәктәпләрендә нык таралган бөтен сүзләр методларына тукталабыз. Боларның һәммәсендә дә бертөрлерәк агым бара. Башта баланы берничә бөтен сүзләр белән таныштыралар. Аннан соң сүзләрне иҗекләргә бүләргә керешәләр. Бөтен сүзләрдән йә иҗекләрдән аерым авазлар, хәрефләр чыгаралар.

Бу методның юллары белән танышыр өчен, шул методны башлап тормышка кертүче Морозова һәм Тихееваларның «Естественный способ усвоения детьми грамоты»[1] дигән китапларының 23 битендә балаларны бөтен сүзләр белән таныштыру турындагы түбәндәге сүзләрне китерәбез: *«папа, мама, Миша, Саша, Маша, Паша»* дигән сүзләрне күчмә хәрефләрдән җыеп ясалган карточкаларны курчакларга беркетеп, балаларга күрсәттек. Ике-өч көннән соң балаларның өчесе без биргән сүзләрне яхшы таный башлады. Моны тикшереп карар өчен, без карточкаларны курчаклардан аерып, балаларга карточкалар биреп, курчакны алып килергә, курчакны биреп, аның карточкасын эзләп табарга кушып карадык. Балалар боларны дөрес эшләделәр. Шуннан соң без балаларның бөтен сүзләрне үзләштергәнен белдек. Тик без балаларның бөтен сүзләрне нинди юл белән үзләштергәнен белмибез. Алар бөтен сүзләрне үз юллары белән үзләштерделәр. Балаларның таныган сүзләре көннән-көн арта барды».

[1] *Тихеева Е.И., Морозова М.Я.* Способ естественного усвоения детьми грамоты, 3 изд., П., 1919.

Морозова белән Тихеева балаларның бөтен сүзләрне үзләштергәнен яхшы аңласалар да, нинди сәбәп беләндер, сүзләрне иҗекләргә бүләргә керешәләр. Югарыда әйтелгән кулланманың 24 битендә укыйбыз: *«Мама, Маша»* кебек икешәр иҗектән төзелгән сүзләрнең карточкаларын икегә кисеп, бүлеп күрсәттек. Аннары иҗекләрдән, күчмә хәрефләрдән сүзләр төздердек». Сүзне иҗеккә бүлү 37 биттә болай күрсәтелә: «Менә шушы *«Мама»* дигән сүзне укыгыз! Менә мин аны икегә бүлдем». Ике кисәген ике кулына алып: «Менә бу яртысында нәрсә?» Монда әлегә кул селтәү дә бар. Иҗекләрдән сүзләр төздергәндә балаларга башта өчәр-дүртәр иҗек кенә бирсәләр дә, соңга таба унар, егермешәр иҗек тә бирәләр. Иҗекләрдән сүзләр төзүне туктатмыйча алып баралар. Алга таба, шул ук 37 биттә: «Бераздан соң без сүзләрне хәрефләргә бүлә башладык. Балаларга таныш булган *«Мама»* сүзен алып, аны балаларга хәрефләргә бүлеп кистек. Балалар ул сүзне хәрефләрдән җыеп бирделәр». Морозова белән Тихеева иҗекләргә, хәрефләргә бүлүгә бик нык әһәмият бирәләр. Бу методның юллары ачык күренә: башта бөтен сүз белән таныштыру, аннары сүзне иҗекләргә бүлү, иҗекләрдән сүзләр төздерү, сүзләрне хәрефләргә бүлү һәм аерым хәрефләрдән иҗекләр, сүзләр төздерү.

Урыс мәктәпләрендә кулланыла торган әлифбалар күбесенчә шушы методка каратып төзелгәннәр. Бу методның урысларда куелышын тулырак күрсәтер өчен, тагын Соловьёва белән Горобецның «Авылдан» дигән әлифбасына кулланма китабын укып карыйк. 3–11 битләрдә бөтен сүз белән таныштыру, сүзне иҗекләргә бүлү, иҗекләрне хәрефләргә бүлүләр күрсәтелгән. Бөтен сүз белән таныштыру шулай ук әңгәмә ясап, рәсемнәр төшерү юлы белән алып барыла.

Балалар бөтен сүзләрне җиңел үзләштерсәләр дә, Соловьёва бу үзләштерүне уку дип танымый. Ул бөтен сүзне үзләштерү, сүзнең шәкелен генә үзләштерү, балалар сүзне иҗек һәм авазларга бүлеп, аның аерым хәрефләрен белгәнче укый белмиләр дип, бик тиздән анализ-синтез юлына кереп китә. Аның методы буенча укытучы *«хата» (хата)* дигән сүзне икегә бүлә дә, икесен ике кулына алып, аерым-аерым укыта. Соловьева ике кул арасында бер аршын ара булырга кирәк (!), ди. Укытучы уң кулын селтәгәч, балалар *«ха»* диләр, сул кулын селтәгәндә «*та*» диләр. Укытучы селтәгән саен

кулларын якынлаштыра, актыгында ике кулын бергә кушып селтәгәндә, балалар *«хата»* дип укыйлар. Соловьёва, ике иҗекне бергә кушканчы, ничә мәртәбә кул селтисен генә әйтмәгән (?!). Алай да ул иҗекләр белән бик яхшы таныштырып барырга кирәк, ди. Аның методы буенча, сүзләрне иҗекләргә бүлеп: *«Па-хо-ма»* дип тә укырга кирәк. Тулы анализ ясаганчы, балалар да уку дип китсә дә, Соловьёва бу китапта сүзләрдән аерым хәрефләрне чыгару юлын күрсәтмәгән. Алай да аның: «Балалар хәрефләрне аерым укырга тырышалар» дигән сүзләреннән анализ нинди рәвештә барганын аңлап була. Мәсәлән: ул балалар аерым хәрефләрне: *«ти, ми, ри, хи»* дип укыйлар, ди. Шуңа күрә Соловьёва: «Балаларга тартык “мәдсез” хәрефләрне аерым укытмас өчен, ул хәрефләр ялгыз укуны яратмыйлар», дип, хәрефләргә *ер, ем, те, ха* кебек исемнәр генә биреп китәргә кирәк, ди. Балалар аерым хәрефләрне укырга тырышалар дигән сүзләр – хәреф чыгарганда сузып укыганны күрсәтәләр. Бу урыс мәктәпләрендә куллана торган методларга төрле рәвештә критика биргәнче, без татар мәктәпләрендә куллана торган методларның юлларын күрсәтеп китмәкче булабыз.

Татарча басылып чыккан әлифбаларда укырга-язарга өйрәтү шул ук урыс мәктәпләрендә куллана торган Тихеева, Соловьёвалар методы белән һәм шуларга охшатып ясалган. Бу әлифбалардан «Кызыл юл» коллектив тарафыннан төзелгән, «Эш һәм белем» Хәйри, Саттаров һәм Тимербулатовлар[1] тарафыннан төзелгән. «Кызыл юл» әлифбасының «Методика хаты»ның 5 битендә укыйбыз: «Безнең бу әлифбабыз буенча укырга-язарга өйрәтү методы бөтен сүзләрне күзәтү методының анализ-синтез төре була. Бу метод белән өйрәткәндә бөтен җөмлә, бөтен тәгъбир[2], яки бөтен сүз рәвешендәге бөтен шәкелдән чыгып эш күрелә». 4 биттә: «Бу метод буенча укырга, язарга өйрәткәндә аерым хәрефләрнең артык әһәмияте дә калмый».

«Эш һәм белем» әлифбасының тышында: «Бу әлифба бөтен сүзләр ысулы буенча төзелде,»– дигән. Алга таба: «Эш һәм белем» буенча укытканда, хәрефләр билгеле бер тәртип буенча узыла», дигән. Бу әлифбалар башта сүзнең шәкеле белән таныштыралар. Өч-дүрт дәрестән соң сүзләрне иҗекләргә бүлүгә керешәләр,

[1] *Саттаров Ш., Хәйри К.,Тимербулатов Г.* Эш һәм белем. Әлифба. М.,1925. 64 б.

[2] Тәгъбир – бер мәгънә белдергән фраза.

иҗекләрдән сүзләр төзерәләр, биш-алты дәрестән соң сүзләрдән аерым хәрефләр дә чыгара башлыйлар. Шуннан соң сүзләрне иҗекләргә бүлү, иҗекләрдән яңа сүзләр төзү, сүзләрдән аерым хәрефләр чыгару, аерым хәрефләрдән иҗекләр һәм сүзләр төзү көннән-көн артып бара. Иҗекләрне, сүзләрне күчмә хәрефләрдән төзерәләр.

«Методика хаты»ның 10 битендә, 7 дәрестә *«Сафа тактага яза»* дигән җөмләдән алган сүзләрне иҗекләргә бүлү юлы күрсәтелгән. Башта *«Сафа»* дигән сүз алына. Укыйбыз: «Ул сүз укучыларның күз алдында ук катыргыны урталай бөгү юлы белән иҗекләргә бүленә. Укытучы катыргының әле бер кисәгендәге, әле икенче кисәгендәге сүз яртысын күрсәтеп укыттыра. Шул юл белән җөмләнең икенче сүзләрен дә иҗекләргә аерттыралар. Бу иҗекләрдән яңа сүзләр тудырыла. Бу күнегүләрнең нәтиҗәсе буларак, күчмә хәрефләрдән ясалган иҗекләрдән *«Тактага Сафа яза»* дигән гыйбарә төзерәләр». Укучылар иҗек һәм сүзләрне күчереп язалар.

Шушы дәресне математика белән бәйләр өчен, материал «көндәлек эшләреннән алына» дигән. Менә ул материал: «Бу дәрестә ничә юл? Беренче юлда ничә сүз? Бу ике юлда ничә сүз? Фәлән сүздә ничә иҗек? Төгән сүздә ничә иҗек? Бу ике сүздә ничә иҗек? Синең кулыңда ничә иҗек?»

«Методика хаты»ның 11 битендә сүздән аерым хәрефләрне чыгару юлы күрсәтелгән. Бу дәрестә *«Рәисә тактага хисап чыгара»* дигән җөмлә алынган. Башта шул җөмләнең сүзләре һәм иҗекләре белән таныштырып уздырыла. Шуннан соң укытучы: «Сүзләр җәдвәленнән балаларга таныш булган *«чыгара»* дигән сүзне кисеп ала да аны болай күрсәтә: *«Чыгар – р, а – а»* һәм шунда ук, ул хәрефләрне аерым-аерым көенчә әйттермичә генә *«ра»* диеп куштырыла. Чөнки *«ра»* иҗеге балаларга билгеле иде. Шулай ук *«Рәисә»* сүзеннән «*ә*»не чыгарта да, аны да *«чыгар»* сүзеннән чыккан *«р»* белән шунда ук *«рә»* дип куштырыла. Чөнки *«рә»* дигән иҗек тә *«Рәисә»* дигән сүздән аларга таныш иде. Димәк монда аваз методы белән укыткандагы кебек *«р»* һәм *«а» ны «р+а» «ра»* дип, *«р»* белән *«ә»* не *«р+ә»* дип куштырылып торылмый, бәлки туп-туры балаларга таныш иҗекләр буенча «*р*» һәм «*рә*» дип кенә кушыла.

Моннан соң *«а»* белән *«ә»*нең сүзнең уртасында һәм азагында килгәндә ничек язылулары күрсәтә: «шуннан соң укучылар: *ар, әр*

кебек хәрефләре өйрәтелгән сүзләрне хәрефләрен аңлап күчереп, яңа хәрефләр белән язалар».

«Эш һәм белем»дә болар әйтелгән: «Балаларны хәрефләр белән таныштырырга артык ашыкмаска кирәк. Хәрефкә кадәр әлифбаның биш-алты сабагындагы материалны хәреф белмәгән хәлдә, ялгышмый укый-яза, аннан соң сүзләрне иҗекләргә аера, иҗекләрдән яңа сүзләр төзи, үтелгән материалларга карап, рәсемнәр ясый алырлык булырга тиешлеләр», диелгән. Боларда хәрефләрне ничек чыгару юлы күрсәтелмәгән.

Шушы кыска рәвештә алынган сүзләрдән урыс һәм татар мәктәпләрендә укырга, язарга өйрәтү бер юлдан барганы аермачык күренә. Тик бу методларның берсен дә «бөтен сүзләр методы» дип булмый. Чөнки уку башындагы дүрт-биш дәрестә генә сүзләрне аерым кисәкләргә бүлмичә, бөтен сүзләр белән таныштырып барыла. Шуннан соң ук иҗекләргә, аваз-хәрефләргә бүлү китә. Бу методлар буенча бөтен сүзләр укырга-язарга өйрәтү өчен кирәк түгел, алар бары сүзләрне иҗекләргә, хәрефләргә бүлү өчен генә кирәк икән, дип аңларга туры килә.

Шаповников белән Соловьёва бер дә яшермичә: иҗекләрне, хәрефләрне, сүздәге авазларны белгәнче, балаларда уку булмый, тик бөтен сүзләр белән генә танышу була дип әйтәләр. Элеккеге аваз методы да мәсьәләне шулай аңлата иде. Аваз методының нигезе дә – хәреф – аваз һәм иҗекләр иде. Аның да анализ-синтез турында хәрефне – авазны бөтен сүздән чыгаралар иде. Анда да сүзләрне иҗекләргә бүлү, иҗекләрдән сүзләр төзү, хәрефләрдән иҗекләр төзү, җөмләләрне сүзләргә бүлү бик тулы бара иде. Аваз методы да бөтен сүздән хәрефләргә – авазларга, иҗекләргә, иҗекләрдән бөтен сүзләргә таба бара иде, тик аваз методы бу юлны тотканда, сүзләрнең шәкелләре белән таныштырмый иде. Хәзерге вакытта урысларда һәм бездә «бөтен сүзләр методы» исеме белән йөргән методлар анализ-синтез дәреснең башында сүзнең бөтен шәкеле белән таныштыргач ясарга кушыла. Башка юллары һәммәсе дә боларда аваз методы юллары кала.

Уку, язу эшен бөтен сүзләр методы белән алып барганда, сүзләрне иҗекләргә бүлү, иҗекләрдән аерым хәрефләр чыгару, боларда күрсәткәнчә, бала укый белә торган сүзне катыргыны икегә кисеп күрсәтү, иҗекләрне куштырганда куллар селтәү, авазларны

суздырып әйттерүләр, күчмә хәрефләрдән сүзләр төздерүләр педагогика ягыннан да, сүзләрнең язылган шәкелләре ягыннан да, аларның сүздәге әйтелеше ягыннан да дөрес юл дип әйтеп булмый. Чөнки сүздәге иҗекләр, авазлар балаларга табигый рәвештә, бөтен сүздә ничек язылса һәм сөйләнсә, шулай ук күрсәтелергә дә тиеш. Бөтен сүздән аерып алынган, хәятта аерым-аерым йөрмәгән, мәгънәләре конкрет һәм балага аңлаешлы булмаган иҗекләрнең һәм авазларның балага күрсәтелүенең баланың укырга, язарга өйрәнүе өчен дә, белеме, аңы арту өчен дә, тәрбия ягыннан да файдалары юк.

Бу методлар, уку башында бөтен сүзләр белән таныштырып, аннан ары тиз генә анализ-синтез юлына керешеп, ике методны болгатып баралар. Шуның өчен укытучылар башта берничә дәрес балаларны җиңел рәвештә бөтен сүзләр белән таныштырып баралар да, соңыннан метод һәм әлифба китабы буенча, иҗекләргә һәм хәрефләргә бүлү вакыты килеп җиткәч, алга таба ничек алып барырга йөдәп, электән үзләренә мәгълүм булган аваз методын алып китәләр. Шуның өстенә укытучылар өчен төзелгән методика кулланмалары да һәммәсендә дә кыска рәвештә язылган.

Без хәзер күрсәткән методлардагы сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм сүзләрдән хәрефләр чыгару җитешсезлекләрен бетереп, бөтен сүзләр, саф Америка методы белән алып барганда, бу эшләрнең ничек эшләнгәнен күрсәтеп китмәкче булабыз. Америкада бөтен сүзләр методы белән файдаланганда, (урыслардагы, бездәге кебек) сүзләрне иҗекләргә, авазларга бүлүгә керешмиләр. Бөтен сүзләр белән танышып барганда, җөмләләр укыганда, укытучы балаларга таныш булган сүзләрдән мәктәп стенасына җәдвәлләр төзеп бара. Америкада мәктәп стеналарында бик зур такталар ясалган. Җәдвәл баганалары сүзләрнең нинди хәрефләрдән торуына карап ясала. Балалар бөтен сүзләрне үзләштереп барганда, яңа сүзләр килеп чыкса, алар тиешле баганага язып куела, уку көннәре алга таба барган саен, җәдвәлләр дә үсә. Яңа сүзләрне кайсы баганага язуны, балалар җыелган сүзләрдән аналогия һәм апперцепция белән үзләре билгеләүгә хәзерләнеп җиткәнче, укытучы үзе күрсәтеп бара.

Балалар бөтен сүзләрне күчереп һәм күңелдән язу, сүзләр һәм уку юлы белән һәм җәдвәлдәге сүзләрне укып, аларның шәкелләрен чагыштыру юллары белән сүздәге хәрефләрне, авазларны һәм язуда

сүзләр төзелү рәвешен үзләренең инстинктлары белән сизә башлыйлар. Формаль яктан сүзләрне аваз һәм хәрефләргә бүлү булмаса да, эштә балалар инстинктлары белән сүзләрнең һәм иҗекләрнең төзелеш кануннарын үтеп алалар. Шулай итеп, баланың үз башында сүзләрне авазларга, хәрефләргә бүлү анализы үзеннән-үзе килеп туа. Шул инстинкт анализы белән балалар практикада да файдалана башлыйлар. Балалар да шул рәвешчә, анализ-синтез ясаса, бу эшләрнең формаль рәвештә эшләнүе уку-язуга өйрәтү ягыннан үзенең әһәмиятен бөтенләй җуя.

Димәк, бу методта сүзләрне хәрефләргә, авазларга бездәге кебек формаль рәвештә бүлү юк. Сүздәге авазларны, аларның шәкелләрен инстинкт һәм практика ягыннан балаларга белдереп, хәрефләрне аерым хәрефләрдә биреп, күп кабатлап урнаштырганнан соң гына, укытучы сүзләрне формаль рәвештә хәрефләргә бүлүне дә күрсәтеп китә. Балаларның яшь акыллары киңәю дәрәҗәсен дә хәтергә алганда, анализны бөтене белән дә, аерым кисәкләре белән дә яхшы беленгән әйберләргә генә ясарга мөмкин. Бала шул рәвештә белгән әйберенә үз башы белән дә анализ ясарга тырыша һәм ясый. Шулай ук ул укый-яза белгән сүзләренә дә уку-язу барышында үз юлы белән анализ ясап бара.

Язганда да баштан ук бөтен сүзләр күчерттереп яздырып барыла. Монда укуга караганда да баланың үз анализы ныграк бара. Чөнки бала сүзнең аерым шәкел кисәкләрен яхшырак күрә. Кулының хәрәкәте хәрефләрнең шәкелләрен ныгыта. Бер үк шәкел – кисәкләрнең күп таныш сүзләрдә очравы балада аналогия, чагыштыру юллары белән, инстинкт юлы белән анализ ясата.

Америкада кулланыла торган бөтен сүзләр методын татар мәктәпләрендә практикада ничек алып бару, балаларда сүзләргә инстинкт юлы белән анализ ясату юлларын ачык рәвештә күрсәтер өчен, без түбәндәге юлны тотарга тиеш дип уйлыйбыз:

1) Балаларга байтак бөтен сүзләр бирелә. Алар бу сүзләрне аерым хәлдә һәм җөмләләрдә тактадан һәм китаптан бөтен килеш укыйлар, күчереп язалар. Шулай итеп, күз күрүе ягыннан да, кул хәрәкәтләре ягыннан да, сүзне бөтен килеш ныгытып, үзләренә урнаштыралар.

2) Шул ук вакытта аерым тамыр – нигез сүзләрдән тыш, өйрәнгән сүзләрнең сарыфы үзгәргән формалары да яңа бөтен сүзләр

итеп таныштырылалар: *ат – атлар, бала – балалар, арба – арбалар, чана – чаналар, арба – арбадан, чана – чанадан* кебек.

3) сүзләрнең нигез һәм бер үк ялгау белән сарыф ягыннан үзгәргән формаларыннан парлы җәдвәл баганалары төзелә:

| | | |
|---|---|---|
| *ат–атлар*<br>*арба – арбалар*<br>*чана – чаналар* | *арба – арбада*<br>*чана – чанада*<br>*бала – балада* | *арба – арбам*<br>*чана – чанам*<br>*ана – анам* |

кебек, яңа сүзләр, өйрәнгән саен һәм ул сүзләр шул формаларда очрау белән, бу баганалар астына языла баралар. Шушы рәвешчә, бер ай, ай ярым кадәр вакыт шундый җәдвәлләр төзеп кенә һәм иҗеккә, фәләнгә аермыйча барыла. Бу арада балаларга таныш тигез сүзләр 100 ләп җыела.

Шул ук сүзләрнең морфология ягыннан үзгәргән унлап төрләрен үз башына аерым сүзләр итеп караганда, балаларның бөтен таныш сүзләре 500 ләргә якын була. Мондый морфология җәдвәлләренең баштарак үткән сүзләрдән алып ясалган үрнәкләре аерым кәгазьгә эре хәрефләр белән укытучы тарафыннан язылып, сыйныф стенасына эленә бара. Балалар да үз кәгазь йә дәфтәрләренә шундый җәдвәлләр[1] ясый баралар. Бу эш күзәтелгән аерым морфология ялгаулары кайда очраганда да сыйныфтагы һәммә балалар тарафыннан җиңел рәвештә үтәлеп алынганга кадәр алып барыла. Шуннан соң бу ялгау белән җәдвәл дәвам иттерелми. Башкалары белән алып барыла. Тик болар берсе дә морфология ялгавы икәне балаларга әйтелми, балалар үз акыллары белән дә моны вакыты белән сизәчәкләр. Анда формаль рәвештә билгеләүнең бу дәрәҗәдә һичбер кирәге юк.

4) Ай, ай ярым чамасы вакыт узгач, тамыр – нигез сүзләрдәге иҗекләрне балаларның башларында инстинктивный анализны ачыкландыру һәм үз-үзен тикшереп, аныклап бару өчен кирәк булган икенче рәвештәге җәдвәлләр ясала башлый. Монда сүзнең башында бер үк иҗек тапкырланган бер-беренә башка булган сүзләрдән җәдвәл баганалары ясала, ул иҗеккә аваз һәм төзелеш ягыннан кардәш булган башка иҗекләр белән дә багана ясала. Бу

[1] Җәдвәлләр – таблицалар.

да кәгазьгә язып, стенага элү һәм балаларның үз дәфтәрләренә яздырып бару ысулы белән ясала. Җәдвәл баганаларының үрнәкләре:

| | | | |
|---|---|---|---|
| *ата*<br>*ана*<br>*ага*<br>*ала* | *ата*<br>*бата*<br>*сата*<br>*тарта* | *арба*<br>*арта*<br>*аркан*<br>*арган* | *татар*<br>*атар*<br>*сатар*<br>*батар* |
| *кар*<br>*тар*<br>*бар*<br>*шар* | *тар*<br>*тап*<br>*тал*<br>*так* | *карт*<br>*тарт*<br>*тазарт*<br>*кабарт* | *ук*<br>*сук*<br>*шук*<br>*тук* |

кебек, балаларның үзләштерүләренә карап, бу җәдвәлләрне элегрәк ясарга да мөмкин.

Төрле иҗек һәм авазлар белән ясалган сүзләргә балада инстинктив рәвештә шундый анализлар ясалганчы, бу рәвештә кирәкле иҗек һәм авазлар белән, бер-береннән күчеп, баганалар төзү алып барыла. Төрле юллар белән баланың күп аерым һәм үзгәрешле сүзләр белән танышу агымында үз-үзеннән ясалып барган анализ, шул юл белән сурәтләттерелә. Билгеле, бу баганаларны төзү өчен аерым дәресләр ясап тору һич кирәк түгел, укытучы шул вакытта күрсәтергә теләгән баганасын, шуңарга кирәкле берничә таныш сүз җыелгач, кәгазьгә язып, йә югары сыйныф шәкертләреннән күчертеп яздырып, элеп куя да аны балаларның дәфтәренә күчертә һәм агымдагы сабакларда шул төркемгә язарлык сүзләрнең балалар дәфтәренә берничә сабакта чыккан саен арттырып бара. Шуның белән янәшә үк башка иҗекләр белән дә шундый кайбер күнегүләр алып бара.

Берникадәр төрле калын һәм нечкә иҗек һәм авазлар белән мондый күнегүләрдән соң, җәдвәлләрне балаларның үзләреннән генә төздерергә дә мөмкин. Бер яздан соң, моның да кирәге бетә. Чөнки балаларда сүзләрне анализ кувәсе шул юллар белән эшләнгән була.

Җәдвәлләр төзүне вакыт күп ала торган бер эшкә әйләндерү кебек казуистикалардан укытучыларга сакланырга кирәк. Балаларның башында җәдвәлсез дә анализ ясалган иҗекләргә, хәрефләргә җәдвәлләр төзүнең һич кирәге юк.

5) Вакыты җиткәч үтелә торган әлифба китабы буенча калынлык тамгасы куела һәм куелмый торган ачык вә ябык иҗекләрдә «ذ»

«وُ»язылa һәм язылмый торган сүзләрнең шулай ук җәдвәлләре ясала. Монда балаларга фәлән хәреф төшеп кала, фәлән хәреф, аваз ишетелсә дә, бу хәреф фәлән урында языла, фәлән урында язылмый дип, «фәлсәфә» сатарга кирәк түгел. Бөтен сүзләр шул рәвешле баралар. Формаль рәвештә иҗек һәм авазлар, хәрефләр чыгаруга бөтенләй керешелми. Апперцепция, инстинкт юллары белән балалар җиңел, дөрес һәм табигый сөйләшкәндәге кебек иҗекләрне сузмый, тасвирый рәвештә укырга өйрәнәләр. Тәмам укырга өйрәнгәч, һәммә хәрефләр күп сүзләрдә күрсәтелеп беткәч кенә, балаларга аерым хәрефләр белән әлифба тәртибе дә күрсәтелә (без монда рәсем төшерү һәм комплексның башка якларын алып баруларга кагылмыйбыз, алар һәммәсе гомуми рәвештә бәйләнеп баралар. Бу рәвештә бөтен сүзләр белән генә алып баруның мөмкинлеген без үз тарафыбыздан татар авыл мәктәпләре өчен төзелгән «Яңа авыл» әлифбасында күрсәттек)[1].

Инде бу методны нигезләү турында бераз тукталыйк. Балалар бөтен сүзләрне иҗекләргә, хәрефләргә бүлмичә дә үзләштерәләр. Яңаларын да аналогия, апперцепция юлы белән читенлексез укыйлар. Аны безгә үз мәктәпләребездәге практика яхшы күрсәтә. Беренче дәресләрдә бөтен сүзләрне үзләштергән кебек, бала алга таба да бөтен сүзләрне шул килеш формаль рәвештә иҗекләргә, хәрефләргә бүлмичә дә үзләштерә ала. Билгеле, башта бала беренче күрүдә сүзнең бар шәкелләрен дә үзләштереп бетерә алмый. Ул аны бөтен көе күңеленә ала. Аннан соң шул сүзне яза-яза, укый-укый һәм аны фикере белән инстинктив рәвештә җәдвәлләрдә башка сүзләргә чагыштырып, сүзнең аерым кисәкләрен дә (иҗек һәм авазларын да) ишетә, аларның язылышларын да күрә, аларны үзләштерә, бала аларга инстинктив рәвештә анализ ясый.

Татар теленең төзелешен тикшереп карасак, без *-лар-ләр, -да-дә, -га-гә, -дан-дән, -ка-кә* кебек кисәкләрнең һәрвакытта сүз нигезенең азагына әйләнеп барганнарын күрәбез. Мәсәлән, *бара – баралар, бәрә – бәрәләр, арба – арбада, кәҗә – кәҗәдә, такта – тактадан, мәктәп – мәктәптән, ат – атка, бәрән – бәрәнгә* һәм башкалар.

[1] «Яңа авыл» *Галимҗан Шәрәф* һәм *И. Алексеев* (әлифба һәм беренче уку китабы). Госпрограммалар буенча Америка ысулы белән төзелгән. Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, Казан, 1926–1927 ел, апрель. *(Г. Шәрәф, И. Алексеев иск.)*

Сөйләшкәндә без гел шундый сарыф кисәкләре белән файдаланабыз. Бу кисәкләр белән мәктәпкә укырга кергәндә балалар да бик яхшы һәм урынлы файдалана беләләр. Бу сарыф кисәкләре, калыннары калын көенчә, кечкенәләре нечкә көе, бөтен сүзләргә кабат-кабат кушылалар.

Менә шундый сарыф ялгаулары, бетемнәре балага бөтен сүзләрне үзләштерергә бик булыша, аларны бала күп сүзләрдә очрата. Шуңар күрә сарыф ялгауларының авазлары да, шәкелләре дә баланың инстинкты ягыннан тиз үтелеп алыналар. Сарыф кисәкләренең сүз тамырындагы иҗекләрдән күп аермасы бар. Сүз тамырындагы иҗекләрне аерым алып карасак, аларның күбесенчә бөтенләй мәгънәсе булмый. Мәсәлән: *Сара, Рәисә* сүзләрен алып *Са-ра, Рә-и-сә* дигән иҗекләргә бүлсәк, без мондагы һәммә кисәкләрне мәгънәсезлеген һәм конкрет түгеллеген, урысча әйтсәк, «отвлеченный» икәнлеген күрәбез. Инде без *«ат – арба»* дигән сүзләргә *«атлар – арбалар»* дип ялгауларын кушып, балаларга янәшә төзегән җәдвәлләребезне чагыштырып күрсәтсәк, алар бу сүзләрнең аермаларын бик тиз сизеп алалар. Чөнки *«чана – чаналар»* сүзләрен чагыштырганда һәр икәве дә мәгънәле һәм конкретрак сүзләр алына. Сарыф кисәкләре кушылгач, аларны укыганда, тыңлаганда аваз ягыннан аермаларын ишетә, язганда язу аермаларын күрә. Ул акылы белән мәгънәсе үзгәрешен сизә дә ул үзгәрешләрне җиңел үзләштерә.

Сарыф кисәкләре кайсы сүзләрдә язганча ишетелми. Мәсәлән: *-дан* белән *-дән* кебек ялгаулар *аттан, бәрәннән* дигән сүзләрдә *-тан, -тән* дип укыла. Боларны язуда дөрес имля белән язып укыганда, сөйләгәнчә, дөрес укуны аналогия белән балалар башында калдырыр өчен, ачык укыла торган сүзләрдән төзелгән җәдвәл янына ачык укылмый торган сүзләрдән дә, йә катыштырып, җәдвәл төзеп барырга кирәк була. Укучы мондый аермаларны җәдвәлләрдә күреп укып барганда, аларны дөрес укырга өйрәнә. Җәдвәлләрне үзе язганда тулы, дөрес язарга механик рәвештә өйрәнә. Җәдвәлләр, бу турыдагы һәрбер әһәмиятле аерманы күрер өчен, балага күзәтү ясарлык материал була. Шуның буенча бала аермаларны да үзләштерә. Бу яктан җәдвәлләрнең балаларның имлясы дөрес урнашуга әһәмиятләре зур. Формаль рәвештә булмаса да, сүзләрнең сарыфы төзелешләре дә бала аңында ачылып бара. Тагы калын сүзләр белән нечкә сүзләргә кагылып китәргә кирәк. Баланы

калын һәм нечкә сүзләр белән таныштырыр өчен, аңар ул сүзләрдә, җәдвәлләрдә чагыштырылып күрсәтелергә тиеш. Моның өчен аерым җәдвәлләр йә элек төзелгән, мәсәлән, *-лар, -ләр, -дан, -дән* ялгавы белән төзелгән җәдвәлләрне чагыштырырга, *сүз – суз, тор – тора, бул – була, уч – өч* кебек сүзләрдән чагыштырма җәдвәлләр ясалырга тиеш. Без мондый җәдвәлләрне күрсәтеп, яздырып, кайсы вакытта сүзләр калын, кайсы вакытта нечкә булалар икәнен, кайчан калынлык тамгасы куела, кайчан куелмый икәнен, кайчан «ـٔ» языла, кайчан язылмый икәнен бала башында ачык иттереп калдыра алабыз. Һәм аның язу практикасында баштан ук дөрес урнашуына хезмәт итәбез. Югарыда күрсәтелгән «Яңа авыл» дигән әлифбада материал татар телендәге төрле сарыф-имля үзгәрешләренә каратып төзергә тырышылган. Укытучыга үзенә күп уйлап торырга, материал җыярга зур ихтыяҗ калдырылмаган. Тик әлифбада күрсәтелгән материалны укытучы белеп, аңлап кулланырга тиеш.

Җәдвәлләр белән стеналар тула дип куркырга ярамый. Америкада бөтен сүзләр методы белән укытканда, бөтен стеналарны язып тутыралар. Җәдвәлдә балалар сүзләрне тикшереп карап, аермаларны күрергә материал булса, җитә. Шуның өчен кайсы җәдвәлдә 6–7 сүз генә булырга мөмкин. Баштарак төзелгән җәдвәлләрнең кирәге беткәч, укытучы аны стенадан алып, киләсе ел өчен җыеп куярга мөмкин. Югарыда күрсәтелгәнчә, сарыф, имля, язу, иҗекләр, авазлар уртаклыгы җәдвәлләрен төзүне без сүзләрне иҗекләргә бүлү, авазлар, хәрефләр чыгару, шул иҗек һәм хәрефләрдән яңа сүзләр төздерү өчен формаль материал итеп карамыйбыз. Һәм мондый формаль материалга ихтыяҗ да юк дип уйлыйбыз. Без аларны уку агымын, язу агымын тизләтә торган, телнең гомуми морфология (сарыф) төзелешенең имля һәм язу белән мөнәсәбәтен балалар күзәтеп бару өчен кирәкле ярдәмче материал итеп кенә алабыз. Алар билгеле аналогия, апперцепция юллары белән, балаларга бөтенләй таныш булмаган яңа сүзләр очраганда да, укырга-язарга да ярдәм итәләр. Ләкин бу ярдәм дә баланың югарыда бирелгән материалны күзәтү, шуларны эшләү аркасында фикер ягыннан алга китүенең генә нәтиҗәсе була.

---

Әлифбасыз укыту турында да берничә сүз әйтеп китик. Хәзерге көндә укыту эшләре комплекслар белән алып барылганда, кайсыбер

методистлар – урысларда Шапошников, Бочкарёв, Болотниковлар, бездә дә кайберәүләр – әлифбасыз укытуны яклыйлар һәм куәтлиләр. Бу мәсьәлә буенча чыгарылган зур гына кулланмалар да бар.

Әлифбасыз укыту мәсьәләсе, моның тарафдарлары сүзенчә, түбәндәге сәбәпләрдән килеп чыга: комплекска карап төзелгән программалар буенча, һәр авылның, һәр мәктәпнең үз материаллары белән кулланырга кирәк. Әлифбалардагы материал комплекстагы материалны һәр җиргә ярарлык итеп бирә алмый. Моның өстенә алар материалны күбесенчә укырга-язарга өйрәтү юлына каратып төзиләр. Шуны күздә тотып, әлифбасыз укыту өчен укытучыларга кирәкле бик тулы зур кулланмалар төзергә кирәк, диләр. Ләкин тулы кулланмалар булганда, авыл мәктәпләрендәге укытучыларның бик азы гына әлифбасыз укыта ала. Чөнки әлифбасыз укыту өчен байтак кына күп материал кирәк. Аннан соң укытучылар да бик хәзерлекле булырга тиеш. Кирәкле материалны укытучы үзе ничә ел җыярга тиеш. Безнең мәктәпләрдә бер укытучыга икешәр, өчәр группа йөкләнгән: аның әлифбага материал хәзерләргә вакыты да юк. Америкада бер укытучы бер генә группа алып бара. Шуның белән бергә анда күп елдан бирле әлифбасыз укытып киләләр, бу юлда Америка укытучылары күп тәҗрибә алганнар. Группа саен бер укытучы булып, ул үз башына метод ягыннан дөрес итеп әлифба һәм башка материалны тулы биреп бара алырлык хәзерлеге булганда, Америкадагы кебек, бездә дә әлифбасыз укытуларны кертеп җибәрергә булыр иде. Хәзерге кебек укытучы өстендә ике-өч группа булганда һәм укытучыларның белем методикаларыннан хәзерлекләре күбесенчә җитәрлек булмаган бер дәвердә, әлифбасыз укыту дигән мәсьәлә теория ягыннан мөмкин кебек күренсә дә, практика ягыннан мөмкин түгел. Әле безнең авылдагы укытучыларыбызның күбесе тиешенчә көндәлек эш алып барыш планнарын да алдан төзеп җиткерә алмыйлар.

Аннан соң безнең татар авылларындагы авыл хуҗалыгы тормышы, гомумән алганда, һәммә авылларда бер-беренә бик якын. Аерым хосусан аермалар укытучы метод белән таныш булганда, әлифбага өстәмә итеп алып барыла. Шуңа күрә комплекс ягыннан куелган дәлилләр дә безнең шартларда әһәмиятле түгел. Шапошников, Болотников, Бочкарёвлар үзләренең методларын техникумнар янындагы үрнәк мәктәпләрендә генә куйганнар. Шуңар карап кына

авыл мәктәпләре эчендә дә шул ук методны тәкъдим итү, бу теория ягыннан карап, эш шартлары белән хисаплашмый кую була. Үрнәк мәктәпләрдә шартлар башка. Анда һәр группага бер хәзерлекле укытучы булып, өстенә техникумның методика алып баручысы бар. Авылдагы укытучы, мәктәптә эшләүдән тыш, авылдагы башка эшләргә дә катнаша. Аңарга байтак кына җәмәгать эше дә йөкләнгән. Боларны хисаплап тикшергәч, авыл мәктәпләрендә әлифбасыз укытырга тиеш, дигән фикер безнең шартларда тормышка кереп китә алмый дияргә туры килә.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 101 сакл. бер.*

*Мәкалә «Галимҗан Шәрәф, И. Алексеев» имзасы белән*
*1927 елда Казанда («Мәгариф» журналы басмасы) басылган.*
*Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр басыла.*

## ИЛЬИНСКИЙ БЛЮМЕНАУ[1]

Александр Адольфовичның Казанга килүен язган идек. Аның килүеннән файдаланып, аның берлән мосахәбезне[2] укучыларыбыз белән уртаклашабыз. «Сезнең татар җырларыны тәрҗемә белән шөгыльләнә башлауга нәрсә сәбәпче булды?» дигән сөальгә А. А. әфәнде түбәндәге җавапны бирә:

– Без Урта Русиянең зур шәһәрләреннән, хосусан, пайтәхетләрендә торучылар татарларның «шурум, бурум» дип кычкырып йөрүчеләрдән башкасыны бик аз беләмез. Татар дигәч тә безнең күзгә кулына иске нәрсәләр тоткан бер сыйфат күренә.

Без кешеләрнең үзләренә махсус вә оригинальный матурлыклар белән тулы, безгә күренми торган әдәби дөньялары барлыгын белмибез. Аларның нинди читенлекләр эчендә ничә йөз еллар буенча үзләренең милли хосусиятләрене саклап килә алулары вә аларның сәбәпләре тугрысында без уйлап карарга теләмибез.

[1] Александр Адольфович Блюменау (Ильинский, 1885–1971) – язучы, шагыйрь, тәрҗемәче, әдәбият галиме.

[2] Мосахәбезне – сөйләшеп утыруыбызны.

Минем берничә еллар (1905–1909 га кадәр) Уфа губернасы башкортлары арасында үткәргән гомерем бу милләткә карашымны бөтенләй үзгәртте.

Мин башкортлар белән күп катнаша, сөйләшә идем. Иң сөйгән нәрсәм башкортлардан җырлату, курай уйнату иде. Су буйларында бөтен төннәр җырлар тыңлап үтә иде. Шулай итеп маташа торгач, мин татарча яхшы гына сөйләшергә өйрәнгәнемне сизми калганмын.

Татарча сөйләгәнемне аңлау татарларның күңелләре, хәятларының төрле яклары белән танышуга миңа күп ярдәм итте. Акрын-акрын минем алдымда бу халыкның йомшак, яхшы күңелләре ачыла башлады. Мин бу күңел, бу җаннарда нindидер куәтле, таза вә киләчәкләренә өмид белән карата торган бер көч күрә башладым.

Татарларның җырларына әһәмият бирә башлаганнан бирле, татар җырларының үзләренә генә махсус русларга, хәтта, гомумән, аурупалыларга ят булган эчкә керү нөфүз кувәсе[1] мине гаҗәпләндерә иде. Мин аларның көйләрен, җырларын тыңлаганда үзем дә татарлаша, башкортлаша, үзем дә аларча уйлый, аларча тоя башлый идем. Вә торган саен бу халыкны үземә якынрак күрә, аларны ярата башладым. Үзем яраткан бу халыкны башкаларга гына яраттырасым килә башлады.

Моның өчен аларның өске тормышлары белән генә таныштыру җитми, аларның искедән бирле йөрәкләреннән янып чыккан, аларның шатлыкларыны арттыра, кайгыларыны баса торган күңелләреннән агып чыккан нәрсәләр белән таныштыру кирәк иде.

Иптәшләремнән яшь шагыйрь Ширинскийның киңәше берлән, мин рус матбугатында татарларны таныштыру юлында, икенче иптәшем Хәсән әфәнде Таниевның ярдәме аркасында, татар җырларын русчага тәрҗемә итә башладым.

Җырларда халыкның җаны, тормышы иң күп күренгәнгә, бу башлавымны иң яхшы юл дип беләм.

Кыскасы: татарларга өмидем әдәбиятларында хосусият күрүем мине тәрҗемә эшенә керештерде. «Татар җырларында нинди хосусиятләр күрәсез?» – дигән соравыма:

– Беренче, татарларның мәхәббәт җырларындагы искренность, чын сөю, куәтле мәхәббәтнең аңкып торуы – миңа охшаган

[1] Нөфүз кувәсе – сүз үтемлелеге көче.

нәрсәләрдән берсе. Безнең рус җырларында ул куәтне табып булмый. Бездә сөю җырларында бер дә искренность юк. Чын сөю берлән уен-көлке галәме бергәрәк буталып, гыйшык кызулыкларын сеңдергән. Икенче, татар җырларындагы охшату (тәшәббеһ)ләр, татар җырларындагы матур охшатуларны, нинди генә телгә тәрҗемә кылсаң да, аның матурлыгын бетерергә мөмкин булачак түгел. Андагы тәшәббеһләр башка телдән урланган булуы да мөмкин түгел, чөнки иң матур охшатулар – татарларның үзләре тормышына гаид[1] нәрсәләрдән алынганнары. Өченче, җырларның ясалышы вә озыннары андый төзелеш безнең рус җырларында юк. Ул безнең өчен яңа. Шуңа күрә мин татар җырларын тәрҗемә иткәндә дә, үз урыннарында калдырып тәрҗемә итүгә әһәмият бирәм. Һәм хакыйкатән дә минем тәрҗемәләр укучыларга, укуы күңелле булган бер яңа нәрсә булып чыга. «Татарча җырлардан башка хәзерге әдипләремезнең әсәрләрене тәрҗемә итәргә уйламыйсызмы?» – дигән сөальгә А. А. әфәнде: «Җырлар һәм шигырьләр тәрҗемәсен дәвам иттереп, әдәби әсәрләргә дә күчәргә дәртем бар. Белмим, кайчан муафыйк була алырмын», ди.

– Тәрҗемә иткәндә нинди әсәрләрне тәрҗемә итәргә уйлыйсыз?

– Әле бер мөхәррирнең бер әсәрләрен күрсәтә алмыйм, алай да мин татарларның төп үз тормышларыннан алынып, татарларның үзләренә махсус тормыш картиналарын күргәзә торган әсәрләрне тәрҗемә итүне муафыйк табам. Чөнки рус матбугатында инде аңарга ихтыяҗ бар, диде.

Бераз сөйләшеп утыргач, сүз арасында: бу ел кышның яртысын, татарлар күбрәк шәһәрләрнең берсендә торып, татар җырлары хакында тагы киңрәк мәгълүмат алып, татар җырлары хакында Мәскәүдә лекция укырга хәзерләнгәнне сөйләде.

«Өеңдәге хәбәрне күршедән сора», диләр. Үз җырларыңдагы хасиятне үзең белмәгәч, башка кешеләрнең айлар, еллар хәзерләнеп укыган лекцияләрен тыңлап, рәхмәт укырга тугры килә шул инде.

А. А. җәнаблары 1905 елларда гына яза башлап, беренче әсәре (кечерәк кенә шигырь мәҗмугасы) 1905 сәнәдә рус матбугаты арасында күренә башлаган.

Бу көндә русларның айлык журналларында, Мәскәүнең көндәлек гәзитәләренең бәгъзыларында, язучы һәм хәзер рус матбугатында

[1] Гаид – караган.

яхшы ук модага кергән «Иптәшләр мәҗмугалары»нда күренекле урыннар тотып килә торган бер шагыйрь һәм драматургдыр.

А. А. җәнабларының, башка рус әдип мөхәррирләренә караганда, безнең өчен бер хосусияте бар. Ул татар телене яхшы белә, татарның иске җырлары, яңа әдәбиятына әһәмият бирә.

Аның татар әдәбиятына әһәмият бирүе бер археолог, бер академикның әһәмият биргәне кеби фәнни тәдкыйкать[1], тарихи әһәмияте өчен түгел; бары бер әдип, бер шагыйрьнең ул әсәрләр, ул җырларда әдәби матурлык, хосусый бер күңеленә охшау күргәнлегеннәндер.

Ул татар җырларын, шигырьләрен, татарның үз мәгънәсен русчага тәрҗемә кылып, русларның яхшы әдипләренең әсәрләре, шигырьләре берлән бер рәткә куя. Аларның әсәрләреннән чын татарның йөрәгеннән чыккан сүзләр дә ким түгел, татарларның искедәге моңнары, зарлары, русларның да шул вакытларда әйткән сүзләренә биргесез икәнне татар җырларын тәрҗемә кылып, күрсәтеп аңлатырга тели.

Әлегә кадәр татар җырлары, ориенталистлар тарафыннан тәрҗемә ителеп, мөтәхассыйслары[2] өчен берничә нөсхәләр генә бастырылып таратылганнары күренгәли иде, ләкин алар берсе дә – гомум халык укып ләззәтләнер, шундагы кыйммәтле мәгънәләрдән гомум халыкны файдаландыру өчен тәрҗемә ителгән әсәрләр түгел, бары мөтәхассыйс кешеләрнең кабинетларында булындыру өчен хәзерләнгән тәрҗемәләрдер.

А.А. җәнаблары тәрҗемә булмаган үз шигырьләренең дә бәгъзыларыны татар рухында, татар җырлары гарузында яза. Анда татар җырларында гына очрарга мөмкин охшатулар ясый. Мисал өчен бәгъзыларыны күрсәтәмез:

*Йөрәгемне яндырадыр бер мәхәббәт ялкыны,*
*Файда бирми һич тә миңа бозлы суның салкыны.*

———

*Сандугачның балалары бар да кунган тирәккә,*
*Мәхәббәтең бигрәк каты кан төшерде йөрәккә.*

———

*Ал күлмәгем ике пар, берсен кисәм, берсе бар,*
*Йөрәгемне яндырадыр нечкә билле матур яр.*

[1] Тәдкыйкать – тикшеренүе.
[2] Мөтәхассыйслары – белгечләре.

———

*Җефәккә тиң кара сачең, җефәк бирим урарга,*
*Бик сагындым, бик саргайдым, килдем җаным күрергә.*

***Русчалары:***

*Огонь спалил мне всю душу, огонь любви молодой,*
*Не в силах я унять огня холодной, как лед, водой...*

———

*Соловушки-детки в ветвях играют, лаская глаз;*
*От любви пылающей душа кровью облилась.*

———

*Рубах алых и не счесть – надел одну еще есть,*
*Страсть к девушке тонко-тальей[1] больно, трудно перенесть.*

———

*Как черный шелк коса твоя, дам шелк волос заплетать.*
*Я соскучился, я желтый стал, пришел тебя повидать.*

## Горе

*(татарский мотив)*

*Умер мой мальчик... Я молюсь Аллаху*
*Желтые щеки жег своей слезой...*
*Умер мой мальчик... Я на землю лягу,*
*С тобой рядышком, с тобой, мой родной...*
*Я не услышу твоего «алекюм»,*
*Я не увижу твоих добрых глаз,*
*Тебя, мой мальчик, заменить мне некем,*
*Ты, как лампа в семь фитилей, погас.*
*И зачем солнцем залито небо?*
*И зачем пчелы жужжат целый день?*
*Если б не уснул, скакал на коне бы,*
*И мед бы ты ел, укрываясь в тень...*
*А теперь ты спишь, спишь, резвый, в полудни,*
*Я не вижу твоих добрых глаз...*
*Родной мой мальчик, праздник моих будней,*
*Ты, как лампа в семь фитилей, погас.*

---

[1] Тальей – талией.

***Тәрҗемәсе:***

**Кайгы** *(татар көенә)*

*Минем балакаем үлде... Мин, Аллага гыйбадәт кыла-кыла, саргайган йөзләремне күз яшьләрем белән яндырдым.*

*Минем балакаем үлде... Синең белән бергә, синең белән беррәттән мин дә җиргә ятар идем, җанкисәгем!*

*Мин синең «сәлам»еңне ишетмим, мин синең нурлы күзләреңне күрмим, синең урыныңа торырлык, сиңа алмаштырырлык дөньяда һичкем юк, балакаем! Син, җиделе лампа сүнгән кеби сүнеп киттең... Нигә генә соң күк кояш белән яктыртылган? Нигә генә соң умарта кортлары көне буе шаулыйлар? Аһ, әгәр мәңгелек йокы белән йокламаган булсаң, син атларда йөрер идең, вә күләгәгә качып, баллы икмәк ашар идең... Әмма хәзер син йоклыйсың, көн уртасында да йоклыйсың, шаянкаем, нурлы күзләреңне күрә алмыйм. Җанкаем, балам, бәйрәмсез көннәрдә бәйрәмем җиделе лампа күк, сүндең дә киттең...*

**Айся-Рохуллах, Мухаммед-Рассюл Уллагъ**[1]
*(Коран)*

*Настанет день, когда Христос*
*Взойдет на вышку минарета,*
*И бездны крови, бездны слез*
*Преобразить в потоки света...*
*И будет вечна радость эта,*
*Когда под знаменем креста*
*Христос обнимет Мухаммеда,*
*А Мухаммед-Рассюл – Христа...*
*И скажет он: – «Я мир принес,*
*Дары грядущего рассвета,*
*В моих садах венком из роз*
*Невеста юная одета,*
*В оковах строгого обета*
*Ждала Невинна и Чиста –*
*Христос обнимет Мухаммеда,*
*А Мухаммед-Рассюл – Христа...*
*Я к вам пришел в сверканье гроз*
*Благоухающаго света,*

[1] Мухаммед расулюллах.

*Испейте сок янтарных лоз –*
*Плодов осеннего расцвета,*
*И будет все весной согрето,*
*И в ясном шелесть листа–*
*Христос обнимет Мухаммеда,*
*А Мухаммед-Рассюл – Христа...*
*Час близок вечного завета*
*Любввеобильного Перста:*
*Христос обнимет Мухаммеда,*
*А Мухаммед-Рассюл – Христа...*

***Тәрҗемәсе:***

**Гайсә – рухаллаһ; Мөхәммәд рәсүлүллаһ**
*(Корьән)*

*Тиздән шундый бер көн килер ки, хәзрәт Мәсих манарага менәр, чиксез кан диңгезләрен вә яшь диңгезләрен яктылык агымына алмаштырыр; шуннан соң мәңгелек шатлык башланыр, чөнки Мәсих байрагы астында хәзрәт Гайсә – Мөхәммәдне вә хәзрәт Мөхәммәд рәсүл Мәсихне кочаклар.*

*Ул (хәзрәт Гайсә): «Мин дөньяга солых вә киләчәктәге яктылык бүләкләрен китердем; минем бакчаларымда, гөл сачәкләре белән бизәлгән Пакизә вә Гафифә кызлар (хурилар)көтәләр», диюр дә: хәзрәт Мәсих – Мөхәммәдне вә хәзрәт Мөхәммәд рәсүл Мәсихне кочаклар.*

*«Мин сезгә хуш исләр сачкән күк күкрәве – яшеннәр ялтыравында килдем; гәрәбә төсле көзге җимешләрнең суларын эчеңез! Боларның һәммәсен яз яктылары йылытыр».*

*Яфракларның селкенгән тавышлары астында хәзрәт Мәсих – Мөхәммәдне вә хәзрәт Мөхәммәд рәсүл Мәсихне кочаклар.*

*Мәңгелек гаһед[1] белән билгеләнгән мәхәббәт белән тулы заман тиздән киләчәк вә хәзрәт Мәсих – Мөхәммәдне вә хәзрәт Мөхәммәд әлрәсүл Мәсихне кочаклаячак...*

Менә бу шигырьләрдә, бигрәк тә соңгысында нидер үзлек күренә, нидер безгә якынлык сизелә.

Чыннан да сабый чактан ук тарихларда укыганымыз Казанның һәр битендә диярлек очрый торган иң соңгы ике пәйгамбәргә, бу көнге рус әдипләренең икесенә бертөрле күз белән карауларын, алар

[1] Гаһед – йөкләмә, килешү.

артыннан гомум халыкның да ике пәйгамбәрнең мәхәббәт белән кочаклашуларын ләззәт белән каршы алуларын күрү, безнең шикелле дини тәрбиядә үскән кешеләрне артыграк шатландырса да гаҗәп түгел бит!

*Мәкалә «Кояш» газетасының 1913 елгы 28 июль (№ 181) һәм 29 июль (№ 182) саннарында «Г. Шәрәф» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр басыла.*

## ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ОЛУГ ГАЛИМЕ В.В. РАДЛОВ[1]

1837–1917

*Сиксән яшь тулу мөнәсәбәте илә*

### I

Һич мөбаләгасыз[2], иң самими сурәттә әйтергә мөмкин ки, төреклекне өйрәнү (тюркология) фәнендә, бу фәннең башлануыннан бүгенгә тикле, Василий Васильевич (Фридрих-Вилһелм) Радлов кадәр бөек бер галим йитешмәмештер.

Радлов Германиянең башкаласы Берлинда 1837 ел 5 гыйнварда дөньяга килгән. Гимназияне бетергәч, 1854 елда Берлин университетының фәлсәфә бүлегенә кергән. Башта ул дин вә фәлсәфә гыйлемнәренә бирелә башлаган булса да, аларга туктап калмый, үзенең специальносте итеп лисан гыйлемене, Шәрык телләрене алган. Берлин университетында, аннан соң Галләдә үткәргән бер кышында Радлов тел фәнендә заманының иң атаклы галимнәреннән дәрес алган. Болар арасында Радловның Шәрык телләрендә баш остазы Шотт (Шоттъ) булып, Радлов аннан монгол, маньчжур, татар, кытай телләрене укыган. Башка остазлары аркылы яһүди, гарәп, фарсы вә госманлы телләре берлә дә танышкан.

Радлов университетта вакытта ук Ботлинкның якут теле грамматикасы берлә дә танышкан. Бу әсәр төрек телләрене фән юллары

[1] Бу мәкалә Петроград университетында Шәрык бүлеге приват-доценты Самойлович җәнабларының 1914 елда Петроградта басылган «В.В. Радловъ – какъ туркологъ» дигән әсәре буенча шуннан кыскартып язылды. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Мөбаләгасыз – арттырусыз.

берлә тикшерүдә беренче адым булып, якында тюркологиядә яңа дәвер башланачагын хәбәр бирә иде: бу дәверне Радлов ачты. Тюркологиянең яңа дәвере үзенең ачучысы вә аның зур вә иң эшлекле хадиме[1] исеме берлә «Радлов дәвере» диеп аталадыр.

## II

Остазы Шоттның тәэсире берлә, университетта ук Русиянең Көнтуыш[2] бүлегендә торучы халыкларның телләре вә тормышлары берлә танышуны төп теләк итеп алганга, Радлов студент чагында ук рус теле вә Русия берлә таныша башлаган иде. 1858 елда Йен каласында фәлсәфә докторы гонванын[3] алгач, ул Русиягә (Петроградка) юнәлде, Шоттның шәкерте булганга, Русиядә фән галимнәре дә, мәэмүрләр дә яхшы каршы алдылар. Тунгуз телләрене тәфтишкә керешергә уйласа да, ул уе, кайбер комачаулар чыгу сәбәпле, эшкә ашмый калып, тәкъдир Радловны тюркологлык юлына салды. Русиянең ул чактагы Берлин илчесе барон Мейендорфның тырышуы берлә Радлов Себердә Барнаул горный училищесында нимес вә латин телләренең мөгаллиме итеп тәгаен ителде. Җәйге айларда Алтай якларындагы халыклар арасында йөреп, аларның тормыш вә телләре тугрысында материал җыяр өчен, мәгашеннән[4] тыш ун елга кадәр еллык 700 сумнан акча да бирергә тәгаен ителде.

Радлов Барнаулда 1859 дан 1871 гә кадәр бары 12 еллап хезмәт итте. Җәйге айларда тирә-яктагы төрек халыклары арасында йөреп, материал җыя вә кышкы айларда укыту эшләреннән арткан вакытларында үзенең шул йирлек мөгыйине[5] була. Җәй көне җыйган материалларыны фәнни рәвештә тәдкыйк итә[6], тикшерә иде. Моның өстенә гарәп телләрендә шул мәсьәләләрдә чыккан яңа фәнни әсәрләр берлә дә таныша бара иде. Радловка эшләре өчен көндезге сәгатьләр генә йитми, ул төннәрен дә эш артында утырып, йокыял итүгә тәүлегенә 3–4 кенә сәгать вакыт бирә иде. Радловның хезмәтендә бу Барнаулда үткәргән дәверен «Алтай дәвере» дип

[1] Хадиме – хезмәткәре.
[2] Көнтуыш – Көнчыгыш.
[3] Гонванын – дәрәҗәсен.
[4] Мәгашеннән – эш хакыннан.
[5] Мөгыйине – билгеләүчесе.
[6] Тәдкыйк итә – тикшерә.

атыйлар. Ул бу дәвердә Алтай тирәсендәге төрек ыруглары, Саян таулары якынындагы суютлар, дала казакъ-кыргызларын, Или үзәнендәге халыкларны (калмык, кыргыз, таранчы, кытай, маньчжурларны), Абакан төрекләрене, гарби[1] себер татарларыны, Йиде су буендагы төрле төрек халыкларыны тел, тормышлары ягыннан тәфтиш иткән.

Радлов әлегә кадәр бөтенләй диярлек тикшерелмәгән халыклар арасында йөреп, аларның теле, ил сүзләре (халык әдәбияты), тормыш – йолалары тугрысында бик күп материал җыю берлә генә калмыйча, бу йирләрдәге борынгыдан калма нәрсәләр, халыкның саны, байлыгы тугрысында вә ул урыннарның җәгърәфиясенә вә башка мәсьәләләргә гаид бик күп материал җыйды. Радловның бу хезмәтләре тюркология тарихында ачык күренеп торган яңа эпоханың башлануы иде. Хәзердә дәвам итмәктә булган бу дәвер, бу көндә тере төрек ыругларындагы телдә вә язуда сакланган материалларны җыю, вә бастыруда, вә болар тугрысында баштагы мәгълүматларны бирүдән гыйбарәт булып, дәвернең башлаучысы Радлов булганы күк, дәвернең хәзерге көндә дәвамы да Радлов исеме берлә бәйләнгәндер.

Бу Алтай дәверендә Радловның нимес, рус вә француз телләрендә 21 әсәре басылып чыкты. Болар арасында зурраклары – «Төрек будуннарының ил сүзе үрнәкләре» (Төрек милләтләренең халык әдәбияты нәмунәләре) дигән әсәренең баштагы өч томыдыр. Боларның 1866 елда чыккан беренче томында Алтай тирәсендәге төрек телләрендәге 1868 дә чыккан 2 нче томында Абакан, Кызыл, Чулым төрекләренең телләрендәге 1870 тә чыккан 3 нче томында, казакъ-кыргыз телләрендәге ил сүзләре җыелган.

Моның өстенә Радлов Алтайдан үзенең яңа хезмәт урыны булган Казанга эшләнеп бетмәгән бик күп материал китерде. Алтайдан кайткач, заграницага китеп, аннан кайткач, 1872 елның кышында татар, башкорт, кыргыз школаларына окружной инспектор итеп тәгаен ителде. Инде бу вакытта Радловның хезмәтләре фән галәмендә тәкъдир ителә башлаган иде: рус фән академиясе аның әсәрләрене нәшер итә дию Пед[агогика] университеты аңа фәнгә хезмәтләре өчен телләр фәне докторы гонваныны тәкъдим иткән иде.

[1] Гарби – көнбатыш.

# III

Радловның фәнни хезмәтендә икенче дәвер булган вә 1876 елдан 1883 елга кадәр дәвам иткән «Казан дәвере» – үткән Алтай дәверенә караганда да, соңгы Петроград дәверенә караганда да фәнни хезмәтләре ягыннан азрак җимеш биргән дәвередер. Моңа сәбәп исә – Радлов үзенең Казанда үткәргән дәверендә вакытының иң зур бер бүлеген Идел буе мөселманнарының ир вә кыз балалары арасында гарәп мәдәнияте тарату юлында хезмәткә бирүедер[1].

Радловның хәятындагы 11–12 ел дәвам иткән бу дәвердә басылган әсәрләре 12 генә булса да, болар арасында тюркология өчен бик әһәмиятлеләре бардыр: бу дәвердә чыккан төрле төрек телләрендәге авазлар вә авазларның бер-беренең мөнәсәбәтләре, аерым телләрдә

---

[1] Казанда Радлов, югарыда язылганча, татар, башкорт, кыргыз мәктәпләренең инспекторы итеп тәгаен ителгән иде. Мәсьәләне тикшергән җәмәгать адәмнәремездән берсенең шәһадәтенчә, бу көнгә кадәр шул халыкларга чыннан да мәгърифәт кенә бирүне максат итеп тоткан вә шул юлда бөтен көченә биреп тырышкан бер кеше бу урында булмаган. Радлов моның өстенә Казанда чагында Учительләр школасында да мөдир булып торган. Мәрҗани мәҗмугасында бу тугрыда түбәндәге сүзләр бар:

«1876 елда Казанда дарелмөгаллимин ачылды. Ошбу мәктәпне ачуны Радловның гына хезмәте диеп атарга ярый. Радлов татарлар арасында мәгърифәт таратуга, аларга русча яхшы өйрәтеп, бара-тора үз телләрендә фәнни мәгълүматны күбәйтү, хәтта милли әдәбиятны арттыруга да хезмәт итте. Радловның хезмәтендә үзенең заманында булган кешеләрнең сүзләренә караганда, аз гына булса да миссионерлык нияте юк иде. Ул Казанда дарелмөгаллимин ачарга уйлагач та, бу дарелмөгаллиминнән татарлар курыкмасын, татарлар арасында игътибары булсын өчен, анда мөгаллимнәрне татарларның үзләреннән куярга иҗтиһад итте *(тырышты).* Үзенең шул максадына бинаән, ул дарелмөгаллиминне ачканда ук, инспектор итеп, рәсман бертөрле дә образование алмаган, закон буенча инспекторлыкка правасы булмаган Гали әфәнде Мәхмүдовны куйды. Ачканның икенче елында ук Ибраһим әфәнде Терегулов һәм Шаһбазгәрәй Әхмәров кеби әфәнделәрне мөгаллим итеп куйды. Шул ук дарелмөгаллиминне үзеннән укып бетереп кенә чыккан Шакирҗан әфәнде Таһировны рәсем вә китап мөгаллиме ясады. Радлов дарелмөгаллимин ачарга карар кылгач та, үзенә яхшы таныш булган, үзе яраткан Мәрҗани хәзрәтләренә шул дарелмөгаллимингә дин мөгаллимлеге вазифасын тәкъдим итте. Шиһаб хәзрәт тә үз тарафыннан русча укуга мотлакан яхшы күз берлә караганнан, школаның ачылуына разый булып, Радлов кеби үзе яраткан вә игътибар иткән бер кеше тәкъдим иткәч, шул школада дин мөгаллиме вазифасын да кабул иткән... илх *(һәм башкалар)*». Мәрҗани с. *(сәхифә – бит)* 128–130. Әдипләремездән берсе бу тугрыда, Радловның Мәрҗани кеби татарның беренче милләтчесене чакыруы, аның татарларга ни дәрәҗәдә хәерхаһлыгыны күрсәтә дигән иде. *(Г. Шәрәф иск.)*

төрле урыннарда үзгәрешләре тугрысындагы чиксез күп хәзерләнү, уйлау вә эшләүне муҗәб[1] булган бу әсәр – бу көнгә кадәр үз бабында беренче вә бердәнбер диярлек әсәрдер. Нимесчә язылган бу әсәрнең мәдхәлендә[2] төрле төрек ыругларының торыш, тормышларындагы аермалары тугрысында мәгълүмат булып, әсәрнең хатимәсендә[3] төрек ыругларының бүленү рәвеше (классификациясе) тугрысында мәгълүмат бирелмештер. «Төрек буыннарының ил сүзе үрнәкләре» дигән әсәрендә Кара, Тубыл, Төмән якларында җыелган халык әдәбиятыннан гыйбарәт дүртенче томы да ошбу дәвердә нәшер ителгән.

Радловның татар мәктәпләрендә укыту өчен язылган «Белек» атлы кыйраәт китабы да ошбу дәвердә (1876 елда) басылмыштыр[4].

Радловның Гарби Себердә тора торган төрек халыкларының диннәре, этнографияләре вә Гарби Себердәге борынгы әсәрләр тугрысындагы ике бүлекле «Себердән» дигән нимесчә әсәре дә Казанда чагында язылган әсәрләрдән булганы күк, «Коман лөгате» нәшер ителүе мөнәсәбәте берлә нәшер иткән коман төрекләренең теле хакындагы әсәре вә башка берничә әсәрләре Казанда язылганнар.

Шулай итеп, Радлов Казанда үткәргән вакытында, бер яктан, Себердә эшләү берлә мәшгуль булса, икенче яктан, ул иске төрек телләреннән коман теле өстендә эшли башлап, үзенең фәнни тормышында өченче дәверене – иске төрек телләре вә язулары берлә танышу дәверене башлаган. Аның өстенә, югарыда әйтелгәнчә, Радлов Казанда чагында үзенең вә башка мөстәшрикъларның җыйган материаллары буенча хәзерге вә элекке төрек телләрене фәнни рәвештә тәфтишкә дә керешеп, төрек телләренең фонетикасын нәшер иткән.

1884 елда 47 яшендәге Радлов үзенең фәнни тормышының 25 нче елында Рус Фәннәр академиясендә әгъза итеп сайланып,

---

[1] Муҗәб – нәтиҗә.

[2] Мәдхәлендә – керешендә.

[3] Хатимәсендә – ахырында.

[4] Радловның татар мәктәпләре өчен язылган кыйраәт китабы мәктәпләремезнең вә ул вакыттагы мәдәниятемезнең түбәнлеге сәбәпле генә йитәрлек рәвештә мәктәпләремезгә керә алмаган. Хәзергә кадәр төрле язучыларыбыз тарафыннан бик күп исемнәр астында бастырылган кыйраәт китапларының күбрәге Радловның шул бабдагы беренче тәҗрибәсенә караганда, мөндәриҗә ягыннан да, тел ягыннан да күп түбәндерләр. Түбән уку йортларыбызның актык сыйныфларына, урта уку йортларыбызның беренче сыйныфларына кыйраәт китабы язучыларыбызның бу әсәргә дикъкатьләрене җәлеп итәмез. *(Г. Шәрәф иск.)*

бөтен вакытыны фәнгә хәзерләүгә имкян тапты. Бу вакыттан Радловның фәнни хәятында өченче дәвер – «Петроград дәвере» башлана. Радловның 1907 елда ук саннары йөздән арткан, басылган әсәрләренең күбе Петроградта басылганнар.

Нәшатлы[1], эшчән, һич армый торган ачык күңелле вә һәрвакытта киң фәнни интереслар вә планнар берлә мәшгуль Радловның хәятындагы Петроград дәвере эшләренең төрлелеге берлә аерым урын тота. Радлов монда да төрек телләре өстендә кабинет хезмәтләренә вакытының зур бер кыйсемене бирсә дә, моның берлә генә калмыйча, ул академиянең көндәлек эшләренә дә Петроградның антропология вә этнография музеенда Урта вә Көнтуышкы Азияне тикшерү комитетында эшләргә дә вакыт таба иде. Рус асаре гатика[2] җәмгыятенең Шәрык бүлегендә рус җәгърафия җәмгыятенең этнография бүлегендә эшләшә, Себер берлә танышу вә андагы торыш, тормышны яхшырту җәмгыятендә вә Петроградта буддалар мәгъбәде[3] төзү комитетында рәислек итә.

1886 елда Радлов, кырым татарларының вә караим төрекләренең теле, тормышы берлә танышу өчен, Кырымга вә гарби вилаятьләргә барды. 1893 елда Монголия вә Кытайга барып, андагы төрек-монголларының телләре, тормышлары берлә танышты. Мөстәшрикъларның Көнбаешкы Аурупада булып торган съездларының күбесендә булдыгы кеби, төрле-төрле мәмләкәтләрнең көтепханә вә музейларындагы төрек буыннарына (милләтләренә) гаид[4] материалларны вә әсәрләрне карау өчен хаслап күп мәртәбәләр заграницада булды. Боларның һәммәсе өстенә үз өендә яшь мөстәшрикъләр (тюркологлар, монголистлар, маньчжуристлар, китаецлар) берлә шөгыльләнеп, алар берлә бергә эшләргә вә аларның эшләрендә юлбашчы булырга да вакыт табып килмештер.

Радловның Казаннан күчкәннән бу көнгә кадәр эшләгән вә әле дә эшләмәктә булган хезмәтләре шулардыр.

Радлов Петроградта «Төрек буыннарының ил сүзе үрнәкләре»-нең үзе җыйган өч томын (5, 6 вә 7 нчеләр) һәм мөстәшрикъләрдан Кунш, Катанов вә Мошковлар җыйган материаллардан төзелгән та-

[1] Нәшатлы – гайрәтле.
[2] Асаре гатика – борынгы әйберләр.
[3] Мәгъбәде – гыйбадәтханәсе.
[4] Гаид – караган.

гын өч томын (8, 9 вә 10 нчылар) нәшер итеп, бу әсәрене ун томга тутырды: 5 томда – кара кыргызларның, 6 нчы томда – таранча төрекләренең, 7 томда – кырымлыларның, 8 томда – госманлыларның, 9 томда – Саян таулары тирәсендәге төрекләрнең, 10 томда Русиядәге Җәнүб гарбесендәге гагауз төрекләренең ил сүзләре җыелган. Болар һәркайсы шул халыкның үз телендә академия әлифбасы илә басылып, байтагында нимесчә йә русчага тәрҗемәләре дә басылган.

Радловның Петроград дәверендәге әсәрләре бигрәк төрек телләрендәге иске язылган әсәрләр тугрысындадыр.

Иң элек Радлов үзенең Казанда башлаган коман төрекләренең телене тәфтиш эшене дәвам иттереп, латинчада сакланган «Кодекс куманикус» дигән әсәр хакында дүрт хезмәтене нәшер итте. Аннан соң Касыймдагы кабер ташлары, сәлҗүк әшгаре Йиде су вилаятендә белгән ташлар хакында әсәрләр нәшер итте.

Соңрак чакларда Радловның фәнни хезмәтләре арасында иң мөһим урынны безгә мәгълүм булган иң иске төрек телләреннән Орхон вә Енисей язмаларының телләре вә уйгур төрекләренең телләрендә сакланган материалларны өйрәнү ишгаль итә[1].

Радлов бу материаллардан иң элек ислам кабулыннан соңгы төрек әсәрләренең иң искесе – милядидан соң XI йөздә язылган «Кутадгу билиг» дигән әсәрне өйрәнергә керешә. 1884 елда Австриянең пайтәхете Венага хаслап барып, «Кутадгу билиг»нең уйгур хәрефләре берлә язылган нөсхәсенең факсимилесене (һәммә сәхифәләренең фотография берлә алынып басылган рәсемнәрене) хәзерләргә кереште. 1890 елларда бу факсимилене вә «Кутадгу билиг»нең матбага хәрефләре берлә басылган мәтенен[2] нәшер итте. Нимесчә булган бу әсәрләрнең мәдхәлендә Радлов уйгурларга гаид аңа кадәр мәгълүм тарихи мәгълүматларны да биргән иде (бу мәдхәлнең русчага тәрҗемәсе дә академия тарафыннан нәшер ителгән). 1900 да «Кутадгу билиг»не академия әлифбасы берлә нәшер итәргә кереште. 1910 да «Кутадгу билиг»нең нимесчәгә тәрҗемәсе дә басылып чыкты. 1892 елда Рус Фәннәр академиясе Радловның идарәсе астында, Орхон суы буендагы иске төрек әсәрләрене тәфтиш өчен, бу һәйәт Монголиядәге иске төрек язылма ташларының вә башка борынгы әсәрләренең рәсемнәрене нәшер итте. Электән

[1] Өйрәнү ишгаль итә – өйрәнү белән шөгыльләнә.
[2] Мәтенен – текстын.

Енисей буенда табылган язу вә әсәрләренең дә рәсемнәрене нәшер итте (1893–1899).

Данияле тел галимнәреннән Вилһелм Томсон тарафыннан Орхон язылмаларының әлифбасы кәшеф ителү[1] берлә, Радлов бу язылмаларның тәрҗемәләрене нәшер итүгә кереште.

1899–1894 еллар арасында бу язылмалар тугрысында күп әсәрләр нәшер итеп, ул язылмаларны тәрҗемә эшендә вә аларның телләрен тәфтиш эшендә Радлов чиксез күп хезмәт күрсәтте.

Аннан соң Радловның дикъкатене Шәркый Төркестанда табылган уйгур әсәрләре җәлеп иттеләр. Бу әсәрләрнең әксәре[2] – будди, манихи, христиан уйгурларының дини әсәрләредер. Телләре ягыннан да, мөндәриҗәләре[3] ягыннан да әһәмиятле бу әсәрләр хакында да, Орхон-Енисей язылмалары тугрысындагы кеби, басылган хезмәтләрнең, мәкаләләрнең күбрәге Радловныңдыр.

Радловның төреклекне өйрәнү фәнендә гомуми әсәрләреннән бу Петроград дәверендә түбәндәге әсәрләрене күрсәтми узарга мөмкин түгел. Иң элек аның 1888 елда басыла башлап, 1811 елда гына басылып беткән, зур дүрт томдагы «Төрек телләренә гомуми лөгать китабы төзүдә тәҗрибә» дигән русча вә немесчә бергә бу әсәре – үз бабында мисалсыздыр. Бу әсәрен мөәллиф үзе дә тулы дип тапмый. Монда һәммә төрек телләре вә аларның бар сүзләре кермәгән. Шулай да булса, һәрбер төреклекне өйрәнүче (тюрколог) өчен, лябед[4], миндә булган бу әсәрлеге өстенә, башка бүлекләрдә эшләүче мөстәшрикълар өчен дә чиксез әһәмиятле әсәрдер[5]. Шулай ук «Төрек телләрендәге авазларның (звук) тарихы», «Төрек телләренең морфологиясене (сүзләрнең төзелеше – үзгәрешләре) тәгаен итү тугрысындагы фикерләр» вә «Төрек телләрендә исламга кадәрле язу ысуллары вә аларның төрек телләренә мөнәсәбәте» тугрысындагы немесчә әсәрләре – бабларында бердәнбер әсәрләрдер.

---

[1] Кәшеф ителү – ачылу.

[2] Әксәре – күбесе.

[3] Мөндәриҗәләре – эчтәлекләре.

[4] Лябед – әлбәттә.

[5] Татар теле, имлясы, әдәбияты вә әдәбият тарихы өстендә эшләүчеләремез, эшләргә уйлаучыларымыз өчен бу әсәрне хәзердән алып калу исләренә төшерәмез вә тәүсыя итәмез. Бу мәсьәләләр өстендә Радловның бу лөгать китабыннан башка җитди вә фәнни рәвештә эшләү мөмкин түгел диярлек дәрәҗәдәдер. *(Г. Шәрәф иск.)*

Радловның төрек илләренең борынгы нәрсәләре вә этнографиясе тугрысындагы әсәрләренең бу Петроград дәверендә басылганнарыннан нимесчә «Себердән» дигән әсәрне вә берничәгә бүленеп чыккан русча «Себердәге иске нәрсәләр» дигән әсәрне күрсәтеп китәмез.

Безнең монда Радловның төреклекне өйрәнү юлында ниләр эшләгәне тугрысында кыскача гына биргән мәгълүматыбыз бу фәндә Радлов хезмәтләренең әһәмияте никадәр икәнене күрсәтергә йитсә кирәк. Югарыда без төреклекне өйрәнү фәнендәге яңа дәверне «Радлов дәвере» дип атап, аның төп хосусияте бу көнге вә иске төрек телләрендәге материалларны җыю, бастыру вә аларны эшләп караудан гыйбарәт дигән идек. Бу дәвердәге төп юл, бер яктан, бу фәннең бу көнге хәле-тормышы берлә билгеләнсә, икенче яктан аның баш эшчесе булган Радловның шәхси хосусиятләре вә аның тәэсире берлә билгеләнә. Радловның көчле, кыю, чиксез-решительный табигате, аны яшьтән үк әлегә кадәр һич диярлек эшләнмәгән, ташланып калган төрек телләрен өйрәнү, аларны фәнни рәвештә тәфтиш – тәдкыйк итүгә омтылдырды.

Тормыш вә сәяси торышлары (хәл) үзгәрүе сәбәпле тиздән югалырга мәхкүм булган, әлегә кадәр җыелмаган ил сүзләре вә башка материалларның күплеге, төрлелеге, мөхтәрәм галимнең мөмкин кадәр тиз Аурупа фән галимене үзенең тапкан материаллары берлә таныштырырга ашыгуы, Радловның кыю табигатенең миниатюр детальләр өстендә акрынлап, җентекләп эшләргә юл куймыйча, киң мәйданда әсасларны эләктереп алырга вә фән галәменә әлегә кадәр мәгълүм булмаган бабларда гомуми булса да мәгълүмат бирүгә омтылуы кеби хосусиятләр Радловның бөтен хезмәтләренең, әсәрләренең төп сыйфатын ачып биргәне күк, хәзерге төреклекне өйрәнү фәненең гомуми хәрәкәтендә дә шул күренмәктәдер[1].

*Мәкалә «Кояш» газетасының 1917 елгы 5, 10 гыйнвар саннарында «Галимҗан Шәрәф» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр басыла.*

[1] Радловның хәяты вә әсәрләре тугрысында мәгълүмат алу өчен бу мәкаләдә кыскартылган Самойловичның «В.В. Радловъ – какъ турккологъ» (СПб. 1914 г.) дигән әсәреннән башка түбәндәге әсәрләрне тәүсыя *(киңәш)* итәргә мөмкин: «Ко дню 70-лѣтія В.В. Радлова» (Спб. 1907), «75-лѣтній юбилей дня рожденія академ. В.В. Радлова» (СПб. 1912 г.) (изданіе Святловского). *(Г. Шәрәф иск.)*

# ГАЛИМҖАН ШӘРӘФНЕҢ БЕРЕНЧЕ БӨТЕНСОЮЗ ТЮРКОЛОГИЯ СЪЕЗДЫНДА ЯСАГАН ЧЫГЫШЛАРЫ[1]

## АРАБСКАЯ И ЛАТИНСКАЯ СИСТЕМА ШРИФТОВ И ВОПРОС О ПРИМЕНЕНИИ ИХ ДЛЯ ТЮРКО-ТАТАРСКИХ НАРОДНОСТЕЙ. [2]

I. Более 90% населения всех тюркских народностей земного шара пользовались столетиями, пользуются и теперь арабской системой шрифтов, остальные же 7–8% (чуваши, крещеные татары, якуты и некоторые мелкие тюркские народности Сибири) пользовались несколько измененными русскими шрифтами, перешедшими к ним от русских вместе с православием; причем из числа тюркских народностей крещеные татары после Октябрьской революции, по постановлению своих конференций и съездов, приступили к практическому переходу от русской письменности к арабо-татарской, а якуты приступили к практическому переходу от русской письменности к латинской, являясь таким образом первыми пионерами среди тюркских народностей в вопросе о практическом массовом переходе к латинской системе. Для тюркских народностей, пользующихся арабским шрифтом, как из среды самих этих народностей, так и извне, бывали предложения со стороны отдельных лиц и групп, как о переходе к русской письменности (Алтинсарин у казак-киргиз, Метиелов, Кулаев у башкир, так. наз. Правила 31 марта Царского Правительства и т. п.), так и о переходе к латинской системе шрифтов (Фатх-Али Ахундов у азербайджанцев, Сагид Рамеев у татар и башкир и др.). В настоящее время среди самих тюркских народностей, пользующихся арабским алфавитом, совершенно не имеется заметных сторонников перехода к русской письменности. Сторонники же перехода к латинской системе шрифтов имеются

[1] Беренче Бөтенсоюз тюркология съезды 1926 елның 27 февраленнән 6 мартына кадәр Бакуда уздырыла. Татарстаннан съездга 9 кеше делегат итеп җибәрелә. Шулар арасында Галимҗан Шәрәф тә була.

[2] Доклад Г. Шарафа на Первом Всесоюзном тюркологическом съезде.

среди всех тюркских народностей, но почти ни один из них еще практически не сделал массового перехода к латинской системе. Итак, все тюркские народности имели и имеют в массовом употреблении или арабский или русский шрифт (чуваши и др.). Поэтому вопрос о принятии латинского шрифта, является вопросом не о выборе шрифта, а вопросом о замене существующих у них шрифтов; это обстоятельство я подчеркиваю, так как вопрос о замене шрифта в культурно-экономическом и общественном отношении имеет громадное значение, в особенности, для народностей, имеющих значительные культурные достижения в прошлом и настоящем, как турки Турции, казанские татары, азербайджанцы, узбеки, казак-киргизы и др. Замена шрифта в этих случаях связана: с переучиванием новой грамоте всех грамотных по прежней письменности, с необходимостью на ряд лет ведения параллельного издательства, обучения грамоте, создания навыков чтения и письма одновременно по двум письменностям, каковое продолжается, как у немцев ряд поколений; это потребует практической и методической переподготовки учителей, переоборудования типографий, словолитен и других технических и практических проявлений культурной жизни, а главное, потребует, в особенности в первые периоды, создания громадного перелома в общественном настроении широких масс населения данной народности. Чем выше данная народность в культурном отношении, чем больше у него культурных ценностей, тем будет труднее провести такую перемену шрифта, не только с экономическо-финансовой стороны, но и общественной. И так, вопрос о перемене шрифта, если приступить к ее массовому практическому осуществлению, является и для тюркских народностей, крупнейшей общественной и экономической задачей, к принципиальному и практическому разрешению которой можно приступать только с сознанием полной ответственности и взвесив все реальные, и только реальные, положительные и отрицательные стороны данной перемены шрифта. И поскольку у нас стоит вопрос не о выборе, а о перемене шрифта, что связано, как я указал, с громадными трудностями, то к предлагаемому вновь для замены латинскому шрифту мы должны относиться с большей строгостью и с большими требованиями, чем к существующим шрифтам, чтоб возместить принесенную жертву и оправдать затраченную энергию и средства.

Шрифт – дело техническое; здесь, действуя без достаточного расчета, вульгарно выражаясь, «можно сесть в калошу».

II. Шрифт является орудием взаимной передачи человеческой мысли и умственных достижений через время и пространство и, в качестве такового, является ценнейшим орудием культуры человечества; значение шрифта и письма несравненно выше значения других орудий того же назначения –телефона, телеграфа, радио и т.п., служащих для передачи только через пространство. Вопрос о выборе или перемене шрифта есть вопрос о выборе соответственного орудия той или иной системы. Для определения годности и сравнения относительной выгодности орудий различных систем, лучшими методами являются методы научной организации труда. Этот метод, путем изучения мельчайших движений и других моментов повторяемых миллионами людей десятки и сотни тысяч раз и интегрируя таковые, точно определяет сравнительную годность различных орудий и методов труда. Мы воспользуемся этими методами НОТ. Точки зрения изучения различных систем шрифтов применительно к тому или другому языку должны сводиться к следующим моментам: 1) Годна ли вполне та или другая система шрифтов для полной и нормальной передачи мысли на данном языке письменности, т.е. имеет ли она достаточный запас графем для практической звуковой передачи языка и, если этот запас недостаточен, имеется ли возможность его пополнения без нарушения системы; 2) при какой системе шрифта быстрее идет самый процесс чтения печатного и рукописного текста; 3) сравнение их с точки зрения скорости процесса письма; 4) удобство типографской техники, способность применения к ним усовершенствований техники; 5) сравнительная вместимость шрифта в печатную страницу, т. е. определение стоимости продукции напечатанной книги при одной и той же чтимости; 6) количество лиц, уже умеющих пользоваться данной системой орудия, т. е. % грамотности по этой письменности среди населения, говорящего на данном языке, сравнительная доступность овладения, изучения для неграмотных и для будущих поколений, а также степень наличия на этом языке по данной системе письменности материала для чтения; 7) момент удобства для межнационального и международного сношения и полезность для взаимных культурных влияний и 8) внешняя изящность букв.

III. Исходя из различных реальных и предполагаемых недостатков арабской системы шрифтов, у многих из нас установился взгляд, что арабские буквы в существующем виде с четырьмя типографскими начертаниями каждой буквы не могут вполне удовлетворять нашим культурным нуждам, вследствие чего поднят вопрос о реформировании или замене арабской системы латинской системой шрифтов.

Что касается сторонников замены, то все виднейшие их представители предлагают принять латинский алфавит, не изменяя принципов его употребления в Западной Европе (графическая прямолинейность начертаний, сохранение заглавных и строчных букв, сохранение значительной разницы в начертаниях типографских и рукописных букв и т. п.), разбиваясь между собой только в отношении установления начертаний букв для звуков тюркских языков, в случаях отсутствия латинских букв, с соответствующим звуковым назначением. Оставляя в стороне сторонников сохранения старых шрифтов при четырех начертаниях, укажем, что сторонники реформы арабского шрифта разбиваются или, вернее, разбивались на пять течений: 1) приближение того или иного начертания каждой арабской буквы к начертанию какой-либо латинской или русской буквы, причем вводятся строчные и заглавные буквы, печатный шрифт отличается от рукописного, строка идет справа налево (представителями были: известный типограф в Казани Н. И. Харитонов, Шериф Манатов и др.), к ним же близко стоит проект братьев Рамеевых, графически разработанный тов. Акчокраклы, и отличающийся от первых проектов сохранением рукописного шрифта в прежнем виде совершенно без изменения; 2) сторонники принятия в качестве единого начертания прежних, так называемых, отдельных начертаний арабских букв, без изменений или с некоторыми изменениями с одинаковыми начертаниями, как для печати, так и для рукописи (проекты Исмагил Хакки Маласлы, Ахмеджан Мустафа, Гимад Нугайбек и др.); 3) сторонники создания двух начертаний: прежних начальных и отдельных букв, с употреблением вместо прежних средних начертаний – начальных, и вместо конечных – отдельных (Проект газеты «Танин», Тукаева, Бурнашева); все 3 проекта осуществлены в типографиях; 4) предложение о принятии в качестве единых т[ак] н[азываемых] начальных начертаний прежних

шрифтов (Рахманкулов, Алпаров, Гади Максудов, Байтурсун, Идрисов и др.), некоторые из них осуществлены в типографиях, особенно широкое распространение в заголовках и учебниках имели шрифты по проекту Идрисова, и 5) предложение о принятии в качестве единых тех же начальных начертаний, но с прибавлением первой половины средних начертаний, напр., буква «б» с прибавлением первой половины «т» в слове «битди» بتدى (проекты Г. Шарафа и Тукаева). Не имея здесь возможности останавливаться на критическом разборе отдельных предложений, ограничусь указанием, что последнее – пятое предложение, новейшее по возникновению, является результатом использования всех прежних опытов в направлении реформы арабских шрифтов и дает возможность сохранить почти полностью имеющиеся у грамотного населения навыки по процессу чтения и письма, устраняя вместе с тем все главнейшие недостатки переформированных арабских шрифтов. Крупные афишные шрифты по этой системе уже осуществлены в Уфе Тукаевым и введены в практику в ряде местностей СССР, словолитни Казани заняты в данное время заготовкой соответствующих типографских шрифтов по проекту Шарафа.

При сравнительной общей оценке системы шрифтов, мы будем сравнивать латинско-русскую систему шрифтов с основной арабской системой. При конкретных и практических сравнениях же буду сравнивать латинский шрифт в том виде, как он принят в Азербайджане, с принятой в Татреспублике системой реформированных шрифтов.

IV. Приступая к сравнению арабской и латинской систем шрифтов, начнем с выяснения вопроса о том, насколько та и иная система шрифтов может служить для достаточно точного обозначения слов тюркских языков в практической письменности, поскольку у нас письмо звуковое. Этот момент сводится к вопросу о том, какая система шрифтов имеет достаточный запас графем, т. е. буквенных начертаний, соответствующих основным звукам того или другого тюркского языка. Арабский алфавит имел раньше 28 букв, тюркские народы ввели, еще задолго до революции, еще 8 букв, таким образом, общее число основных букв дошло до 36, из них 4 служили для обозначения гласных, остальные – согласных звуков.

Запас буквенных начертаний для согласных по арабским шрифтам достаточен для обозначения, в письме всех соответствующих звуков языка и их начертания и звуковые значения установились однообразно у всех тюркских народностей. Что же касается гласных звуков, то относительно их обозначения можно применять два метода: 1) метод использования момента сингармонизма – при этом приходится дополнять наличные буквы одним знаком для указания твердости или мягкости слова и 2–3 начертаниями для гласных; 2) метод парных гласных, возлагающий на гласные звуки задачу указания также твердости или мягкости всего слова в этом случае придется прибавить к существовавшим раньше еще 5–6 букв для тех гласных, по которым недостает знаков. Опыт применения того и другого метода был почти у всех тюркских народностей. Эти опыты подтвердили возможность установления для тюркских языков на основе арабской системы, не только возможность установления близко к фонетической практической орфографии, но даже академической транскрипции (казанский проект).

Основная латинская азбука имеет 26 букв, в этом числе 6 гласных и 20 согласных. Опыт применения латинского алфавита для различных тюркских народностей показал, что азербайджанцы из 34-х букв для своей письменности только 19 (56%) сумели взять непосредственно из латинского алфавита, не меняя начертания и значения, в 7 случаях (21%) они взяли латинские начертания с изменением обозначаемого ими звука, в остальных 8 случаях (23%) изменили и начертания и значения, в том числе частью взяли русские начертания. У якутов из 34-х букв, только 17 (47%) соответствуют латинским по значению и начертанию, 2 соответствуют по начертанию, но не по значению, остальные же 17 (47%) отличаются от латинских, как по начертанию, так и по значению; проект латинистов по применению к башкирскому и татарскому языкам – только в 19 случаях из 35 (54%) сумел сохранить латинские буквы, без изменения их начертаний или значения. Итак, латинский алфавит без изменения значений и начертаний удовлетворяет только от 47 до 56% звуков тюркских языков, тогда как по арабской системе приходится для писаний по той же орфографии прибавлять только 15% новых или измененных начертаний. Итак, запас графем-букв, для обозначения звуков и слов тюркских языков и для установления

нормальной практической орфографии, у арабской системы более благоприятный, чем у латинской. Если дополнить соответствующими знаками, то и по арабской и по латинской системе можно писать по какой угодно точной орфографии. Так что вопрос об орфографии вопрос совершенно другого порядка. Все северные тюрки изменилии свою орфографию и ряд лет уже пишут или фонетической или близкой к фонетической орфографией. В печатных материалах же, подготовленных к нашему Съезду, и в трудах по этому вопросу, написанных сторонниками принятия латинского шрифта, – почти все сторонники латинской системы шрифтов всегда путают вопрос орфографии с вопросом о шрифте. Потому мы подчеркиваем, что эти вопросы совершенно разного порядка, и что и по латинской системе можно иметь очень плохую орфографию, как у англичан и американцев, а также и по арабской системе можно иметь точную фонетическую орфографию, как у казаков, башкир и татар. Если среди нас имеются народности, а азербайджанцы остаются уже таковой единственной тюркской народностью в СССР, совершенно почти неподвижной, другими словами консервативной в отношении реформы орфографии по арабской системе, то это еще не дает право возлагать на систему шрифта вину за то, что они не хотят улучшать и реформировать свою орфографию. Это замечание относится и к той части ленинградских и московских русских профессоров, давших заключение о признании русской наукой «полной непригодности арабской системы шрифтов для передачи звуков турецкого языка»[1]. Трудно объяснить такое заключение, тем более после имеющихся уже опытов и практики в этом направлении. Если у кого плохая орфография, то нужно направлять орфографию, а не поднимать из-за этого вопрос о перемене шрифта, так как иначе можно очутиться в положении Японского Комитета по введению латинской письменности, истратившего массу энергии, достойной более положительного применения, а также убившего 90 миллионов фунт стерлингов денег на это дело, и в конце концов через несколько лет в 1914 году прекратившего свое существование. (См. бакинский журнал معارف مذنيت 1923 года № 11 стр. 42.)

[1] *Агамали Оглы.* Неотложные культ[урные] нужды тюрко-татарских народов. Стр. 73, а также см. сборник «В борьбе за новый алфавит». Москва, 1926 года. (*Примеч. Г. Шарафа*)

V. Переходим к моменту скорости процесса чтения. Сначала остановимся с точки зрения процесса чтения печатного текста. Когда мы читаем, то мы слова разбираем не по отдельным буквам, а своим зрением воспринимаем целое напечатанное слово, или даже два небольших слова и узнаем общее начертание этих слов, так же, как узнаем мы отдельные знакомые предметы и лица. Написанные или напечатанные слова, по какой бы системе шрифтов они не были обозначены, являются теми же самыми иероглифами, как китайские и египетские, и отличаются от последних только системой конструкции рисунка иероглифических знаков: если в иероглифах для обозначения понятий «он» рисовали руку с указательным пальцем, то для обозначения того же слова «он» звуковым письмом, мы составляем рисунок, состоящий из особых двух маленьких значков, условно отвечающих соответствующим звукам, входящим в состав данного слова. Итак, грамотный человек читает не отдельные буквы, а сразу целые слова, узнавая общее обозначение их, т.е. их иероглиф, и на этом принципе основывается и так называемый американский метод обучения грамоте, метод целых слов. Чем характернее общий рисунок – иероглиф того или другого слова, тем он скорее схватывается нашим зрением при процессе чтения. Итак, с точки зрения процесса чтения, установленного и общепризнанного соответствующими специалистами, быстрая охватываемость, чтимость слов определяется не начертанием отдельных букв, входящих в состав слова, а только характерностью рисунка всего данного напечатанного слова в совокупности, отдельные же буквы, входя в состав слова, играют служебную роль только в отношении усиления и ослабления характерности всего иероглифа данного слова среди других слов.

Буквы в латинской системе шрифта представляют из себя, большею частью, рисунки из прямых линий частью сочетающихся с рисунком «о» и вписаны в прямоугольники. Здесь печатная строка располагается между двумя параллельными линиями, и каждое слово состоит, грубо выражаясь, из отдельных кирпичиков, насаженных вертикально. Поэтому иероглифы слов отличаются между собой, большей частью, только числом этих кирпичиков и разницей между рисунками, вписанными в этих кирпичиках. Только часть латинской системы букв, как d, b, 1, t, h, p, q, i, имеют те или иные выступы,

или надстрочные знаки-точки, лежащие за параллельными линиями строки. Известный профессор Мейман и другие ученые по экспериментальной педагогике и по педологии рядом точных опытов установили, что охватываемость отдельных слов нашим зрением, другими словами, быстрота чтимости отдельных слов, напечатанных по латинской системе, определяются наличием и количеством в них букв, начертание которых имеет части, выходящие вверх или вниз за пределы двух параллельных линий, а также букв, имеющих точки и надстрочные знаки, как «i, ä, ö, ü, t, b, d» – в немецком языке[1]; так международное слово mimimum без точек над «i» читался бы гораздо труднее, чем при этих точках.

Арабские же буквы не имеют двух параллельных линий и прямоугольников; здесь имеется только одна основная линия строки, от которой вверх и вниз идут разнообразные по размерам прямые и кривые линии, снабженные в большинстве случаев точками и значками над или под строкой. Вот это обстоятельство, именно наличие точек, отсутствие кирпичиков, наличие кривых и прямых линий, отходящих от одной основной линии, дают характерность каждому отдельному слову-иероглифу, облегчая своей характерностью в том или ином направлении моментальное нахождение и припоминание знакомых образов. Совершенно так же, как мы своих знакомых, ходящих с палкой или в шляпе с широкими полями, узнаем сразу среди массы публики, так же характерные слова, написанные арабскими буквами, мы узнаем среди других слов, характерных уже в других отношениях, точки сверху, снизу, хвостики вверх и вниз отходящие от основной линии строки. Таким образом, графический характер арабской системы шрифтов, если мы будем исходить от установленных наукой принципов процесса чтения, в отношении более скорой чтимости является более благоприятным, чем в латинской системе.

Правильность же законов о процессе чтения мы можем проверить и без приборов. Так слово «джан» (душа) мы привыкли видеть в книгах ввиде جان или جاذ в слове جانلى , если мы это слово напишем в измененном виде ج ا ن, т. е. отдельными начертаниями тех же букв, то мы не узнаем этого слова, так как в арсенале иероглифов

[1] *Мейман.* «Лекции по экспериментальной педагогике» т. III, лекции 14-я и 15-я. (*Примеч. Г. Шарафа*)

знакомых нам слов, не имеется такого иероглифа-слова. Трудность для непривычных чтения газеты хотя бы «Jeni Jol», напечатанной латинскими буквами, заключается не в том, что они плохо знают латинские буквы, они может быть, знают их и очень хорошо, но иероглифы слов, состоящие из латинских букв, в совокупности им ещё не знакомы, и они читают как посетители пункта по ликвидации безграмотности, знающие отдельные буквы, но не привыкшие сочетать их в иероглифы целых слов. Это обстоятельство, если с одной стороны подтверждает иероглифичность наших писаний, с другой стороны указывает, что после перемены шрифта, чтоб заново научиться нормально читать и писать, нам недостаточно ознакомление с отдельными буквами, а нужно создание в своей памяти целого арсенала иероглифов по новой системе, т. е. создать у себя заново процесс чтения по ней. Если даже мы не будем исходить от процесса чтения, а исключительно от начертания букв, то едва ли имеет смысл обвинение арабских шрифтов в однообразии (напр. отличие букв для звуков – *б, п, т, н, и* – между собою только надстрочными и подстрочными точками), если примем во внимание, что взамен их предлагается латинская система, в которой, по применению ее в Азербайджане буквы *o, ө, d, b, p, q, g, e, ə, c* или *i, n, m, ņ, u, h, r, e* в основе своей исходят от «о» и «i» и являются их видоизменением посредством дополнительных палочек и хвостиков, и вырезывания частей в «с», «е». Оба алфавита мирового значения, латинский и арабский, исходят от немногих основных нот, и это сделано не зря, а в целях облегчения усвоения приемов процесса письма, к которому мы подойдем ниже.

Что же касается заявления о том, что арабская система своими точками и значками является вредной для глаз и негигиеничной, сообщаемых в представленных вниманию всемирного Тюркологического Съезда печатных материалах, то нужно сказать, что они основываются на представлении, как будто тюрко-татары читают не по нормальному процессу чтения, а вместо этого считают сколько и где точек поставлено. Для того, чтоб проверить влияние для глаз той или иной системы шрифтов, достаточно прибегнуть к приему глазных врачей, взять какой-нибудь текст, напечатанный шрифтами одинаковой крупноты по латинской и арабской системе, и одновременно издали приближать их к себе, человек достаточно грамотный

по обоим шрифтам, как видно из многократно поставленных опытов, текст по арабской системе разбирает на более дальнем расстоянии. Лицам, достаточно грамотным по обоим системам, можно еще над собой сделать такой опыт: один вечер попробовать долго читать книжку напечатанную арабскими шрифтами, другой вечер читать книгу напечатанную по латинской системе или на русском языке, что мало изменит точность опыта. И вы увидите, следя по часам, что глаз начинает уставать скорее при чтении по латинской системе. Я не буду затруднять ваше внимание еще рядом возможных простейших опытов в этом направлении, все они приводят к одним и тем же результатам; некоторые из них опубликованы мною еще в 1923 году[1].

На ложность утверждения, что арабские шрифты вредны для глаза, указывает и то обстоятельство, что среди народов Востока, даже среди лиц, занятых всю жизнь чтением и письмом по этой системе шрифтов, лица носящие очки встречаются чрезвычайно редко; если мы сами носим очки, то это является для нас в значительной степени подарком от русской системы шрифтов.

Сообщу ещё об одном опыте, поставленном в 1922 году в Казани над 40 учениками татарского педагогического техникума и над таким же количеством учеников русского педтехникума, с соблюдением нормальных условий опыта. Опыт имел целью выяснение скорости чтения и письма тех и других на родном языке, у первых по арабской, у вторых по русской письменности, текста в 1000 типографских знаков. Опыт подтвердил, что у татарских учеников, несмотря на их несколько меньшую общую подготовку и старые нереформированные шрифты, скорость чтения была в среднем на 26% выше, а скорость письма на 32% выше, чем у русских учеников. Что же касается басен о превращении فازتلره в فاقبلر и т. п., то они являются веселыми анекдотами, а не историческими фактами, что можно сразу уяснить, если вдуматься в их содержание.

Несколько слов скажем относительно процесса чтения рукописного текста. Здесь остаются те же законы. Но поскольку в арабской системе слова имеют в печати то же или близкие начертания к рукописным, то создавшийся процесс чтения над печатным текстом переносится и на рукописный. Поэтому нормальный рукописный

[1] См. журнал «Мaариф». Казань, 1923 г., №№ 2, 3–4. *(Примеч. Г. Шарафа)*

текст по арабской письменности, кем бы он ни был написан, всегда разбирается легко, тогда как написанное латинскими и русскими буквами, очень часто, даже самим написавшим, разбираются с трудностью; и здесь арабскому шрифту помогает характер графики, система точек, а также общность знаков для рукописного и печатного текста. Несмотря на это, латинисты частью ставят в вину арабскому шрифту то, что у него не имеется отдельных от рукописных начертаний для типографии. В странах же с латинской системой со стороны отдельных лингвистов и педагогов в их трудах нам приходится слышать обратные предложения о сближении печатного текста к рукописному. Так, известный языковый профессор Томсон, в своем труде по теории русского правописания, высказывается о желательности введения курсива, близкого к рукописному, в качестве основного типографского шрифта, в целях создания общего процесса чтения, а также, как он говорит, для избежания прямоугольных типографских букв, затрудняющих процесс чтения, более закругленным типографским курсивом[1]).

VI. С точки зрения скорости письма вопрос можно исследовать по НОТ в следующей плоскости: 1) направление движения руки при процессе писания в латинской системе идет большей частью как в буквах «о, в, е, и» против часовой стрелки, этим же объясняется направление слева направо. По арабской же письменности как в буквах «و، ر، ب، س» движение руки при писании букв и слов идет преимущественно по часовой стрелке, поэтому и строка идет справа налево. Если мы будем следить, как рабочий за станком или швея вертит рукой свою машину, то увидим, что все это делается движениями по часовой стрелке. Вообще, когда в процессах труда приходится делать массовые круговые и овальные движения, когда шьют иголкой, где вьют веревку и т. п., всегда рука человека делает массовые движения по часовой стрелке, тогда как, если например, машину начнет вертеть в обратном направлении, то рука весьма скоро устает. Известный педагог Блонский, в своем труде «Педология в массовой школе»[2] говорит, что русские дети в первом

[1] См. *А. Томсон* «К теории правописания и методологии преподавания его» // «Летопись Ист. Фил. Об-ва при Новор. Ун-те», XI. Одесса 1914 г., стр. 216–217 и 228. *(Примеч. Г. Шарафа)*

[2] Москва, 1925 г. стр. 3–7. *(Примеч. Г. Шарафа)*

месяце обучения письму пишут буквы справа налево, т. е. по часовой стрелке, иногда даже у них слова получаются обратные нормальному русскому, получается так называемое детское «зеркальное письмо». Он объясняет это явление тем, что у людей, а у детей в особенности, лучше развиты мелкие мускулы, подвигающие руку и пальцы в этом направлении; он дает целый ряд указаний, какими приемами искусственно нужно развивать у детей мускулы для движения в обратном направлении, т. е. против часовой стрелки; в частности, как подготовительный прием, он предлагает заставлять детей вить веревку в обратном направлении тому, как это делается обычно. Итак, многие латинисты обвиняли арабский шрифт за то, что он пишется справа налево. Право же, в этом виновата не арабская система, а природа человеческой мускулатуры. Нельзя же ставить ей в вину то, что и в отношении направления движений в письме она соответствует законам организации труда!

Почему же культурные народы Запада пишут иначе? Ответ простой: деды их писали так, устанавливалась традиция. Первоначальное же установление у прадедов письма слева направо, относится ко временам, когда ещё ни бумаги, ни карандаша, ни перьев не было, а писали они почти исключительно на мраморе, вырезывая буквы, и направление письма, как я думаю, установилось у них в зависимости от орудий письма. Когда же появились бумага и перо, дальнейшие поколения не захотели переменить направления, хотя бы на естественное.

Итак, направление мелких движений письма и связанное с ним направление строки в арабской системе более естественное и соответствующее нормальной мускулатуре человека, освобождающее от таких трудовых процессов, как вить веревку в обратном обычному направлении.

От направления движения переходим к качеству движения. Латинская система требует для каждой буквы крупных движений, тогда как арабские буквы, как и стенографические знаки, превращаются почти в одни зигзаги. Этот момент ускоряет письмо, потому она и принята стенографией, которая несмотря на то, что возникла в западных странах, не приняла приемов латинского письма со штрихами полного оформления. Мелкие движения, хотя представляют несколько большую трудность при обучении беглому письму,

но наши татарские учителя знают очень легкий выход из этого положения: на первых порах они детям предлагают писать крупными буквами и только. Теперь переходим к вопросу о количестве движений. Если написать татарское слово بالتا «балта» (топор) по курсиву рокга арабской письменности, требуется, включая и отдельные движения и отрывы руки для точек, всего 8–9 импульсов движения руки, для написания того же слова латинскими буквами потребуется 13–14 импульсов движения. Опыты над значительным количеством слов показывают, что в среднем латинская система требует для написания одного и того же текста на 30–35% большего количества импульсов движений, чем при писании того же текста арабской системой.

При указанных трех преимуществах, арабское письмо имеет и некоторые недостатки: это наличие точек и надстрочных знаков и букв, не соединяющихся с последующей буквой того же слова. Но, если со включением отрывов руки от основных начертаний для перехода к точке, а также движений на установку точки, а также обратного движения от точки к основной строке, все же получается быстрота письма большая на 30%, чем при латинской системе, то отрывы для точек вполне можно простить арабской системе. Чтобы удостовериться в этом, лицам одинаково свободно пишущим по обоим системам предлагаю взять какой-нибудь небольшой текст достаточно характерный для данного языка, и с секундомером на столе, в течение двух или трех минут, писать и повторять все тот же текст, сначала по одной системе, потом по другой. Такие многократно поставленные опыты подтвердили характерность результатов, указанных выше опытов в казанских педтехникумах, указывающих на значительно большую скорость письма арабским шрифтом. Исходя из больших преимуществ арабской системы письма от латинской, в Казани в данное время тов. Нугайбек, много занимавшийся раньше вопросами шрифта и орфографии, занят приспособлением стенографии к татарскому языку справа налево; первые опыты обещают дать желательные результаты.

VII. Переходим к сравнению систем шрифтов с точки зрения типографской техники: латинская система шрифтов имеет по два начертания каждой буквы для типографии: заглавные и строчные, и вполне приспособлена для типографской техники, для наборных и

Миллион ярым башкортларның 800 мең кадәресе – иске (вотчинник, гасабә[1]) башкортлар. Калганнары соңгы гасырларда башкорт арасына күчеп утырган һәм башкорт исемен алган татар, мишәрләрдән гыйбарәт гасабә башкортлар арасында да тарих, татар һәм башка төрек элементларының күп булуын күрсәтә.

Халык телендә мишәр дип аталып йөргән Нижгород, Пенза, Сарытау, Сембер татарлары 1897 елгы гомуми переписьтә дә, аннан соңгы земстволар тарафыннан ясалган переписьләрдә дә үзләрен татар дип яздырганнар; рәсми статистика да аларны шулай дип таный. Шуңа күрә, югарыдагы 200 мең мишәрләр санына алар кермәгән. Бу мишәрләр исә – элек тә башкорт кантоннары булган җирләрдәге мишәрләрдер. Гомумән, башкорт, мишәр, типтәр истыйляхлары[2] элек тә башкорт кантоннары булган җирләрдә генә сакланганнар. Бу урыннарда да, бу истыйляхлар бер милләт йә ыруг исеме булып түгел, бәлки казачий, крестьян, инородец дигән кебек бер сословие исеме булып кына сакланганнар.

Иске хөкүмәт, бу исемнәр белән җир, урман биләүдәге, салым (налог) түләүдәге, төрле капиталлар белән файдаланудагы вә барыннан бигрәк гаскәри хезмәт ысулындагы аермаларны бәйләгән.

Кемнең бу сословиеләрдән кайсына кереп калуына да аның башкорт кантоннары тирәсенә кайчан күчүе һәм нинди ысул белән күчүе (хөкүмәт тарафыннан күчерелү йә үзе теләп күчүе) һәм күчүченең байлык-ярлылыгы кебек хәлләр сәбәпче булган. Башкортларның төрле чобалу, баш күтәрүләре дә нинди дә булса милли әсаста[3] булмыйча, сословный мәсьәләләр, җир, налог һәм гаскәр хезмәте үтәү мәсьәләләрендәге имтиязларын[4] саклау өчен булган; XIX гасырның соңгы яртысында башкорт, мишәр вә типтәрләр гаскәре төзелеш, налог түләү һәм идарә эшләрендә башка крестьяннар белән

---

[1] Гасабә – кабилә.
[2] Истыйляхлары – атамалары, терминнары.
[3] Әсаста – нигездә.
[4] Имтиязларын – өстенлекләрен.

тигезләнеп, крестьян хәленә күчерелгән булсалар да, башкортларның җир, урман биләү мәсьәләләрендә башка крестьяннардан кайбер аермалары калганга һәм электән калган берникадәр башкирский капиталлары булганга, боларның башкорт исемнәре һаман сакланып килгән. Шуларга ияреп, бер агым белән боларның күршеләрендә типтәр, мишәр исемнәре дә сакланган.

Башкорт кантоннарыннан башка җирләрдә бу исемнәр белән андый сыйнфый аермалар бәйләнмәгәнлектән, бу якларда башкорт, мишәр, типтәр исемнәре югалып, һәммәсе дә татар исеме астында кушылганнар.

Татар, башкорт, мишәр, типтәрләрнең шивәләрендә аермалар бераз булса да, ләкин бу шивә аермалары бик кечкенә булу өстенә, алар тугрыдан-тугры бу исемнәрдә йөргән группалар белән дә бәйләнмәгән.

Мәсәлән: Минзәлә йә Бөгелмә өязләрендәге башкортлар белән татарлар, йә типтәрләр сөйләшүе арасында һичбер аерма юк диярлектер. Верхнеурал, Орски өязләрендәге башкортларның сөйләшләрендә кайбер аермалар булса да, бу аермаларның Казан сөйләшенә мөнәсәбәте Минзәлә, Бөгелмә башкортларының сөйләшенә мөнәсәбәте кебек үктер. Һәрхәлдә, бу аерма Казан татары сөйләше белән Касыйм татары сөйләше арасындагы аермадан артык түгел. Әгәр шәркый башкортларның сөйләшләрендәге хосусиятләр әдәбиятка кертелсә, бу хосусиятләр башкортларның үзләреннән дә күбесенә бик ят булыр иде.

Шуңар күрә, башкортларның үз араларыннан чыккан эшчеләре дә (бөтен карьерасын башкортны татардан аеруга корганнарына чаклы) язуда әсәрләрендә уртак әдәби телне (татар телен) кулланалар.

Хәзерге көндә фән кашында, гомумән, социалист вә коммунистлар кашында әдәби тел вә шул телдәге мәдәният әсбабы милләтнең әсасы итеп таныла.Татар, башкорт, мишәр, типтәрләр дә – барысы бер тел вә бер мәдәният астында җыелганлыкларыннан һәм иң кире сепаратистлары да әдәби телне аеру авантюрасына кушылмаганлыкларыннан, без аларны бер милләт итеп кенә карый алабыз. Бу милләтне татар-башкорт милләте, татар милләте, Эчке Русия вә Сибирия мөселман төрек-татарлары, шималь төрекләре кебек исемнәрдән кайсы белән булса да атарга мөмкин. Эш исемдә түгел.

Менә шул татар-башкортлар иске Русиянең төрле губерналарында түбәндәге санда таралганнар[1]:

Уфа губернасында – 1 616 000,
Казан губернасында – 935 000,
Оренбург губернасында – 537 000,
Самар губернасында – 421 000,
Пермь губернасында – 219 000,
Вятка губернасында – 211 000,
Сембер губернасында – 201 000,
Сарытау губернасында – 155 000,
Пенза губернасында – 95 000,
Әстерхан губернасында – 80 000,
Нижгород губернасында – 62 000,
Уральски областенда – 50 000,
Тамбов областенда – 38 000,
Екатеринслав областенда – 35 000,
Аурупаи Русиянең башка губерналарының барысында – 125 000,
бөтен Себердә – 175 000,
Урта Азиядә (Төркестанда) – 52 000,
Кавказ вә Кырымда – 38 000.

Бары: 5 035 000.

Бу җәдвәлдән бөтен татар-башкортларның 4 миллион 150 мең кадәресе (82 ярым проценты) Уфа губернасында һәм аны тирәли чолгап алган Казан, Сембер, Самар, Оренбург, Пермь, Вятка губерналарында икәнен күрәбез.

Татар-башкортларның бу губерналарның кай җирендә торуларын тикшерсәк, аларның Уфада бөтен губернага таралып утыруларын, Казан губернасының Уфага чиктәш шәркый кыйсемендә торганлыкларын, Оренбургның Уфага чиктәш гарби кыйсемендә торганлыкларын; Сембер, Самара һәм Вятка вә Пермь губерналарындагы татар-башкортларның күбрәге һәм тыгызрак булып, бу губерналарның Казан һәм Уфа губерналарына чиктәш волостьларында торганлыкларын күрәбез.

[1] Бу саннар перепись, земство һәм волость идарәләре статистикасы буенча һәм кыйсьмән Уфадагы Диния нәзарәтендәге мәгълүматлар буенча 1918 ел башына хисапланган. *(Г. Шәрәф иск.)*

Уфа губернасының берничә рус волостьларын чыгарып калдырып, Казан, Сембер, Вятка губерналарының татарлар торган һәм күпчелек тәшкил иткән бер-беренә чиктәш җирләрен алып, Оренбург, Самара, Пермь губерналарының да Уфага чиктәш һәм татар-башкортлар күпчелектә булган җирләрен кертеп, бик боргаламыйча гына шундый бер хөдүд[1] сызарга мөмкин ки, бу хөдүднең эчендә бөтен халыкның 54–55 процент кадәресен татар-башкортлар тәшкил итәләр һәм Русиядәге бөтен татар-башкортларның 3 миллион ярым кадәресе яки 69–70 проценты шуның эченә кереп бетә.

Калган татар-башкортлар бөтен Русиягә таралган булганлыктан, шул микъдардан артык татар-башкортларны хөдүд эченә алырга тырышканда, башка халыкларны да күп итеп кертергә тугры килә һәм татар-башкортларның проценты кимеп, хөдүд эчендә тәэсирләре дә кимергә, азаерга тиеш була. Һәр татар-башкортка үз өлкәсенә кереп калу матлуб[2] булганлыктан, алар күпчелек тәшкил иткән вә хөдүдкә тоташкан җирләрнең җөмһүрияткә керми калуы хаклыкка да, милләтнең хөдүд эченә кергән вә керми калган кисәкләренең интересларына да каршы булганлыктан, өлкәнең хөдүден мәгълүм даирәдән тарайтырга да мөмкин түгел иде.

Шул сәбәпләрдән, татар-башкорт иҗтимагый мөәссәсәләреннән[3] кайсы гына татар-башкортларның милли мәсьәләләрен тупрак (территория) белән бергә хәл кылырга керешмәсен, һәммәсе әсасан бер үк хөдүдләрдә туктыйлар иде. Бу хөдүдләр Уфада җыелган Милләт Мәҗлесе тарафыннан әсасан билгеләнеп, Тупраклы Мохтарият һәйәте[4] тарафыннан тәфсыйлле рәвештә эшләнгән хөдүдләр иде. 2 нче хәрби съезд[5] да шул ук хөдүдләрне кабул итте. Бу хөдүдләрне җимерү өчен Грасис тарафыннан чакырылган II губерна съездындагы мөселман сул социалистлары фракциясе дә шул ук хөдүдләрне кабул итте. Хөдүдләр ляихәсе[6] белән якыннан танышканнан соң, башында Мулланур Вахитов торган Мәркәз Мөселман Комиссариа-

[1] Хөдүд – чикләр.

[2] Матлуб – таләп ителгән.

[3] Мөәссәсәләреннән – оешмаларыннан.

[4] Һәйәте – комиссиясе, комитеты.

[5] 2 нче хәрби съезд – 1918 елның 8 гыйнвар – 20 февраль көннәрендә Казанда уза. Анда Идел-Урал Штатын оештыру мәсьәләсе карала.

[6] Ляихәсе – проекты.

ты да шул ук хөдүдләр ляихәсен кабул итеп, мәшһүр Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте низамнамәсен игълан иттерде. Бу тугрыдагы беренче киңәш мәҗлесе шул ук хөдүдләргә туктады.

Татар-башкорт җөмһүриятенең мәйданга чыгуы сузылу сәбәпле һәм Дутов[1], чехлар вә Колчакларның[2] сугышлары нәтиҗәсендә югарыдагы хөдүднең шәркый кыйсемендә кечкенә Башкорт җөмһүрияте төзелгәч, югарыдагы хөдүдләрнең аннан тыш калган кыйсеме һаман да татар-башкортларның Тупраклы Мохтарият хөдүдләре булып калды. Моны Казан губернасы мөселман коммунистлары конференциясе «Татар җөмһүрияте» исеме белән, Уфа губернасы мөселман коммунистлары конференциясе «Татар-башкорт җөмһүрияте» исеме белән атап тәэкид иттеләр[3].

Мәскәүдә җыелган шәрык мөселман коммунистларының 2 нче гомуми съезды исем мәсьәләсендә Уфага кушылды. Ләкин хөдүд Казанда да, Уфада да, Мәскәүдә дә бер үк, шул Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте низамнамәсендәге хөдүдләр алынып, шуннан тик кечек башкорт ягына чыгарылган иде.

Татар-башкортларның сан ягыннан күп, процент ягыннан иң югары булган җирләре шул һәм шул гына булганга, һәм бу хөдүдләргә икътисади яктан да, идарә өчен уңайлык ягыннан да зур бәхетләр килмәгәнгә, ничә мәртәбәләр әтрафлы сурәттә төрле комиссияләр тарафыннан тикшерелсә дә, хөдүд мәсьәләсе һаман бер үк әсасларда саклана иде. Шуңа күрә Татар-башкортларның Тупраклы Мохтарият хөдүдләре тугрысындагы теләкләре (территориальный самоопределениеләре) тәмамән билгеләнгән диярлектер.

Игълан ителгән Татар җөмһүриятенең хөдүдләренә бәһа кую, бу хөдүдләрдә булганда да алырга тиешме, юкмы икәнен хәл иткәндә дә иң дөрест үлчәү – югарыдагы Татар-башкорт җөмһүрияте хөдүдләре белән чагыштыру һәм шул ноктадан бәһа бирүдер.

---

[1] Дутов – Александр Ильич Дутов (1879–1921), Оренбург казаклары атаманы, Гражданнар сугышында Көньяк Уралда большевик гаскәрләренә каршы көрәшнең җитәкчесе. 1919 елдан генерал-лейтенант, Колчак гаскәрләренең Оренбург отделениесендә командалык итә. Колчак гаскәре җиңелгәннән соң, Кытайга кача, шунда үтерелә.

[2] Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), рус хәрби һәм сәяси эшлеклесе, Гражданнар сугышы чорында аклар хәрәкәте җитәкчеләренең берсе.

[3] Тәэкид иттеләр – раcладылар.

Югарыдагы хөдүдләрдә мохтарият[1] алу өчен безгә иң күп уңайсызлык китергән нәрсә, безнең күпчелек тәшкил итеп, шул хөдүдкә кергән җирләр безнең элекке губерна, өяз, хәтта волость границалары белән дә тугры килмәве иде. Иске хөкүмәт руслаштырырга һәм һәртөрле милли хәрәкәтләрне басарга уңай булсын өчен, икътисади яктан һәм идарә өчен уңайлыгы ягыннан һичбер сәбәп булмаса да, югарыдагы татар-башкорт күпчелеге җирләрен төрле губерналарга бүләргә вә аларны бу губерналарның һәммәсендә дә азчылыкта калдырырга тырышкан һәм муаффәкъ дә[2] булган иде. Тик уртада калган Уфа губернасында билмәҗбүрият[3] татар-башкортлар 52 процент тәшкил итсәләр дә, башкаларында зур азчылыкта калган иделәр: Казан губернасында алар 31 процент кына, Оренбург губернасында – 22, Самарада – 11, Сембердә – 9, Пермьдә – 5 ярым, Вяткада – 5 процент кына тәшкил итәләр. Бу аерылу, бердән, татар-башкортларның барлы-юклы мәдәни көчләрен бүлгәләнеп таралырга мәҗбүр итә һәм губерналарда аз процент тәшкил иткәнлекләреннән электәге земстволарга да, хәзерге советларга да аларның уку-укыту һәм гомумән милли мәдәният эшләренә артык әһәмият бирергә юл куймый иде.

Безнең тупрак (территория) ягыннан милли самоопределениемезнең иң әһәмиятле һәм мохтарият бирелсә дә, бирелмәсә дә, үткәрелергә тиеш кыйсеме, элекке губерна границаларын бозып, югарыдагы 7 губернаның бер-беренә чиктәш һәм татар-башкортлар торган кыйсемнәреннән 2 йә 3 татар-башкортлар күпчелек тәшкил иткән губерна ясау иде. Мондый губерналар тәшкил ителүе берлән шулар эчендә эшләү, губернаның гомуми эшләренә тәэсир итү, мәдәни һәм партийный көчләрне бергә җыю өчен никадәр әһәмиятле булса, шундый татар-башкорты күпчелектә булган губерналарны берләштереп, бер мохтар[4] өлкә (җөмһүрият) тәшкил итү өчен дә әсас[5] ясалганлыктан, тәмамы территориальный самоопределение өчен дә ифрат әһәмиятле иде.

[1] Мохтарият – ирeклелек, бәйсезлек.
[2] Муаффәкъ дә – ирешкән дә.
[3] Билмәҗбүрият – ирегеннән тыш, ихтыярсызлык белән.
[4] Мохтар – ирекле.
[5] Әсас – нигез.

Элек тә игълан ителеп мәйданга куелган башкорт җөмһүрияте татар-башкорт хөдүдләренең[1] шәрык тарафында, губерна границаларын үзгәртеп, Оренбург, Пермь губерналарының татар-башкорт күпчелек тәшкил иткән җирләрен һәм Уфа губернасының Златоуст һәм Эстәрле өязләрен кушып, шулардан бер вахиде[2] идарә (административная единица) ясавы сәбәпле, гомуми Татар-башкорт Тупраклы мохтарият мәсьәләсе хәлли[3] ягыннан әһәмиятле бер адым иде. Хәзер игълан ителгән Татар җөмһүрияте – шул ук юлда икенче һәм тагын да әһәмиятлерәк адымдыр.

Татар җөмһүрияте Казан шәһәре һәм Казан губернасының мөселманлы өязләрен алып, алар янына Сембер, Вятка, Самара губерналарының татар-башкортлар иң тыгыз утырган волостьларын һәм Минзәлә өязен кушып, барысыннан күпчелеге татар-башкорт булган тагын бер вахиде идарә (административная единица) мәйданга китерә. Бу вахиде идарәнең хөдүдләре тәмамән диярлек югарыда күрсәтелгән татар-башкорт хөдүдләренең гаребтәге кыйсеменә тугры килә, (кайбер волость һәм авылларда – Чабаксар һәм Чуел өязләренең татар авыллары керми калуы кебек – аермалар булса да, болар – шул җирдәге татар авылларының икенче өяз һәм волостьларга карауга ризалыклары мәгълүм булмаганлыктан гына кертелми калдырылган кисәкләрдер) бу авылларның керү-кермәүләрен махсус хөдүд комиссиясе карамагына калдырылган (низамнамәнең 9 нчы маддәсе).

Татар-башкорт хөдүдләре эчендә татар-башкорты иң аз процент тәшкил иткән даирә Казан тирәсе иде.

Мондагы өязләрдән Спас, Зөя, Чистай, Лаеш өязләрендә татарлар 30–40 процент тәшкил иткәндә, руслар үзләре генә 50–60 процент тәшкил итәләр; һәм байтак чуаш вә башка халыклар торалар. Казан шәһәренең үзендә татарлар бары 20 процент тәшкил итеп, руслар 75 проценттан артыграк тәшкил итәләр. Шуңар күрә бу даирә – җөмһүрияткә кертелүе иң авыр һәм ихтиляфлы булган бер даирә, шуның белән бергә, бөтен татар-башкорт мәдәниятенең иң зур мәркәзе булган Казанны да эченә алганлыктан, керми калуы татар-башкортлар карашында мөмкин булмаган бер даирә иде.

[1] Хөдүдләренең – чикләренең.
[2] Вахиде – бер, берәмлек.
[3] Хәлли – чишелү.

Руслар зур күпчелектә булу аркасында бу даирәнең, вакытлы булса да, җөмһүрияткә керми калуы, бу җирләрдән бөтенләй колак кагу булып чыгачак иде. Хәзер «Татар җөмһүрияте» мәйданга куелу аркасында бу даирәне эченә алган, шуның белән бергә, гомумән дә, күпчелек татар-башкортлар да булган бер вахиде идарә ясала.

Шулай итеп, башта Башкорт җөмһүрияте, аннан соң Татар җөмһүрияте төзелү аркасында, губерна вә өяз границаларына без теләгән һәм безнең милли интересларымызга муафыйк булган[1] алмашынулар кертеп бетерелгән була. Вә шуның нәтиҗәсендә татар-башкорт хөдүдләре мәркәз тарафыннан кабул ителгән һәм һәркайсында халыкның күпчелеге татар-башкорт булган өч кисәккә бүленгән була:

**Башкорт җөмһүрияте** – шартый[2] рәвештә кертелгән Златоуст һәм Эстәрлетамак кисәкләре белән бергә, киләчәктә саклануы өмидсез булган Чиләбе җәнүбендәге, һәм Оренбург өязенең җәнүб гарбисендәге утрауларыннан башка исәпләгәндә: бөтен җире (мәсахәи сатхиясе[3]) – 86 092 дүрткел чакрым йә 9 053 568 дисәтинә; бөтен халкы (тәкърибән[4]) – 1 317 000 кеше; шул җөмләдән: татар-башкортлар – 747 000 (йә 57 %), руслар – 467 000 (йә 35 %), башка милләтләр – 103 000 (йә 8 %).

**Татар җөмһүрияте** – игълан ителгән хөдүдләре буенча: Бирски һәм Бәләбәй өязләреннән башка: бөтен җире – 55 987 дүрткел чакрым йә 5 831 631 дисәтинә; бөтен халкы – 3 276 000; шул җөмләдән: татар-башкортлар – 1 644 000 (йә 50 %), руслар – 1 332 000 (йә 41 %), чуашлар вә башкалар – 300 000 (йә 9 %)

Хөдүдләр тәмам өзелгәндә әлегә керми калган хөдүд янындагы татар авыллары керәчәк һәм вакытлы рәвештә кертелгән Тәтеш өязенең гарбендәге чуаш кыйсеме чыгачак булганга, ул вакытта татар-башкортларның проценты Татар җөмһүриятендә тагын бер ярым йә ике процент кадәр күтәрелергә тиеш.

Хәзерге хәлендә Татар җөмһүрияте үзенең җире киңлеге ягыннан һәм халкының саны ягыннан элеккеге Казан губернасыннан бераз зуррак була.

---

[1] Муафыйк булган – туры килгән.
[2] Шартый – шартлы.
[3] Мәсахәи сатхиясе – яссылык киңлеге.
[4] Тәкърибән – якынча.

Уфа губернасы – Шәрыктагы Башкорт җөмһүриятенә кергән кисәкләрен, гарбендәге Татар җөмһүриятенә кергән Минзәлә өязен чыгаргач калган кисәгендә: бөтен җире 65 167 дүрткел чакрым йә 5 838 856 дисәтинә; бөтен халкы – 1 767 000; шул җөмләдән: татар-башкортлар – 957 000 (йә 54 %), руслар – 543 000 (йә 31 %), башкалар – 267 000 (йә 15 %).

Шулай итеп, Татар җөмһүриятенең мәйданга куелуы – без татар-башкортларның, гомумән, миллият мәсьәләсе хәлли ягыннан иң әһәмиятле адымнардан берседер. Татар җөмһүрияте, губерна границалары үзгәреп, яңа хөдүддәге бер губерна тәшкил ителүдән генә гыйбарәт булып кала икән, ул вакытта да Татар җөмһүрияте тугрысындагы низамнамәне безгә эшче вә игенчеләр хакимиятенең зур бүләге итеп карарга тугры килер иде. Саботажга, авантюраларга (җилкуарлык) бирелми тиешенчә эшләсәк, җөмһүриятнең нәтиҗәсе зур булачагы да көн кебек ачыктыр.

## Автономияле Татар Шуралар Җөмһүрияте хакында декрет

Бөтенрусия Мәркәз Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы карар бирде:

I

§ 1. Русия Кушма Шуралар Җөмһүриятенең бер кисәге итеп, Автономияле Татар Шуралар Җөмһүрияте төзелә һәм аның эченә түбәндәге җирләр керә: а) Казан губернасыннан: Казан өязе, Лаеш, Мамадыш, Свияжский, Чистай, Тәтеш өязләре; Жидяевский, Юрткольский волостьларыннан башка Спас өязе; Алабуга өязенең Чиркәс, Салагыш волостьлары һәм Красно-Кокшай өязенең Күлле Киме һәм Кшклов[1] волостьлары;

б) Уфа губернасыннан: Минзәлә өязе;

в) Самар губернасы Бөгелмә өязеннән: Азнакаевский, Алькеевский, Александровский, Альметьевский, Бавлинский, Богоявленский, Варваринский, Верхне-Карамальский, Каратаевский, Кузайкинский, Ивановский, Масягутский, Микулинский, Мордовско-Афонькинский, Мордовско-Ивановский, Мордовско-Кармальская, Нижне-Чиршелинский, Ново-Письмянский, Салихов-

[1] Кышлау волосте.

ский, Спасский, Спиридоновский, Эстәрлетамакский, Сумароковский, Тамтык, Урсалинский һәм Чеканский волостьлары;

г) Вятка вилаяте Малмыж өязеннән: Кошкин, Нослинский, Арборовский, Янгуловский, Сардыбашевский, Нижне-Читаевский, Шудинский, Ципинский волостьлары;

д) Сембер вилаяте Сембер өязеннән: Сөендек, Олуг Тархан һәм Олуг Чаллы волостьлары, Буа өязеннән: Старо-Студенецкий, Янтугановский, Шәйхирданский, Ново-Кәкерлинский, Дрожжановский, Мочалевский, Бурундуковский, Рунгинский, Тимбаевский һәм Городищенский волостьлары.

*Искәрмә:* социализм әсасына корылган Татар Шуралар Җөмһүриятенә Уфа вилаятенең Бөре һәм Бәләбәй өязләрен кушу мәсьәләсе мәркәз өязләрдәге үз көче белән көн итүче җирле халыкның ризалыкларын белгәнгә кадәр ачык хәленчә калдырыла.

II

§ 2. Автономияле Татар Шуралар Җөмһүриятенең хөкүмәт аппараты, Русия Шуралар Җөмһүрияте конституциясе буенча, җирле советлардан Татар Җөмһүрияте Мәркәз Башкарма Комитетыннан һәм Татар Җөмһүрияте Халык Комиссарлары Шурасыннан гыйбарәт була.

§ 3. Автономияле Татар Шуралар Җөмһүриятенең эшләрен башкару өчен, түбәндәге халык комиссариатлары төзеләдер: 1) почта-телеграф идарәсе белән эчке эшләр халык комиссариаты, 2) гадлия[1], 3) мәгариф, 4) сәламәтлекне саклау, 5) иҗтимагый тәэминат, 6) җир эшләре, 7) азык-төлек, 8) малия, 9) эш һәм юл йөртү бүлекләре белән халык көнкүреше шурасы, 10) эшче крестьян инспекциясе.

*Искәрмә*: Татар җөмһүриятенең тышкы эшләре һәм тышкы сәүдә мөгамәләләре бөтенләе белән Русия Кушма Шуралар Җөмһүрияте кулында кала.

Хәрби эшләрне якындагы округ хәрби комиссариатына буйсынган Татар хәрби комиссариаты идарә итә.

Гакселхәрәкәт[2] белән көрәшү, Татар Җөмһүрияте Халык Комиссарлары Шурасы белән мәркәз фәүкылгадә[3] комиссия арасын-

[1] Гадлия – юстиция.

[2] Гаселхәрәкәт – каршылар.

[3] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

дагы килешү буенча төзелгән җирле фәүкылгадә комиссия кулында кала.

§ 4. Русия Кушма Шуралар Җөмһүрияте малия һәм халык хуҗалыгы эшләре сәясәтләренең җөмһүриятнең бөтен җирләрендә бер көенчә саклануы максады Татар Шуралар Җөмһүриятенең азык-төлек, малия, эш һәм юл йөртү бүлекләре белән бергә халык хуҗалыгы шурасы, эшче, крестьяннар инспекциясе, Эчке эшләр халык комиссариаты каршындагы почта-телеграф идарәләре Русия Шуралар Җөмһүриятенең халык комиссариатларына буйсынып, соңгыларының боерык һәм тәгълиматларыны җиренә җиткерергә тиешләр.

§ 5. Татар Шуралар Җөмһүриятенең эчке эшләр (моңа почта-телеграф идарәләре керми), гадлия, мәгариф, сәламәтлекне саклау, иҗтимагый тәэминат һәм җир эшләре халык комиссариатлары үз эшләрендә автономияле булып, Мәркәз Башкарма Комитеты алдында турыдан-туры мәсъүлләр[1].

§ 6. Казан шурасы рәисе, тавыш бирү хакына малик булып, Автономияле Татар Шуралар Җөмһүриятенең Халык Комиссарлары Шурасына керә.

§ 7. Социализм әсасына корылган Татар Шуралар Җөмһүрияте, малия һәм техника җәһәтеннән Бөтенрусия Шуралар Җөмһүриятенең гомуми хәзинәсеннән тәэмин ителер.

III

§ 8. Татар җөмһүрияте эченә керә торган җирләрдәге шураларның беренче съездын җыйганчыга кадәрле, җөмһүрият эчендәге бөтен хакимият Мәркәз Комитет тарафыннан төзелгән ревком кулында булачак.

Ревкомның беренче вазифасы – Татар җөмһүриятендәге шураларның беренче съездын җыю һәм ревком каршында, шушы положениенең 3 нче параграфында күрсәтелгәнчә, төзелә торган Татар җөмһүрияте халык комиссариатларына мөтәнасиб[2] булган шөгъбәләрен[3] төзү.

---

[1] Мәсъүлләр – җаваплар.
[2] Мөтәнасиб – тигез, бер чамадагы.
[3] Шөгъбәләрен – бүлекләрен, тармакларын.

§ 9. Социализм әсасына корылган Татар Шуралар Җөмһүриятенең хөдүдләрен билгеләгән вакытта чыгуы мөмкин булган мәсьәләләрне хәл итү өчен, Эчке эшләр һәм Милләтләр халык комиссариатларына катыш бер комиссия төзергә тапшырыла.

| | |
|---|---|
| Бөтенрусия Мәркәз Башкаручы Комитетның рәисе: | М. Калинин |
| Халык Комиссарлары Шурасы рәисе: | В. Ульянов (Ленин) |
| Бөтенрусия Мәркәз Башкаручы Комитетның сәркатибе: | Енукидзе. |

*Галимҗан Шәрәф. Татар-башкортлар һәм Татар җөмһүрияте, «Өмид», 1920. 24 б. Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче мәртәбә басыла.*

## ТАТАР ИЛЕ

### Татар Социал Советлар Җөмһүриятенең чикләре

Кояш баешы ягында: (төньягыннан көньягына таба) Вятканың уң тармагы булган Әҗем суының югарысыннан башланып, Вятка суының уң ягыннан кушылган Шушманың сул тармаклары булган Кугубор, Арбор, Көшкәт суларының һәм Шушманың үзенең башларын нечкә калдырып, чик, Илләт суының сул тармагы булган Шура суының башына килә һәм Шура суы башыннан кинәт шәрыкка борылып, шул ук Илләтнең сул тармагы булган Ашыт суы башына килә. Ашытның уң ягында булган Күлле Киме, Кышыклы волостьларын эчкә калдырып, Ашыт буеннан кечкенә борылышлар белән Иделгә таба юнәлә һәм аны Илләт тамагыннан 6 чакрым кадәр түбәнрәк, Зөя тамагыннан 16 чакрым югарырак аркылы чыга һәм Иделнең уң ягында шул җирдән Зөя суына янәшә (мөтәвази) рәвештә аның сул тармагы булган Гөбенә суына кадәр килә. Аннан соң Гөбенә суы буйлап аның югарысына таба сулдан кушылган Ырым суы тамагына чаклы бара. Шул җирдә кояш баешы көн ягына (җәнүби гаребкә) Кече Бола башына бара. Аннан кинәт кенә кире кояш чыгышына борылып, Олуг Бола суын Кече Бола кушылудан 15 чакрым югарырак кисеп, кояш баешы – көн ягына Кече Карлы

тамагына таба бара. Карлының сул ягындагы чуаш өлкәсенә кергән волостьлар арасына чәчелеп утырган Шыгырдан волосте да Татар җөмһүриятенә карый. Аннан Олуг Карлы суы буйлап бара һәм Яңа Кәкерле авылына 3 чакрым йитмичә кояш баешына таба борылып, Төке авылы яныннан әйләндереп алып, бөтен Мәчәли волостен Татар җөмһүриятендә калдыра, Шамкино авылы янында (аны тышка калдырып), 60 градуслы почмак ясап, кояш чыгышы – көньягына юнәлә. Татар Шатыршаны дигән авылдан 2 чакрым югарырак Олуг Яклы суын (Сура суына коя торган Барышның уң тармагы) кичеп, кинәт кояш чыгышка юнәлә һәм татар җөмһүрияте җирләренең иң көндәге кисәген әйләндереп ала һәм көньяк чикләренә күчә.

Көньягында – (кояш баештан чыгышка таба) югарыда күрсәтелгән Олуг Якла суы буйлап, аңа уң яктан Акса суы кушылган. 1 чакрым түбәнрәк башлана. Олуг Якла буйлап югарысына таба ул көньягына борылганчы су буйлап барып, аннан соң да чик элекке юнәлешендә дәвам итеп, Тимерсән суы башына (Зөягә коя торган Бирүч суының сул тармагы) бара. Аннан, турыпочмак ясап, кояш чыгыш көн ягына юнәлә, Олуг Чынлы суы башына бара. Аның уң ягындагы Олуг Чынлы һәм Өендек волостьларын эченә алып, кечкенә йөрешләр белән Идел буена юнәлә һәм Ундыр пристаненнән 3 чакрым югарырак Иделгә килеп терәлә. Аннан соң Идел буйлап югарыга менеп, Пәләнкә авылы янында (Утка суының тамагыннан 2 чакрым югарырак шәрыкка борылып, электә Спас өязендә, хәзер Мәләкәс өязендә булган Волостников, Матвей, Йөрткүл (Иске Жидей һәм Йөрткүл) волостьларын тышта калдырып, Иске Кара Йөрткүл авылыннан 5 чакрым чыгыштарак көньягына борылып, Майна суына чаклы бара. Аннан соң шул су буенча кояш чыгышка таба бара һәм шул юнәлештә дәвам итеп, Кече Чирмешән суын турыпочмак ясап кисә. Аннан соң Олуг Чирмешән суын Юрматы тамагы янында кисеп, Юрматы суы буйлап аның башына чаклы бара. Аннан кояш чыгышы төньягына юнәлеп, Волга-Бөгелмә тимер юлына янәшә (мөнәвази) булып, 2 чакрым кадәр ераклыкта бара. Норлат стансасыннан 10 чакрым чыгыштарак чик тимер юлны кисеп, Кондырча суы һәм аның тармагы булган Тукмак суы буйлап бара. Шулай бу кисәгене әйләндереп алып, чик тагы тимер юлына кайта һәм кояш чыгышына таба Чесноковка суы башына барып, аннан чыгыш – көньягына юнәлә һәм кечкенә-кечкенә борылышлар

белән Бөгелмә шәһәреннән 20 чакрым җәнүбкәрәк[1] үтеп, Дим суына чаклы бара. Дим суын кичеп, көньягына юнәлә һәм Попов (Ивановский һәм Салих) волостен эчкә калдырып, җөмһүриятнең кояш чыгыш чикләренә килә.

Кояш чыгыш ягыннан – (көньягыннан төньягына таба) Ык суының сул тармагы булган Кандыз буйлап, аңа Кушма суы кушылудан 12 чакрым түбәнрәк башлана. Кандыз суы буйлап аның тамагына чаклы бара. Аннан Ык буйлап китеп, Бөгелмә, Минзәлә кантоннарының һәм Бәләбәй өязенең уртак чикләрендә булган Шуган авылы янына килеп җиткәч, турыпочмак ясап, чыгыш төньягына юнәлә һәм Сөн суына килеп, аңа сул яктан Гомәр суы кушылудан 5 чакрым түбәнрәк җирдән башлап, чик түбән таба Сөн буйлап бара. Аның тамагына кадәр җитеп, Ак Идел буйлап түбән таба, аның Камага койган җиренә чаклы бара. Аннан төньяк чикләре башлана.

Төньяк чикләре – (кояш чыгышыннан баешка таба) Ак Идел тамагыннан түбән таба Кама буйлап 20 чакрым кадәр баргач, кинәт төньякка таба борылып, Олуг Бима суының башына бара. (Олуг Бима – Ижга сулдан кушыла торган Курыкмас суының сул тармагы.) Олуг Бима буйлап аның тамагына чаклы бара, Курыкмас суын кичә, аның уң тармагы булган Молебная суы буйлап бара. Аннан кояш баеш – көньягына әйләнеп, электә Алабуга өязендә, хәзер Сарапул өязендә булган Мушак волостен тышта калдырып, аның көньягыннан әйләнеп, Иж буйлап югарыга менә, моннан Казан-Екатеринбург тимер юлына җитеп, Әгерже стансасын, Бубый авыллары белән бергә Әгерже волостен Татар җөмһүриятенә кертеп, тагын көньягына әйләнә. Сарсак-Омга, Көчек, Салагыш волостьларының кояш баешы яклары белән текә генә Камага Ижның койган җиренә таба бара. 30 чакрым кадәр генә Камага җитми, тагын Камадан кояш баеш төньягына таба борылып, Койма суының урта агымында утырган Курак волостен эчкә алып, янәдән Кама янына килә һәм Каманың кинәт җәнүбкә борылып киткән җирендә Камага 6 чакрым кадәр җитми, чик шәрыкка һәм Вятка суына сулдан Үмәк ермагы койган җиргә бара. Аннан Вятка буйлап югарыга китеп, Вятканың сул тармагы буйлап Лубяна суы буйлап бер киртә ясап, яңадан Вяткага кайта, аны аркылы чыгып, Вятка белән ике арада беррәттән Вятка буйлап тезелгән Татар җөмһүриятенә керми торган

[1] Җәнүбкәрәк – көньяккарак.

Вятская Поляна, Иске Борец, Маринов, Малмыжка, Сәвәләй, Кече Рузкин, Әҗем волостьларын калдырып, Вяткага янәшә (мөнәвази) рәвештә бара. Һәм Вятканың тармагы булган Әҗем суы башына барып чыга һәм шуннан җөмһүриятнең кояш баеш чикләренә кушыла.

Революциягә кадәр булган губерна, өяз чикләре белән чагыштырганда Татар җөмһүриятенә түбәндәге идарәи берлекләр өяз һәм волостьлар керәләр:

Казан губернасыннан – Казан шәһәре, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Чистай, Тәтеш өязләре бөтенләе, Спас өязенең Жидәй һәм Йөрткүл волостьларыннан башкасы, Кызыл Кокшай (Чар) өязеннән Күлле Киме, Кышыклы волостьлары.

Уфа губернасыннан – Минзәлә өязе бүтәннәре.

Самар губернасыннан – Бөгелмә өязенең Бөгелмә шәһәре һәм Азнакай, Александров, Әлки, Баулы, Богоявлен волостьларын, Верхний Кармала, Каратай, Кузайкин, Иванов, Мәсгуд, Микулин, мордва – Ановкин, мордва – Иванов, мордва – Кармала, Түбән Чыршылы, Түбән Писмән, Салих, Спас, Спиридонов, Эстәрлетамак, Сумароков, Тымытык Урсала, Чикән волостьлары.

Вятка губернасыннан – Малмыж өязенең Кошкин, Нослин, Арбор, Янгул, Сәрдекбаш, Түбән Чутай, Шода волостьлары, Алабуга өязенең Салагыш, Чиркәс, Казил, Трехсвят, Качкин, Лекар, Курак, Көчек, Сарсак-Омга, Пьянобор, Бима, Чикалды волостьлары һәм Сарапул өязенең Әгерже һәм Исәнбай волостьлары.

Сембер губернасыннан – Сембер өязенең Сөендек, Олуг Тархан, Олуг Чынлы волостьлары, Буа өязенең Буа шәһәре, Суыксу, Янтуган, Шыгырдан, Яңа Кәкерле, Дрожжан, Мәчәли, Борындык, Рунга, Тимбай, Уби, Городище волостьлары керәләр.

Татар иленең өсте (сатыхы). Татар иленең өсте бик аз аерма белән бар урыны да тигезлек диярлек. Бу тигезлек Урта Урал тауларының иң түбән итәгеннән кояш баешына таба сузылып бара да Иделнең аргы ягындагы Урта Русия күтәренкесенә килеп кушыла.

Шулай да Кама елгасының уң ягында Минзәлә һәм Бөгелмә кантоннарының кояш чыгышы, аларга күрше булган Спас һәм Мамадыш өязләренең кояш чыгышы яклары Урта Урал тауларының итәге төсен бирәләр. Ләкин боларны бөтенләй тау рәвешендәге күтәренке урын дип әйтеп булмый, чөнки Бөгелмә өязендә Зәй суының уң ягы һәм Чирмешән елгасының югарыгы агымы

буйлары – Татар иленең иң югары урыны дип йөртергә мөмкин, бу тирәләр – диңгез өстеннән 120–140 сажиннар күтәренке урыннардыр. Тәтеш һәм Буа кантоннары, гомумән, Урта Русиянең күтәренке урыныдыр. Күп аермасы юктыр. Бунда да Тәтеш кантонлыгында Идел буе, Буа кантонлыгында Кәрлә һәм Бизнә елгалары арасы диңгез өстеннән 100–120 сажин чамасындадыр. Күзгә күренгән әйтерлек тау юк. Бары Казан шәһәре каршысында Иделнең уң ягында урман һәм Тәтеш таулары – диңгез өстеннән 102 сажин биеклегендәге таулардыр. Боларны «тау» түгел, бәлки «үр» дип кенә йөрергә кирәк.

Бөтен Татар илендә диңгез өстеннән түбән урын юк, иң түбән урын – Спас кантонлыгында Спас шәһәре тирәсендәге урындыр. Бундагы үр диңгез өстеннән 20–40 сажин биеклегендәдер.

Һава – Татар иле һавасы. Кояш баеш көньягыннан (гареб җәнүбе) исә торган диңгез җилләре Татар иленең һавасын һаман да үзгәртеп торалар.

Чөнки бу җилләр безнең ил өстенә юеш һава китерәдер, ләкин кояш баешы ягыннан искән җилләр безнең ил өстенә җитәрлек яңгырлы болытларны туктатмый, бәлки аларны Урал тауларына таба куып, болытлар шунда терәлеп калалар. Кыш көннәрендә уртача исәп белән Казан, Сембер һәм Уфаның Казан вилаятенә якын чикләрендә (Минзәлә кантонлыгында) суыклык 14 градус чамасы буладыр. Җәйнең иң кызу көннәре июль аена тугры килсә, Татар илендә эсселек уртача 20 градус чамасында йөридер.

Татар илендә һава җәйдән көзгә таба бик акрынлык белән үзгәрә, инде яздан җәйгә таба бик кинәт үзгәрәдер. (Октябрьдә һава 3, 7°, ноябрьдә – 4°, язда, апрель – 4, 6°, май – 2, 6°.)

Бөтен Татар илендә кышның озынлыгы бер үлчәүдәрәк. Һәммә җирдә кыш биш ай чамасына сузыла. Гадәттә ноябрь уртасыннан башлап апрель башларына кадәр барадыр.[1]

[1] Явымның күпме явуы бөтен җөмһүрият өчен бик мөһим булганга, явымның төрле айларда булынуы нисбәтен күрсәткән җәдвәлгә рас итеlә:

| вилаятьләр | январь | февраль | март | апрель | май | июнь | июль | августь | сентябрь | октябрь | ноябрь | декабрь |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Казан | 3,7 | 1,7 | 16,5 | 22 | 38,1 | 50, 2 | 60, 4 | 58,7 | 4 | 31 | 26, 4 | 17 |
| Уфа | 24,9 | 20,9 | 20,7 | 18,7 | 38,9 | 74,2 | 61,8 | 58,2 | 49,3 | 50,7 | 35,6 | 35,4 |

*(Г. Шәрәф иск.)*

Идел елгасы ел әйләнәсендә 220 көн Ак Идел һәм Кама елгалары 208 көн чамасы боздан әрчелеп торалар.

Явымның бик күбе җәй көненә туры килә. Җәй көнендәге явым кышка караганда дүрт мәртәбә артыктыр. Февраль аенда кыш көне дә кар яумый. Декабрь, январь һәм февраль айларында Минзәлә кантоннарында күп вакыт февраль урынында ноябрь айларында кар явып куя. Яңгыр күбрәк июль, август, сентябрь һәм октябрьнең башларында буладыр. Шулай да Чистай һәм Спас кантоннарының кояш чыгыш көньякларында (шәркый җәнүби) явым азрак булып, корылык күбрәктер.

Татар илендә һәр җәйдә диярлек авыл халкы арасында «рәшә» дип мәгъруф[1] бертөрле томан сыман һава була. Бу гадәттә кызу көннәрдә июль һәм август айларында күренә. Шул «рәшә» соңында игеннәр кинәт җитеп киткән кебек күренәләр, ләкин карабодай, солы кебек ашлыклар шул рәшәдән көеп калалар. Мондый һава Татар иленең һәр җирендә, бигрәк Чистай, Спас, Минзәлә кантоннарының җәнүбләрендә көчлерәк буладыр.

Һава галимнәре моны җәй уртасында Урта Азиядә күтәрелгән ком буранынннан килгән ком тузаны, шул тузан бөтен Идел буе вилаятьләрен, бигрәк Астрахань һәм Самара вилаятьләрен каплый, диләр. Ләкин әле бу көнгә кадәр шул рәшәнең игеннәргә зарар китерүенең төп сәбәпләренә төшенгәннәре юк.

**Татар җөмһүриятенең туфрагы**

Бөтен Татар җөмһүриятенең туфрагы ягыннан төзелеше бер төсле түгел. Чөнки бу җирнең тарихында, ягъни туфрагының яратылуында бик күп төрле үзгәрешләр булган. Мәсәлән, Татар җөмһүриятенең җирендә Казаннан Түбән Иделнең болын ягында һәм Татар җөмһүрияте эченә кергән Кама һәм Вятка елгалары буенда иң элек диңгез асты булган, диңгез җәнүбкә таба киткәч, диңгез төбе булган урында бик борынгыдан бирле халык көн күреп килгән. Урманнарын кискәннәр, иген чәчкәннәр, җир өстендә череп кара туфракка әйләнерлек күп нәрсәләр булган. Иделнең Казаннан югары агымында халык аз торган, ул тирәгә борынгы диңгездә җитешмәгәнгә диңгез төбе дә булмаган, шуңар күрә ул бик борынгыдан бирле энәле агач (кызыл) урманнары астында калган. Анда черергә

[1] Мәгъруф – беленгән.

әйбер күп булмаган, халык тормаганга, урманнары киселмәгән, шуңар күрә туфрагы да башка төсле булган.

Менә шундый үзгәрешкә карап та туфракның төрлелеген күрсәтәләр: гомумән караганда, Татар җөмһүриятенең иген игәр өчен туфрагы яхшы, күбрәк урыны ком катыш туфрак һәм балчык катыш туфраклардан гыйбарәт. Бөтенләй комлык дип әйтерлек киң җирләр юк. Татар җөмһүрияте эченә кергән Каманың аргы ягында, кояш баешы ягында Чистай, Спас һәм Бөгелмә кантоннарында ком катыш балчыклы туфрак урыны-урыны белән известьле туфрак та очрый. Шулай да Бөгелмә өязендә кара туфрак та күп. Инде Чистай, Спас кантоннарының Идел һәм Каманың түбәнге ягы буендагы җирләрдә кара туфрак. Зөя, Тәтеш, Спас, Минзәлә һәм Бөгелмә кантоннары аркылы киң кара туфрак юлы сузыла. Бу туфракны Татар җөмһүриятенең мәгъдән байлыгы дип исәпләргә ярый. Чөнки бу туфрак ашлыкның иң уңып була торган урыны Чистай кантоннарында, Чирмешән суы буенда, бигрәк тә Бүләр авылы янында бөтенләй кызыл балчыклы туфраклар очрый. Каманың бире ягында, ягъни Иделнең болын ягында Арча, Лаеш, Мамадыш кантоннарында күбрәк туфрак соры балчыклы туфрак белән комлы туфрак. Казан тирәсендә көлле (көл сыман) туфрак та бар. Лаеш кантонының көньягында Кама һәм Иделгә таба урыннарында кара туфраклы җирдер. Иделнең ары ягында Зөя һәм Тәтеш кантоннарының югарыда әйткән кара туфраклы киң юлыннан башка урыннарның барысы да ком катыш һәм соры балчык катыш туфраклы җир дип әйтеп буладыр. Шулай бөтен җөмһүриятнең туфрагы ашлыкны җирдән туйдыра алу ягыннан яхшы. Бары шуның өстенә һаваның гына ярдәме кирәк.

**Агым сулар**

Татар илендә пароходлар йөрерлек зур агым сулардан берсе дә чыгышыннан (мәнбәгъ[1]) башлап тамагына тикле җөмһүрият аркылы сузылып чыкмый. Татар илендә Аурупаның иң зур елгаларыннан санала торган Идел елгасының үзәге һәм Чалман (Кама), Ак Идел, Нократ (Вятка) елгалары кебек атаклы елгаларның түбәнге агымнары Татар иле эченнән агалар.

[1] Мәнбәгъ – чыганак.

Татар илендәге зур елгалар үзләренең ярлары биеклеге сәбәбеннән авыл көнкүрешенә әйтерлек файда китерә алмыйлар. Бу елгалар тирәсендәге җирләр турыдан-туры ул елгаларның дымнары белән сугарылмыйлар. Бәлки бу елгалар үзләре үз тирәләрендәге вак елгаларның суларын суыру сәбәпле игенле җирләргә, болыннарның дымлы торуына зарар итәләр.

Зур елгаларның файдалары җирләрне юеш тотудан бигрәк, аларның су юлы булуыннан күбрәк файда ителәдер. Җәй көне су юлларының күрше өлкәләрдән әйбер китерү, Татар иленнән күрше өлкәләргә әйбер чыгару өчен кирәкләре зурдыр. Шуның өчен Татар иленнән чыга торган әйберләрнең бик күп өлеше су юлы белән озатылган кебек, кергән әйберләр дә җәй көне су юлы белән килеп каладыр.

Ак Идел елгасы – Татар-башкорт илендә бик борынгыдан бирле үзенең тыныч-сөзәк ярлары белән атаклы елга. Чөнки бөтен Татар-башкорт илендәге зур сәяси болганулар, зур чуалышлар шул елганың ярдәме белән булган диярлек.

Татар илендә Ак Идел елгасының түбәнге агымы, Бөре белән Минзәлә кантоннарының төньяк чикләрен ике як яры белән аерадыр. Уң як яры Бөре өязендә калып, Сөн елгасыннан башлап, сул як яры Минзәлә кантонлыгы чигендә 60 чакрым озынлыгында сузылып, Камага килеп кушыладыр.

Чулман (Кама елгасы) – Татар илендә пароход йөри торган елгаларның иң озыны һәм һәрвакыт суның күплеге ягыннан иң беренчеседер.

Татар елгасы Ак Иделнең Камага кушылган урыныннан башлап, Татар иленә кереп китә. Ул үзенең уң яры белән Алабуга кантонын буып, сул яры белән 175 чакрым озынлыгында Минзәлә кантонын буадыр. Нократ иделе кушылган урыннан башлап, Кама елгасы ике як яры белән дә Татар иленең Мамадыш, Чистай һәм Лаеш кантоннары аркылы 190 чакрым озынлыгында сузыладыр да Иделгә килеп кушыладыр.

Чулман елгасының Татар иле аркылы уза торган өлешендә мәңге су күп булганга һичбер вакыт пароход тукталырлык дәрәҗәдә саекмый, шуңар күрә Татар иленең бу өлешендә җәй көне су юлы һич киселмидер. Нократ (Вятка) иделенең түбәнге агымы Татар иленә килеп кушыла. Бу идел «Түбән шун» дигән авылдан башлап,

60 чакрым чамасы акканы соңында Соколка дигән урында Камага кушыладыр.

Нократ иделе – ул аз сулы идел. Җәй уртасында Камада йөри торган пароходлар да су сайлыктан йөри алмыйлар. Шулай да Нократ иделенең Татар илендәге өлешендә су һәрвакыт күп булганга, пароходлар гамьсез йөриләр.

Пароходның мактанычы, киң Русия әйберләренең бик зур өлешен өстендә йөртә торган бөек Идел елгасы Татар иленең төньяк кояш баешыннан башлап, көньягына таба аркылы узып агып чыгадыр.

Илләт елгасының Иделгә кушылган урыныннан алты чакрым түбәндәрәк Идел елгасы Татар иленә кергән исәпләнәдер. Идел Татар иленең көн баешыннан Казанга таба туры агып килә дә, Казан каласы турысында кинәт көн баешына таба борылып, туры Спас, Тәтеш шәһәрләрен узып, Тәтеш шәһәреннән түбәнрәк Полянка дигән урынга кадәр ике яры белән дә 170 чакрым озынлыгында агадыр. Полянкадан башлап, Сембер вилаятендәге «Ундыр» исемендәге пристаньгә кадәр 15 чакрым озынлыгында уң яры Буа кантонлыгын, сул яры Самар губернасының Мәләкәс өязен буадыр.

Татар илендә Идел ярларының төзелеше Самара белән Нижний арасындагы гомуми төзелешеннән әйтерлек аерма юктыр. Яр текә бөек яр булып сузыла. Яр кайбер урыннарда, мәсәлән, Казанга йитәр алдыннан Вязовой, Казан каласы каршында Ослан тауларын ясап, үзенең үсемлеге, җәй буенча яшеллеге белән Идел буенда аерым күрек биреп торалар. Иделнең уң яры Татар иле буенча имән, каен, нарат агачлары белән капланган урман рәвешен тотадыр.

Иделнең сул яры сөзәк булганга, яз көнендә ташу суы урыны белән кырык, илле чакрым киңлегендә җәеләдер. Тау ягында еллар буенча Идел дулкыннары белән яз буенча чыгарган комнары инде киң болын ясаган, шуңа күрә Татар илендә Иделнең бик күп урында текә уң яр алды өч-дүрт чакрым киңлегендә тал әрәмәлеккә әйләнеп, бик күп урыннары болынлык төсен ала.

Татар иле эченә кергән Идел агымында Казаннан түбән 30 чакрым чамасында «Шеланга» һәм шуннан 5 чакрым түбәнрәк Тәмте перекатлары бар. Бу урыннарда июль һәм август айларында су кимү сәбәпле, су саега. Кайбер урыннар 14–16 вершокларга гына калып, Иделнең зур пароходлары үтә алмаслык була. Ләкин хосусый Идел-

нең төбен казый торган машиналар өзлексез рәвештә казып торулары сәбәпле, пароходлар туктарлык булмыйлар. Татар илендә Ак Идел, Чулман, Нократ иделе кебек атаклы елгаларга башка янә яз көнендә пароход йөрерлек «Зөя» суын атаклы елгадан исәпләргә ярыйдыр.

Зөя суы Иделнең агышына бөтенләй каршы рәвештә көньягыннан төнгә таба агадыр. Чөнки Идел яры буенча күтәренке көн башына таба төшә барса, Идел ярыннан эчкә таба күтәренке урын төньягына төшә барадыр. Шуңар күрә бу ике янәшә ага торган елга берсе бер якка, икенчесе аңа каршы якка таба агадыр. Татар илендә Зөя суы 145 чакрым озынлыгында булып, аның түбәнге агымында 30–40 чакрым урынында яз көне бер-ике кечкенә пароходлар йөрерлек буладыр.

Буңар башка Иделнең сул ягыннан кушыла торган Илләт, Казан, Әшнәк, Шушма, Мишә елгалары – атаклы елгалардыр. Шулай ук Иделнең тау ягында ага торган Зөя тармакларыннан Чынлы, Бола, Чирмешән, Бәрле, Гөбенә елгалары һәм Каманың сул ягында Актай, Бездна, Олы һәм Кече Чирмешән, Утка, Майна, Уратма, Шантала, Чишмә, Талкыш, Зәй, Ык, Минзәлә, Мәллә урман чишмәсе, Бөгелмә кебек елгалар – Татар илендә танылган елгалардыр.

Бу елгалар барысы да зур булмасалар да, Идел буена таба, бигрәк Иделнең сул ягында ага торган Казан, Илләт елгаларында яз көнендә сал агыза, Иделдә агызырга агач хәзерләүдә зур һәм файдалы урын тоталар. Боларга башка һәрбер елга үз буйларында бик күп су тегермәннәренә су бирәдер.

**Мәгъдәннәр**

Татар җөмһүрияте җир асты байлыгы белән мактана алмый. Әгәр дә кара туфраклы мәгъдәнгә исәпләмәгәндә алтын, бакыр, тимер, җир күмере, нефть кебек халык көнкүрешенә кирәк булган мәгъдәннәр буңа кадәр беленгәне бөтенләй юк диярлек дәрәҗәдәдер. Минзәлә, Бөгелмә, Мамадыш һәм Чистай кантоннары Урал тауларына якын кантоннар булса да, боларда да әйтерлек мәгъдән юк. Казан тирәсендә гипс ташы, Тәтеш кантонында Идел буйларында яна торган сланец, Сүки авылы янында нефть барлыгы мәгълүм. Мамадыш кантонлыгында искедән бакыр комы барын beləләр иде. Шуңар күрә анда әле дә борынгы заманда бакыр казыган учаклар

күмелеп бетмәгән, ләкин аны әле яңадан тикшереп караганнары беленми. Чистай кантонының Чирмешән суы буенча чүлмәк балчыгының күплеге, Черемух бистәсе янында күкерт, асфальт һәм нефть маеның барлыгы мәгълүм. Шулай ук Минзәлә, Бөгелмә кантоннарында урыны-урыны белән бакыр комы һәм нефть булган кебек үк, Зәй сулары буенда асфальт күптер. Идел елгасының уң як яры буенча известь ташы күп. Моңа кадәр Татар җөмһүриятендә мәгъдән эше яхшы тикшерелмәгәнгә өзекле рәвештә бер сүз дә әйтеп булмый. Соңгы тикшерүчеләр Бөгелмә, Чистай һәм Тәтеш кантоннарында нефть маеннан башка күмер дә тапканнар.

**Татар иленең үсемлекләре**

Бөтен Татар илендә иген кырлары – 3 304 035 дисәтинә 57,8 %.

Болыннар – 410 807 дисәтинә 7,2 %.

Урман һәм әрәмәлек 1 013 098 дисәтинә 17,7 %.

Яшелчә һәм җимеш бакчалары – 7 635 дисәтинә 0,1 %.

Бу саннардан үсемлекнең иң күбе мәдәни үсемлеккә[1] төшәдер. Чөнки бу үсемлек бөтен Татар җөмһүриятенең яртыдан артык мәйданын каплап торадыр. Аннан кала урман һәм әрәмәлек. Бу үсемлек бишнең береннән дә ким. Ләкин бу үсемлекләр үзләренең табигатьләре белән Татар җөмһүриятенең төрле урынында төрлечә таралганнар: җөмһүрияттә чүл рәвешендә бөтенләй эшкә яраксыз яткан җир бик аз, шулай да төрле юллар, тирән чокырлар, текә тау битләре кебек мәдәни үсемлек өчен яраксыз урынның барысы 368 284 дисәтинә була, 6,4 процент туры киләдер. Үсемлексез чүл булып ята торган урыннар бер дә юк, сазлык урыннар югарыдагы эшкә яраксыз җир исәбенә керәдер.

Җөмһүриятнең шималендә Арча кантонлыгында чыршы, нарат кебек энәле агачлы урманнардыр. Күптән түгел генә Казан тирәсендәге киң урманнар хәзер инде шактый киселгәннәр, аларның урыннарын ямь-яшел иген басуы каплап алган.

Татар җөмһүриятендә урманнар Казан каласыннан көньягына һәм кояш чыгыш көньягына киткән саен энәле, ягъни кызыл урман агачларыннан нарат,чыршы һәм артыш кебек агачлар сирәгәеп, алар урынында кара урман урын тотадыр. Бу урманнарда бигрәк

[1] Мәдәни үсемлекләр – культуралы үсемлекләр.

имән, каен юкә агачлары нарат белән кушылып китә, бик күп йирләрдә катыш урманнар ясыйлар. Бу урманнарның иң күп урыннары Минзәлә, Чистай һәм Спас кантонлыкларында, урыны-урыны белән Лаеш кантонында шулай ук Тәтеш һәм Зөя кантонлыкларында да атау-атау булып утыралар.

Нарат, чыршы кебек энәле агачларның иң күп булып, киңәеп үскән урыннары Чистай һәм Минзәлә кантонлыкларының Самар вилаятенә таба урыннарындадыр, чөнки бу урыннарда комлыкта нарат урманнары үзләре атау-атау булып утыралар. Бундагы нарат-лар һәм чыршылар Арча кантонлыгындагы төсле нәзек булмыйлар, бәлки калын җәенке булып үсәләр. Кайбер урыннарда дүртәр сажин калынлыкта наратлар очратырга мөмкин. Ләкин мондый наратлар өчен комлык һәм бик корылык кирәк. Юеш урыннарда наратлар бер дә үсә алмый. Урман янгыннарында нарат, чыршы агачлары соңында бары имән, каен, карама кебек агачларының гына үсүе сәбәпле, Чистай, Спас, Минзәлә кантонлыкларында катыш урманнар мәйданга килгән, бөтен Татар җөмһүриятенең һәммә җирендә диярлек күбрәк ошбу агачларны очратырга мөмкин – нарат, чыршы, артыш, каен, имән, өрәңге, усак, юкә, өянке, карама, зирек; су буйларында – тал; җимеш агачларыннан – алма, чия, миләш, шомырт. Казан һәм Минзәлә кантонлыкларында балан агачлары күп, чикләвек һәр җирдә бар. Һәммә җирдә диярлек үгез күзе (эт борыны) үзенең исле чәчәге белән матурлап утыра. Чәчәкләр, вак үләннәр Арча кантонлыгының шималеннән башка урыннарның һәркаюсында бөтен җирне бизәклиләр; бары куе наратлык һәм чыршылык булган урманнар гына аларга кояш яктысы үтә алмаганга, чәчәкләр һәм үләннәргә ярлыдыр. Аның урынына бундый урыннарда җиләкләрдән – бөрлегән, кара җиләк һәм мүк җиләге күп буладыр. Тагын бөтен урманнарның юешрәк урыннарында хәтфә кебек мүк бөтен урманны, агач төпләрен мамыкландырып сырып ала. Яфраклы урманнарны җөмһүриятнең һәммә җирендә очратырга мөмкин булганга ул урманнарда үсә торган җиләкләрдән – каен җиләге, җир җиләге, урман кура җиләге, карлыганнарны бик күп җыялар.

Кала тирәсендәге авыллар, җиләк өлгергәндә җиләк җыеп көн күрәләр. Шулай бөтен җөмһүрияттә үсемлекләр, кирәк агачлык, кирәк җишәүлек, кирәк әрәмәлек ягыннан үзгәрешләре юк. Үсемлекләр барысы да бертөсле, бер һавада, бер үлчәүдә үсәләр.

**Мәдәни үсемлекләр**

Татар илендә сөелеп чәчелә торган орлыклы ашлыклардан: арыш, солы, бодай, борчак, карабодай, тары, борай, ясмык, баса[1] һәм җитен.

Болар җөмһүриятнең һәммә кантонлыкларында бар. Чистай, Зөя һәм Лаеш өязләренең кайбер урыннарында печән чәчү дә тәҗрибәгә кереп бара. Ләкин әле ул башланган рәвештә генә.

Бәрәңге үсемлеге бөтен җөмһүрияттә үзәк үсемлегеннән исәпләнәдер. Һәр җирдә бәрәңгене күпләп чәчәләр, янә рус авылларында кәбестә, кишер, торма, керән, кабак, кыяр үстерү елдан-ел күбәеп бара, татар авылларында хәзер бу үсемлекләргә дә игътибар итү бар.

Бигрәк тә Казан тирәсендә кәбестә, бәрәңге, суган, кишер үстерү иң файдалы кәсеп булып исәпләнә. Татар илендә Зөя, Тәтеш, Лаеш кантонлыкларында алмагачлар бик күп үстерелә. Иң күбе – Зөя һәм Тәтеш кантонлыкларының тау як Идел буендагы авыллар. Яратып үстерелә торган кышлык алмалардан Анис, Рус Малиты; көзлек Барабинка[2]; җәйлек Пудеш, скороспел Храшавка[3] кебек алмалардыр. Алмага башка ара-тирә груша һәм каражимеш агачлары да очрый, ләкин алар аз. Аның урынына чияне һәр җирдә очратырга була.

**Терлек һәм җәнлек**

Татар илендә Русиянең һәммә җирендә очрый торган йорт җанварларыннан: ат, сыер, сарык, кәҗә. Ерткычлардан: бүре, аю. Җәнлектән: төлке, куян, сасы көзән кебек җанварлар һәр йирдә бар. Боларга башка Арча һәм Бөгелмә, Минзәлә, Чистай кантонлыкларында вакыт-вакыт поши һәм шималь боланы күренгәли.

Аю Арча һәм Бөгелмә кантонлыкларында әле дә очрый. Бүре, төлке һәр җирдә бар. Борынгы Арча һәм Бөгелмә, Чистай кантонлыкларының урманнарында вакыт-вакыт күпләп тә очраталар. Арча урманнарында сирәк кенә булса да кама, горностай кебек җәнлекләргә дә аучылык итәләр. Арча кантонлыгына күрше Малмыж, Кызылкокшай тирәләрендә тиенгә дә аучылык итәләр. Тәтеш җөмһүриятендә иң күп тотыла торган җәнлектән соры куян, бу һәр

[1] Баса – киндер.
[2] Боровинка.
[3] Тиз өлгерә торган сорт Хорошавка.

йирдә бар. Буңа һәркем аучылык итә, чөнки бу җәнлек кыш көне үсемлек агачларының кайрыларын кимергәнгә, авыл халкына күп зыян китерә.

Ашлык дошманнарыннан җомран, сасы көзән, ләтчә, сукыр тычкан кебек җир асты җанварларын һәр җирдә табарга буладыр, Чистай һәм Минзәлә кантонлыкларында сурка[1] да очраштыргалый.

Татар иленең һәр җирендә кошлар, төньяк кошлары: карга, чәүкә, күгәрчен, чыпчык. Җәен килеп кышын китә торганнардан сыерчык, карлыгач, тургай һәр җирдә күп.

Ерткыч кошлардан: бөркет, карчыга, ябалак, лачын, байгыш кошлары бар. Урманда очрый торган кошлардан – тукран, кәккүк, саескан; һәр җирдә күп сайрар кошлардан сандугач һәрбер агачлык урын да бар.

Көртлек, урман тавыгын һәр урманда очраталар. Кыр кошларыннан һөд-һөд, дүдәк һәр җирдә бар. Су кошларыннан аккош, торна, челән Кама, һәм Ак Идел буйларында, бигрәк тә Ак Иделнең түбәнге агымында җәй көне күп була һәм аңар аучылык итәләр. Татар илендә иң яратып аучылык ителә торган кошлардан – кыр үрдәге. Бу инде һәр җирдә күп, бигрәк тә Идел, Кама тугайларында, сазлыкларда күпләп-күпләп йөриләр. Еланнардан чага торган кара еланга башка җиз башлы кара елан һәр җирдә күп. Кәлтә еланының күп төрләрен һәрбер урманда, кырларда һәрвакыт очратып буладыр.

Татар илендәге агым сулардан Идел, Ак Идел һәм Камада һәрвакыт балык тотыла. Ләкин бу тирәдә пароходлар бик күп йөргәнгә, балыкны күпләп тоту юк. Шулай ук бу суларда балык тоту файдалы кәсеп урынында торадыр: җәй көне күп тотыла торган балыклардан стерлядь (чөгә), таран (лещ), җәен (сом), алабуга, судак (тешле), чуртан (щука), чабак, кызыл канат, табан балык (карась), эт балыгы (налим), осетр һәм селедка балыклары тотыладыр.

Татар илендә күлләр аз булганга, монда балык та аз тәрәккый иткән, күлләрдә күбрәк: табан балык, таран һәм алабуга күп буладыр.

**Татар илендә авыл хуҗалыгы**

Татар илендә башлыча авыл хуҗалыгын өч кәсепкә бүлеп йөртергә кирәк: 1) иген игү эше; 2) терлек асрау; 3) урман эше.

[1] Сурка – сурок, байбак.

Болар арасыннан иң күп каралганы – иген игү эшедер. Татар иле Русиянең икенче иле исәпләнгәнгә, ул үзе игелгән ашлыкның үз иленнән артканын читкә чыгарадыр.

Татар иленең һәммә җирендә иген игү эше бер юл белән бара. Бер ысулда эшлиләр. Русиянең бик күп җирендә булган төсле, Татар илендә әле иген игү өч кырлык ысулы бара, ягъни уҗым, сабан, такыр басу (парния[1]). Ике кырлык ысулы бер дә юк диярлек. Өч кырлык ысулында ел саен бер кырны, ягъни арыш, бодай чәчелгән кырга сабан ашлыгы чәчәләр. Инде өченче елда бу кырга бернәрсә дә чәчмичә ял иттерәләр. Бу елда бу кырда бары терлек кенә йөри.

Татар иленең һичбер җирендә диярлек күп кырлык ысулы кермәгән. Күп кырлык ысулында кырны чәчми буш калдырып ял иттермиләр, бәлки шул кырга ел саен чәчелә торган әйберне алыштырып торалар. Мәсәлән, бер елны арыш чәчелсә, икенче ел солы, аннан соң печән, аннан соң җитен, аннан соң бәрәңге, аннан соң инде янә арыш чәчәләр. Шулай итеп, басуны үсемлек белән алыштыру аркасында басуга ял иттерергә лязим булмый, бәлки ял иттерәсе урынга җирне яхшылата торган печән кебек үсемлек кенә чәчәргә кирәк буладыр. Менә бу ысул Аурупада бик күптәннән, Русиянең көнбатыш ягында яңа гына гамәлгә куела башласа да, безнең илдә бунын әле күренгәне юк. Җир кысрыкланса, ашлыкның уңмавы ешайса, халык үзе бу ысулның кирәклеген аңлап, өч кырлык ысулыннан күп кырлык ысулга күчәр дип өмид ителә.

Татар иленең һәммә җирендә дә халыклар бертөсле утырган диярлек, бер җирендә кысырык, икенче җирдә сирәк түгел. Шуңар күрә көн күрүләре дә бертөслерәк. Бөтен Татар илендә текә ярлы тау битләреннән ишелеп тора торган чокырлардан һәм әле киптерелеп өлгермәгән сазлыклардан башка су сакланмаган җир юк. Хәтта аз гына иген булуы көтелгән тау итәкләре дә сукаланган.

Татар илендә иген эше – бик борынгыдан бирле атаклы кәсеп. Шулай да җир яхшы яңартылмаганга, хәзер искергән. Җир тазарткыч мәгъдәннәр һич кулланылмый. Җир яңарту бик искедән бирле беленгән тиресләү ысулы белән. Ләкин тиресләү ысулы да тиресне берәр ел җыеп, черетеп булмаганга файдасы күп имеш. Иген коралларыннан Татар илендә агач суканы инде гамәлдән чыккан дип уй-

[1] Пар җире.

ларга ярый. Бары Лаеш, Мамадыш кантоннарының кайбер карарак авылларында агач суканы очратып буладыр. Ләкин һәммә җирдә диярлек ике көрәнле сабан белән җир сөрү гадәткә кереп киткән.

Машина белән сукалату бөтенләй юк диярлек. Двигатель белән суктыра торган «паровой машина», Спас, Чистай, Зөя кантоннарындагы боярлардан калган машиналар гына бар. Авыл халкы кулында юк. Аның урынына суырдыргыч (веялка) һәм ат җигеп суктыра торган машинаны һәр авылда табарга буладыр.

Су буйларындагы печән чаптыра торган машиналарны сирәк кенә очратып буладыр. Сукаланган җирнең йомшаруына, шуның белән бергә игеннең уңуына иң кирәкле булган тырмалау эше дә бик борынгы ысул белән барадыр. Һәрбер авылда кыска тешле тимер һәм агач тешле тырмаларны гына күреп буладыр. Урак уру, чәчү, җыю һәммәсе кадимге бабайлар ысулы белән барадыр.

Татар җөмһүриятендә иң күп игелә торган ашлык – арыш һәм солы ашлыгы. Арыш чәчелгән бөтен җир 1 044 000 дисәтинә булып, солы 623 000 дисәтинәдер. Шуннан калганы – карабодай, бодай, тары, борай, борчак, ясмык, бәрәңге, җитен кебек ашлыклар. Ләкин болар бик аз чәчеләләр. Бөтен кырның яртысы арыш кына чәчелгәнгә, күп вакыт иген уңышлы булмый. Чөнки авыл халкының җире нәрсә чәчсәң уңуы, нәрсә чәчкәч уңмавы әле бөтенләй тикшерелмәгән. Шуңа күрә җиренә карап ашлык чәчелми. Шул сәбәпле күп вакыт уңмыйча кала. Арыш җиренә карап чәчелмәгәнгә уңмаса, ярты кыр уңмады, дигән сүз буладыр. Шуның өчен дә Гарби Аурупада бертөрле игенне күп чәчмиләр, бәлки җирне чиксез күп шакмакларга бүлеп төрле иген чәчәләр. Шунлыктан анда бездәге киң яп-ялангач, ач та калмыйлар.

Уртача исәп белән уртача иген булган елны дисәтинәсенә илле пот арыш исәпләп, уңмаган елларны чәчүенә, ягъни 8 һәм 10 пот та булмаган еллар бар. Солы уртача 40 пот исәпләп йөртелә. Уңмаган елны ул да шулай чәчүгә дә җитми каладыр. Татар җөмһүриятендә уртача исәп белән 7–8 елга бер мәртәбә көчле ачлык була килә. Бу җиде-сигез елга бер мәртәбә көтеп алу дәрәҗәсендә гадәткә кереп киткән. Җир мәгъдән белән яңартылмаганга һәм терлек тә күп асрамагач, тирес белән яңарту да мөмкин булмаганга, Татар җөмһүриятендәге җирләр бер вакытта да искиткеч күп орлык бирә алмый.

Гарби Аурупада яңартылган һәм тиреслэнгән җирләрдә иген безгә караганда ике (Германия) һәм дүрт өлеш (Дания) кадәр артык җитешкән урыннар бар.

**Җимеш һәм яшелчә үстерү**

Татар илендә иген эше белән беррәттән җимеш һәм яшелчә үстерү эше дә – шактый тәрәккый иткән кәсеп. Югарыда әйткәнчә, яшелчә белән кала тирәсендәге рус авыллары гына шөгыльләнәләр. Бу авыллар бөтен Казан каласы халкын бәрәңге, суган, кишер, кәбестә белән туйдырып торган төсле. Шәһәрдән артканын Идел буендагы чит шәһәрләргә дә җибәрә иде. Җимеш үстерүдә иң күп таралган кәсеп – алма бакчаларын үстерү, тәрбия итү. Зөя, Тәтеш кантонлыкларында һәм азрак Лаеш, Спас кантонлыкларында ике миллион төпкә якын алмагачлар үрчетелгән. Алма уртача уңган елны дүрт миллион пот кадәр алма бирәдер. Шуның өчен бу кантоннар алма белән үз тирәләрен һәм шуның өстенә чит авылларны да тәэмин итә алалар.

Революциягә кадәр Казан тирәсендәге алманың бик күбесе Кама, Ак Идел шәһәрләренә һәм Себергә китәдер иде. Шулай ук Царицын[1], Астрахань шәһәрләре Казан тирәсеннән төшкән суган, бәрәңге белән туенып торалар иде. Кәбестә ел саен бик күп, вагонлап-вагонлап, Мәскәүгә җибәреләдер иде.

**Терлек асрау**

Татар җөмһүриятендә терлек асрау төп эшләрнең берсеннән исәпләнмидер. Чөнки терлек асрау өчен иң кирәкле булган киң далалыклар юк. Шулай ук терлек үрчетү өчен мәдәни рәвештә печән чәчеп үстерү дә әле гамәлгә куелмаган. Шуның өчен Татар җөмһүриятендә терлек халыкның үз кирәк-ярагына җитәрлек кенә асраладыр. Терлек арасында сарык иң күп асрала, эре һәм мөгезле маллардан – сыер, ат, тәвә[2] кебек терлек көнкүрештә кирәк кадәр генә тотыла. Сарык, сыер, кәҗә кебек терлектән халык бары үзе өчен җитәрлек йон, май, сөт әзерли, буны бер кәсеп рәвешенә кертә алмый, шулай ук вә терлектән файдалана торган әйберләр дә мул, кирәгеннән артып калырлык рәвештә түгел. Терлек туйдыру бик

[1] Хәзерге Волгоград.
[2] Тәвә – дөя.

начар куелган. Һичбер йортта үзенең терлегенә ел буена җитәрлек әзерләп куелмый. Җәй көне игелгән иген, җыелган печәне терлекләренә ел буенча бер үлчәү белән җитәрлек итеп исәпләп кую гадәте дә юк. Шуның өчен бервакыт терлеге чибәр генә тәрбияләнсә, кышка кергәч, сыер, сарык кебек маллар коры салам белән туеналар, печән яисә болгатып биру кебек азыклар бәйрәм азыгы төсле уйланалар. Шулай ук терлек асрауда беренче урынны тота торган терлек торырлык урыннар бик начар, суык, җил ыжгырып йөрерлек җимерек лапаслар гына була. Бу да терлеге көр, халык өчен файдалы итүгә зыян китерә.

1917 ел исәбе буенча бөтен Татар җөмһүриятендә терлекләрнең саны ошбу рәвешчә булган:

Атлар – 571 607.
Мөгезле эре терлек – 724 800.
Сарыклар – 2 137 814.
Кәҗәләр – 86 485.
Дуңгызлар – 287 052.

Кантоннарга бүленешләре (бөтен терлекләрне бергә кушып исәпләгәндә) ошбу рәвештә:

Арча кантонлыгында – 409 740.
Бөгелмә – 439 331.
Буа – 244 050.
Лаеш – 312 665.
Мамадыш – 313 671.
Минзәлә – 80 813
Зөя – 170 353.
Спас – 277 899.
Тәтеш – 263 757.
Чистай – 567 256.

Бөтен җөмһүриятнең кантоннары арасында терлек асрауда күзгә бәрелгән бертөрле аерма юк. Руслар белән татарлар арасындагы аерма – бары дини гадәтләре буенча дуңгыз асрауда гынадыр. Бөтен терлекне авыл көнкүрешенә каратып җан башына бүлгәндә, һәрбер йөз кешегә вак терлектән – 131 иген игәр, эшкә ярарлык эре терлектән 71 терлек төшәдер. Татар җөмһүриятендә терлек асрау эше шул рәвештәдер.

**Татар җөмһүриятендә җир биләү**

Октябрь революциясе җир биләүне бөтен нигезе белән үзгәртте. Чөнки революциягә кадәр Русия вилаятьләрендә җирне бик төрле рәвештә билиләр иде.

Авыл халкы дворян, хөкүмәт, удел, шәһәр идарәләре, хосусый кешеләр вә башка төрле хуҗаларның җирләре булып килде. Октябрь революциясе соңында бөтен җир бөтен хезмәт иясенә бирелде. Шуңар күрә хәзер югарыда күрсәткән исемнәр белән бүлеп йөртмиләр.

Шулай да Татар җөмһүриятендә җирне төрле кантоннарда төрлечә билиләр. Бөтен чәчелгән җирне кантоннарга бүлеп карасак, ошбу рәвештә булыр иде[1]:

Казан-Арча кантонлыгында – 183 175 дисәтинә.
Лаеш – 167 614 дисәтинә.
Мамадыш – 164 796 дисәтинә.
Зөя – 98 108 дисәтинә.
Спас – 185 149 дисәтинә.
Тәтеш – 152 692 дисәтинә.
Чистай – 297 745 дисәтинә.

Безнең кантоннарда җир һәрбер ашаучы башына бүленгән, революциянең беренче, икенче елларында җирне ел саен шобага белән бүлеп килгәннәр. Инде соңгы өченче елда җөмһүриятнең бик күп урыннарында алты елга кадәр иткәннәр; ел саен җирне бүлү авыл халкы хуҗалыгы өчен зарарлы, чөнки җирне һәр ел бүлгәндә, киләчәк елда бу җирнең кем кулына күчәчәген белмәгәнгә, бер ел өчен генә җирен тиресләми, яхшыртмый. Шуңар күрә бөтен кыр тиресләнмәгән килеш кала.

Кайбер авылларда бергәләп, артил белән җир биләүчеләр дә бар. Шулай ук кайбер авылларда сирәк кенә булса да җирне коммуна белән биләүчеләрне очратырга мөмкин. Артил һәм коммуна белән биләгәннәрнең ашлыклары күбрәк була, чөнки болар җирләрен яхшырак яңарталар, тиреслиләр.

[1] 1917 ел гомум авыл көнкүреше исәбе буенча Бөгелмә, Минзәлә, Буа кантоннары тугрысында бу елгы мәгълүмат кулымызда булмады. (*Авторлар иск.*)

**Кул һөнәре**

Татар җөмһүрияте игенчелек җөмһүрияте исәпләнсә дә, аның халкы иген кәсебе белән генә туенып тора алмый. Шуңар күрә 6–7 ай иген эшләп калган, 4–5 айда бүтән төрле эш эзләргә мәҗбүр. Шуның өчен Татар җөмһүриятендә иген эшеннән башка кул һөнәре дә – бик таралган хезмәт. Кул һөнәре аркылы эшләнгән әйберләрнең бик күбесе Татар җөмһүрияте халкының үзе өчен булса да, шактыйсы Татар җөмһүриятеннән тышка чыгарыладыр.

Иген эшеннән башка иң алда торганы – агач эше. Чөнки Татар җөмһүриятенең дүрттән бер кадәр урыны урманчылык белән капланган. Һәм Татар җөмһүрияте уртасыннан Идел, Кама һәм Вятка кебек зур елгаларның агуы да бу эшне бик үрчетәдер. Урман кисү, такта яру Арча, Лаеш, Чистай, Мамадыш, Минзәлә һәм Буа кантонлыкларында күбрәк эшләнәләр. Бу һөнәр кыш көннәрендә эшләнә. Кайбер авыллар кыш буенча урманнарда көннәрен үткәреп чыгалар. Язында шул эшләнгән агачларны су белән урмансыз якларга җибәрәләр. Шулай ук арба, чана, кисмәк, чыпта, кап эшләре – барысы да шул агач эшләредер. Янә күмер яндыру, сумала алу, скипидар ясау, кебекләр дә – урман эшләредер.

Арба-чана һөнәре бик күптәннән бирле. Казан кантоннары арба, тарантас һәм чана ясау белән дан чыгарганнар. Лаеш, Арча, Тәтеш, Зөя, Чистай, Бөгелмә кантоннары рус, татар һәм немец арбалары дип йөртелә торган өч төрле арба ясыйлар. Шуларга карап, чаналары да бераз бүленеп йөртелә.

Татар җөмһүриятеннән читтә яратып истигъмаль ителә[1] торган тарантаслар бигрәк Арча кантонлыгында Дербыш, Чебакса, Борисоглеб авылларында эшләнәдер. Бу һөнәрләр бик гади эшләнә. Һәрбер авылда, һәрбер гаилә үзенең өй эчендә эшләрлек кешеләре белән бергә эшлиләр. Аерым завод-фабрика кебек биналар кормыйлар, лапас, өй алды, яисә мал өе кебек урыннарда гына эшләнәләр.

Җүкә каезлау, кайры куптару, мунчала ясау, мүк җыю – барысы да Мамадыш, Спас, Зөя, Лаеш һәм Арча кантоннарында күбрәк эшләнә. Боларны эшләү яздан көзгә кадәр сузыла. Мунчаладан, җүкә, кайрыдан әйберләр күбрәк Бөгелмә, Буа, Мамадыш һәм Арча

[1] Истигъмаль ителә – кулланыла.

кантоннарында ясала. Чыта, каб эшләре күбрәк татарлар кулыннан үтә, чабата тугу эшен бөтен Русиянең һәммә авылында очратырга мөмкин, ләкин Татар җөмһүриятендә Мамадыш, Спас, Тәтеш һәм Арча кантоннарында бу эшне аерата яратып эшлиләр.

Татар җөмһүриятендә эшләнгән кисмәк такталары Русия эчендә генә тукталып калмый, бәлки Франциягә кадәр китәдер.

Кәрзин, бөккән урындыклар, тарантас читәне Арча һәм Чистай кантоннарында күбрәк эшләнә.

Балта осталыгы – татарлар һәм руслар арасында таралган һөнәр. Бигрәк күп балта осталары Чистай, Арча, Спас, Тәтеш һәм Мамадыш кантоннарыннан чыгып йөриләр.

Балта осталары, йорт, сарай, шундый каралты-кирәкләре эшләгән кебек, Идел буйларында баржа һәм кимә[1] ясау белән дә шөгыльләнәләр.

Агачтан кырып эшләнгән әйберләрдән савытлар, урындыклар, тәрәзә кысасы (рамы), агач тартмалар Арча, Бөгелмә, Чистай кантоннарында ясала.

Урмансыз, ягъни агачка ерак авылларда агач эшеннән бүтән эшләр белән мәшгуль булалар. Мәсәлән, бау үрү, эшлея, дилбегә вә башка ат-арба тирәсендәге җепләр, шулай ук камыштан төрле чыпта ясау, намазлык сугу кебек эшләр Бөгелмә, Мамадыш, Спас, Арча һәм Лаеш кантоннарында күбрәктер.

Тире эшләре. Сары тун эшләр өчен, сарык һәм бәрән тиресен иләү Бөгелмә, Арча, Зөя, Тәтеш һәм Спас өязләрендәдер. Авыллардагы тире иләүчеләр үз йортларында кечкенә генә завод сыман йорт-куралар, шунда чаннары, буйый торган кораллары була. Тире иләүчеләр читкә чыгып та эшлиләр. Каеш, күн, бияләй эшләре Чистай кантонында Богородский авылында, Арча, Мамадыш, Зөя һәм Бөгелмә кантоннарында эшләнә. Бу эш – Татар җөмһүриятендә искедән бирле танылган һөнәр. Шуңар күрә бу әйберләр күбрәк күрше вилаятьләргә җибәреләдер иде. Аяк киемнәреннән бигрәк күп эшләнә торганы – Шәрык өчен хәзерләнә торган хатын-кыз һәм ирләр читеге, Казан тирәсендәге бистәләрдә һәм Арча кантоннарындадыр. Аларга башка гомум аяк киеме Чистай, Спас, Мамадыш һәм Арча кантоннарында әзерләнә.

[1] Кимә – көймә.

Йон эшләре. Йоннан киез итек басу күбрәк Арча кантонында, Кукмара авылында һәм Чистай, Бөгелмә һәм Буа кантоннарында күптер. Бу кантоннарда йон эшләпә, киез, бурка, туфли һәм киез каталар да эшләнәләр. Йон эрләү, йон туку күбрәк Лаеш, Чистай һәм Арча кантоннарындадыр.

Тимерчелек, бакырчылык – бөтен кантоннарда таралган һөнәр. Тимерчелек ат дагалау, йорт-җир кирәкләрен булдырудагы һөнәрләр генә түгел, тарантас тимерен ясау, тәрәзә-ишек тоткаларын эшләү, божралар, йозак әйберләре, балта, караватвә башка шундый әйберләр дә эшләнәдер. Чистай, Тәтеш кантоннарында авыл хуҗалыгы коралын эшләү дә шактый үрчеп бара. Бакырчылык эшләренең иң күп эшләре – Лаеш һәм Мамадыш кантоннарында. Чиләк төпләү, ясау, тимер мич, тимер моржа ясау – барысы да Чистай кантонында. Алтын-көмеш эше күбрәк Лаеш кантонында таралган. Мәсәлән, «Рыбная Слобода» авылы бөтен тирә-якка үзенең көмешчеләре белән дан чыгарган.

Таш чыгару, кирпеч сугу эшләре. Идел буендагы кантоннарның барысында диярлек таш чыгару белән шөгыльләнәләр. Шулай ук Чистай һәм Спас кантоннарында чүлмәк ясау эше дә бик үрчегән. Кирпеч ясау – бөтен кантоннарда таралган һөнәр.

Шулай ук игенчелектән башка ау аулау, балык тоту – Арча, Чистай, Спас һәм Тәтеш кантоннарында үрчегән һөнәр. Кама, Идел һәм Ак Идел елгалары балык тоту һөнәрен шактый югары дәрәҗәгә мендергәннәр.

Өстән генә санап чыкканда, Татар җөмһүриятендәге вак һөнәрләр төрләре шунлардан тора. Техника күтәрелгән саен, бу вак һөнәрләр акрын-акрын бетәрләр, ләкин хәзер бу һөнәрләр халык хуҗалыгына бик күп ярдәм итәләр.

**Татар җөмһүриятендә сәнәгать (завод, фабрика эше)**

Татар җөмһүриятендә вак кул һөнәренең үрчүе, аның көннән-көн үсүе үзе үк бу җөмһүрияттә эре завод һәм фабриканың азлыгын күрсәтәдер. Чөнки зур завод һәм фабрикалар әйберне кечкенә заводларга караганда бик күп арзан төшерә һәм бик күп артык эш чыгара. Шуңар күрә зур завод, фабрика булган җирләрдә вак һөнәр эше күп үрчи алмый. Татар җөмһүрияте халкының егермедән бере генә завод һәм фабрика кебек эшләп чыгару

мөәссәсәләрендә[1] көн күрә. Калганнары барысы да авыл халкы хуҗалыгы белән шөгыльләнәләр. Иң зур завод һәм фабрикалар Казан шәһәрендә җыелганнар, Татар җөмһүриятендә эшләнә торган атаклы әйберләр: шәм, сабын, гөлсирин[2], күн, порох, күкерт кебек әйберләр. Янә он тегермәннәре, такта яру заводлары, йон тетү, бәз, тула эшләнә торган заводлар да бар.

Иң зур һәм бөтен Русиядә атаклы заводлардан: порох заводы, хәрби әйберләр хәзерли торган Алафузов заводлары, янә шәм, сабын, гөлсирин эшли торган Крестовников заводлары.

Советлар Русиясе өчен Казандагы порох эшли торган заводлар иң кирәкле һәм иң күп эш чыгара торган заводлардан исәпләнәләрдер. Чөнки Гражданнар сугышы вакытында советлар Русиясендә бүтән җирдәге порох заводлары төрле сәбәпләрдән эшләмәделәр. Алардан сугыш өчен порох килмәде, бөтен фронтлар өчен өзлексез порох әзерләп торучы «чишмә» Казан тирәсендәге порох заводлары булды. Порох заводлары көн-төн туктамый эшлиләр, бөтен эше хәрби нигезгә куелган.

Крестовников заводы да Казанда бик иске заводлардан. Бу завод – 1860 елларда корылып эшкә тотынган завод. Бунда эшләнеп чыккан шәм һәм сабын бөтен Русиядә, хәтта чит мәмләкәтләрдә дә атаклы. Сугышка кадәр Крестовников заводы елга бер миллион пот шәм эшләп чыгара иде. Шулай ук гөлсирин һәм сабын бик күп эшләнәдер иде. Боларга башка Казанда Арсланов[3], Үтәмишев[4], Пекин заводлары елга бер миллион ярым пот чамасы сабын, гөлсирин кайнаталар, йон тетү, юу заводлары да бар. Казанда иң искедән бирле күн эше эшләнә. Шулай ук күннән итек вә башка аяк киемнәре хәзерләнә. Мәсәлән, бер Алафузов заводы сугышка кадәр елга 500 мең пар итек әзерлидер иде. Сугыш вакытында Алафузов заводлары бары хөкүмәткә генә эшләгәнгә, эшләп чыгару хасиятләрен тагын арттырдылар. Шулай итеп, сугышка кадәр Казандагы

---

[1] Мөәссәсәләрендә – оешмаларында.

[2] Гөлсирин – глицерин.

[3] Исхак Арслановның (1852–1901) сабын һәм глицерин җитештерү заводы.

[4] Мөхәммәдгариф Үтәмишев (1830–1893) 1888 елда Г.Х. Якупов һәм М.А. Усманов белән берлектә Казанда «Үтәмишев вә К° мануфактурасы» ширкәте оештыра. Киҗе-мамык тукымалар ману фабрикасын төзи һәм сабын кайнату белән шөгыльләнә.

күн заводлары елга ике миллион баш эре мал тиресе, дүрт миллион данә вак мал тиресе китерелеп эшләнә килде. Болгар күне, сәхтиян (сафьян күне) – Казанның атаклы эшләреннән. Боларга башка Казанда һәм Казан тирәсендә тегермән-заводлар да шактый урын тота. Мәсәлән, Казаннан ун чакрым җирдә Идел буендагы Акунишников тегермәне – үзенең онны ярмалы рәвештә тартуы белән бөтен Русиядә атаклы тегермән. Бу тегермән сугышка кадәр елга өч миллион пот бодай артып чыгарадыр иде. Татар җөмһүриятендә әлегә күзгә бәрелгән һәм халык көнкүреше өчен әһәмияте зур булган завод-фабрикалар шулар. Боларга башка тула, бәз фабрикалары булса да, алар ул кадәр зур урын тота алмыйлар. Мәгъдән[1] заводлары әле үрчемәгән.

**Татар иленең кыскача үткәне**

Татар җөмһүрияте урынында борынгы заманда кемнәр утырган?

Бу сөальгә кыскача гына булса да җавап бирергә кирәк.

Моннан мең ел артык электә хәзерге Татар җөмһүрияте урынында «Болгар» исемендә атаклы мәдәни бер мәмләкәт булган.

Болгар мәмләкәтенең төп халкын «Болгар халкы» дип йөрткәннәр. Борынгы «Болгар» иленең чикләрен аермачык күрсәтеп булмый, шулай да ул мәмләкәттә Нократ (Вятка), Чулман (Кама), Чирмәсән, Ахтай, Ак, Зәй, Кечек Чирмешән, Олы Чирмешән, Сая, Мишә елгалары кебек елгаларның барлыгын әйтергә мөмкин. Шулай булгач, борынгы Болгар мәмләкәте дә хәзерге Татар җөмһүрияте урынында булганын күрсәтәдер. Хәтта аның чикләре безнең җөмһүрият читендә, тышта киңәйгәнен белеп буладыр.

Борынгы Болгар мәмләкәтендә безнең заманга кадәр бик аз әйберләрнең эзләре калган, кайбер урында Болгар мәмләкәтендә сугылган акчалар табыла, төрле йорт, шәһәр урыннары, кабер ташлары чыга, Болгар шәһәре урыны да әле җимерелеп бетмәгән, манара, мәдрәсә, мунча биналарының хәрабәләре бар.

Болгар халкы иске-искедән бирле ерак җирдән килә торган гарәпләр, фарсылар, ерак төрекләр, шомахилар[2], славяннар белән алыш-биреш иткәнгә, болгарларның шәһәрләре дә күп булган.

[1] Мәгъдән – металл.

[2] Шомахи – бүгенге Азәрбайҗан территориясендә булган тарихи өлкә. Шомахилар шул өлкәдә яшәүчеләр.

Безнең заманга исемнәре калган шәһәрләрдән иң атаклысы: Казан шәһәреннән 123 чакрым Идел агымы белән төшкәч, Спас шәһәреннән 25 чакрым гарәп җәнүбигә таба «Болгар» исемендә бер зур шәһәр булган. Бу шәһәр «Болгар» мәмләкәтенең пайтәхете булган.

Шулай ук Чистай кантонлыгында Кечек Чирмешән буенда «Бүләр» исемендә (хәзер «Посад Билярова» дигән зур рус авылы) мәшһүр зур шәһәр булган.

Янә Самар вилаяте белән электәге Казан вилаяте чигендә, хәзер «Кузнечиха» дигән рус авылы урынында «Сувар» исемендә бер шәһәр булган, шулай ук Чистай кантонлыгында «Тубылгы Тау», Нижний Новгород шәһәре урынында «Ибраһим кальгасы» (Ибраһимов) кебек шәһәрләр булган.

Болгар халкы авылларда башлыча иген игү, мал асрау һәм шәһәрләрдә һөнәр, сәнәгать эше һәм алыш-биреш белән шөгыльләнгәннәр.

Хәзерге Идел буенда беренче мәдәни үсемлек үрчетү шәрәфе борынгы Болгар халкы өстенә төшәдер.Чөнки болгарлар игенне бик тырышып пөхтә эшләгәннәр. Аларның ашлыклары үзләреннән арткан. Күрше халыклар белән кадерле җәнлек тиресенә, төрле мәгъдәннәргә алыштырганнар.

«Болгар» мәмләкәтендә бүз[1] туку, тула сугу, шәм кою, сабын кайнату атаклы һөнәрләрдән исәпләнгән. Янә сәхтиян күнен эшләү, Болгар күне, сауры[2] эшләү – барысы да болгарларның яраткан һөнәрләре булган.

Болгар мәмләкәтендә эшләнгән төрле сугыш кораллары, фарфор, пыяла, ахак кебек ташлардан ясалган сәдәп, алка, муенса, беләзек, йөзек, шулай ук каптырма һәм төрле бизәнү әйберләре һәм җиз, көмеш, пулат вә башка мәгъдәннәрдән эшләнгән нәрсәләр бөтен Шәрык һәм Гареб халыклары арасында күпләп-күпләп таралган.

---

Болгарлар гыйлем, мәдәният ягыннан күршеләреннән югары булсалар да, саннары аз булганга, бервакыт та тыныч тора алмаганнар.

---

[1] Бүз – бәз.
[2] Сауры – савыр күне.

Аларның күршеләреннән мәдәнияттә түбән, саннары күп халык славяннар булганга, алар әледән-әле болгарларны килеп борчыганнар. Бигрәк тә ачлык елларны славяннар Болгар иленә «азык ауларга» чыкканнар.

Еш-еш баскыннар сәбәпле, үзләре корган мәдәниятне саклап алып бара алмаганнар, чөнки славяннарның «Болгар» мәмләкәтенә 15–16 мәртәбә һөҗүм итеп, талап киткәннәре тарихка мәгълүм.

Янә шулар өстенә 1237 елда Монголия сахрасында монгол-төрек[1] халкыннан төзелгән Бату ханның көчле явы «Болгар» мәмләкәте өстенә килеп чыгып, Болгарны күтәрелмәслек дәрәҗәдә харап иткәннәр. Һәм шул вакытта «Болгар» мәмләкәтенең истикъляллиятен[2] югалткан дип йөртелергә буладыр. Чөнки бундан соң «Болгар» мәмләкәте татар ханнарының провинцияләре булып исәпләнде, һәм татар бикләре, татар морзалары тарафыннан идарә ителде.

Бу чагында кирәк татар бикләре, кирәк славяннарның кинәт һөҗүме сәбәпле ясалган җәбер-золымнар «Болгар» халкын мәмләкәтләрен ташлап кыргыз сахраларына, урман араларына качарга мәҗбүр итте.

Янә «Болгар» иле татарлар хакимиятенә күчкәч, ул үзенең истикъляллияте белән бергә төзеклеген һәи икътисади байлыгын югалтты.

Буның югарыда күрсәтелгән сәбәпләреннән башка, татар хакимиятенең, Алтын Урда мәмләкәтенең пайтәхете «Сарай» шәһәренең сәүдә һәм икътисад ягыннан күтәрелеп китүедер. Чөнки буңа кадәр «Болгар»га килеп алыш-биреш итә торган чит ил сәүдәгәрләре, «Сарай» шәһәре күтәрелгәч, малларын Сарайга гына китерә торган булдылар; Болгарга барырга кирәклек табылмады. Кыскасы, Алтын Урда мәмләкәтенең Сарай шәһәре «Болгар» шәһәре урынын алды. «Болгар» шуның белән Шәрык мәмләкәтләре арасында үзенең Аурупадагы сәүдә алышу мәркәзе әһәмиятен югалтты. Бәлки шул тирә өчен генә әһәмиятле бер шәһәр булып калды. «Болгар» мәмләкәтенең бетүенә бу сәбәпне тагы да көчлерәк дип уйларга кирәк.

[1] Төрек – төрки мәгънәсендә.
[2] Истикъляллиятен – бәйсезлеген.

**Казан падишаһлыгы**

XV йөзнең урталарында Алтын Урда мәмләкәтенең тәмам җимерелеп, таралып беткән чорларында борынгы атаклы Болгар иле урынында «Казан падишаһлыгы» исемендә яңа бер мәмләкәт төзелә. Тиз арада бу мәмләкәт тирәсенә Алтын Урдадан чыккан атаклы бикләр, морзалар, тарханнар, шулай ук Болгар иленнән калган сәүдәгәрләр, бикләр җыелалар. Мәмләкәтне чынлап хәрби оешкан бер мәркәз рәвешенә китерәләр.

Мәмләкәтнең пайтәхете Казан шәһәре була. Ләкин бу Казан падишаһлыгы Алтын Урда кебек көчле мәшһүр бер мәмләкәтнең хәрабәсеннән калган морзалар, бикләрдән генә төзелгән бер мәмләкәт булганга, ул чагында күчерелгән славян кенәзләре белән көрәшеп, үзенең истикъляллиятен саклап торыр дип уйларга мөмкин түгел иде. Шулай да Казан кинәт борынгы Болгар һәм Сарай шәһәрләренең икътисади урынын тотып киткәнгә һәм, Казан падишаһлыгы гаскәре башында талантлы мөдирләр торып, Мәскәү кенәзлегендә – кенәзләр белән боярлар низагысы бик көчле булганга, берникадәр заманга Казан падишаһлыгы үзенең истикъляллиятен саклап килә алды.

Ләкин бу вакытлы саклау, вакытлы истикъляллият иде, чөнки Мәскәү падишаһлыгы көннән-көн Мәскәү суы, Ока сулары буеннан Идел һәм Урал буена җәелергә омтыла, шунда киңәюне бөтен мәмләкәтнең төп сәясәте итеп тота, бу юлда торган комачаулык белән ригаясез көрәшергә нинди генә корбаннар белән Казан арасында, Идел-Урал буенда өстенлек өчен 70–80 ел өзлексез сугышлар сузыла. Актыгында, XVI йөзнең урталарында, 1552 елда Казан падишаһлыгы үзенең истикъляллиятен тәмам югалтып, бөтен Казан падишаһлыгы Мәскәү падишаһлыгының мөстәмләкәсенә[1] әйләнә.

---

Казан падишаһлыгының төп халкы төрек телендә сөйли торган татарлар иде. Янә татарларга башка фин ыруыннан ар, мордва, мари кебек халыклар булган кебек, Урал итәкләрендә башкортлар да бар иде.

Казан падишаһлыгында иген игү, умартачылык, мал асрау һәм урман эшләренә, башка алыш-биреш эше бик киң рәвештә куелган

[1] Мөстәмләкәсенә – колониясенә.

иде. Чит мәмләкәтләрдән килгән сәүдәгәрләр өчен Казанда хосусый сәүдә йортлары, шул мәмләкәтнең сәфарәтханәләре[1] булган. Бохара, Иран, Шомахи, Әрмәнстан, Гарәбстаннан килгән маллар, Гаребтән килгән Новгород, Герман һәм Скандинавия халыклары сәүдәгәрләре китергән маллар белән алыштыралар. Алар белән һәмишә мөнәсәбәттә булалар.

Казанда ел саен бер мәртәбә зур базар була (ярмарка). Бунда бөтен дөнья сәүдәгәрләре үзләренең малларын китерәләр, бер еллык алыш-биреш ясыйлар иде.

Казан падишаһлыгы болардан тиешле салым җыйганга, сугыш вакытларында акчага күп аптыраганын белдерми. Шуңар күрә булырга кирәк, Өченче Василий, Казанны икътисади яктан аптыратыр өчен, рус сәүдәгәрләренә ел да була торган Казан базарына килергә мәнгы итә[2]. Казан белән Нижний Новгород арасында булган, Идел буендагы, Макарьев шәһәрендә сәүдә мәркәзе ясарга боерык бирә. Казан үзенең икътисади көчен югалткан соңында, Макарьев ярмаркасы Казан базары урынын тота. Татарлар арасында «Мәкәрҗә» дип йөртелә торган ярмарка шуннан калган. 1817 елда Беренче Александрның боерыгы белән Макарьев ярмаркасы – Нижний Новгородка күчә.

---

Казанда мәмләкәтнең идарәсе хакиме мотлак (абсолютист) булган хан кулында иде. Хан тирәсендә атаклы аристократлар җыелалар. Болар – ханның киңәшчеләре, Казанның аристократлары. Нәселләренә карап мәртәбәләр төрлечә иде. Алар морза, бик дәрәҗәләренә бүленеп йөртеләләр. Морза Һади аксөяк, бикморзаларның атаклырагы. Аның дәрәҗәсе морзадан күп югары була. Инде кайберләре Алтын Урдадан килгән мангыт, тичак, ширин, аргын кабиләләреннән булса, алар карачы дәрәҗәсен алып, алар хөкүмәтнең үзгәрмәсен әгъзалары исәпләнәләр иде.

Хан янында һәмишә, шул морзалардан төзелгән вә углан исемендәге гвардия гаскәре буладыр иде.

[1] Сәфарәтханәләре – илчелек б업алары.
[2] Мәнгы итә – тыя, рөхсәт бирми.

Байлар – зур акча ияләре мәмләкәттә мәэмүрлек бурычын үтиләр. Ләкин болар мәмләкәттә нөфүз[1] иясе түгелләр.

Руханилар мәмләкәттә зур урын тоталар. Руханилар башында «Сәйид» тора. Ул бөтен дин эшен үзлегеннән башкара. Сәйидне хөрмәт итәләр, мәсәлән, хан Сәйид белән очрашканда, аны олуглап, аңа каршы барып, аның кулын үбә, гади халык Сәйиднең киеменә бәрелү, яисә атына кулларын тиерү белән шатланалар иде. Сәйид ханның дөнья эшләренә катыша. Чит падишаһка җибәрелгән рәсми кәгазьләрдә хан, бик һәм Сәйиднең исеме дә искә алына иде.

---

Казан падишаһлыгында тышкы яктан өзлексез Мәскәү белән көрәшү булса, эчтән тәхет, түрәлек өчен партия яклашуы барды. Партия дигәч, бунда икътисади, иҗтимагый, гомумән халык көнкүреше өчен яклашу түгел, бәлки тәхте сарай өчен яклашу иде.

Ике көчле партия дәвам итте: берсе Кырым, икенчесе Мәскәү партиясе. Һәр ике партиянең башында атаклы бикләр торалар.

Кырым партиясе тарафындагы бикләр Казан падишаһлыгы тәхетендә Кырым ханнарыннан берәүне һәм бөтен Казан падишаһлыгының сәясәтен Кырым ханлыгына баглап йөртү ягында.

Мәскәү партиясе тарафында булганнар Казан тәхетенә Мәскәү киңәше белән хан кую һәм Мәскәү сәясәте белән баруны яклаучылар иде.

Боларга башка янә өченче «Нугай» партиясе бар иде. Ләкин бу әйтерлек зур нөфүзле түгел иде.

Халык һәм гаскәр дә шул ике партиянең берсенә ияргән. Иң кызу көрәш вакытларында шул ике партиянең берсе ноктасыннан хәрәкәт итәләр иде. Ханнарның әледән-әле алмашып торуы, мәмләкәт өчен нык сәясәтнең булмавы, барысы да шул тәхет низагысыннан килгән. Актыгында, Мәскәү Казанга якын торганга, аның гаскәре һәм байлыгы да Кырымга караганда артык булганга, Мәскәү партиясе җиңде. Казан ханлыгы Мәскәү кенәзлегенә күчте.

Мәскәү кенәзләре сугышып алынган һәрбер җирне үзләренең хосусый милекләре дип исәплиләр иде. Шуңар күрә андагы җир, су, урман байлыкларын теләгән кешеләренә бүләк рәвешендә, кайберенә санап та бирәдер иде. Мәскәү кенәзе Дүртенче Иван да

---

[1] Нөфүз – авторитет.

Казан падишаһлыгы белән шулай мөгамәлә итте. Ләкин Казан падишаһлыгы һәм аның борынгы түрәләре һәм байлары мөстәкыйль мәмләкәт идарәсендә тәрбия ителгәнгә, «Болгар», «Алтын Урда» мәмләкәтләренең шанлы тарихы әле бөтенләй онытылып бетмәгәнгә, Мәскәү падишаһына Казан ханлыгын катгый рәвештә Мәскәү падишаһлыгының өзелмәс бер кисәге итеп тоташтыру шактый бер авыр эш иде.

Нинди авыр эш булса да, Казан ханлыгын Мәскәү җире итәргә һәм андагы халыкларны борынгы татар бикләре, татар морзалары тәэсиреннән чыгарырга кирәк иде.

Бу теләгенә ирешү өчен Мәскәү өч юл тотты:

1 – Казан падишаһлыгы җиренә русларны күчерү.

2 – Рус кенәзлегендә булган идарә ысулын кертү.

3 – Рус булмаганнар арасында христиан динен тарату.

Казан падишаһлыгы Дүртенче Иван заманында Иванга ошамаган боярларның күчеп килә торган урыннарына әйләнде. Шуңар күрә Дүртенче Иван үз заманында Казан тирәсенә бик күп атаклы, борынгы нәселле боярларны күчерде. Алар бунда теләгәнчә җир, судан файдаландылар. Шулай ук 1556 елларда Псков һәм Новгород сәүдәгәрләрен, боярларын күпләп-күпләп Казанга күчереп, Казанның борынгы сәүдәсен шул яңа килгән русларның кулына бирергә тырышты. Яңа күчеп килгән кешеләргә җир бирүдә, сәүдә эшендә, салым түләүдә, шәһәрнең уртасында урын алуда артыклыклар күрсәтелде.

Ул заманда Казан тирәсендәге кадерле җирләр, сулар татарлар кулыннан алынып, рус түрәләренә, попларына бүләк итеп бирелде. Мәсәлән, 1555 елда «кечкенә Кабан күле» аның тирәсендәге бөтен урманнар һәм сусар, кондызлы сулар Гурий[1] попка бүләк итеп бирелгәннәр иде.

Шуның белән бергә төп җирле халыкны төрле салымнар, авырлыклар белән икътисади ярлылыкка төшерелде; җирле түрәләр, бәк, морзалар гади халыкка караганда югары дәрәҗәдә исәпләнсә дә, аларның кузгалуыннан шөбһәләнеп, аларны һәмишә[2] халыктан ераграк җибәрү сәясәте тотылды.

[1] Гурий (Руготин Григорий, 1500–1563) – дин эшлеклесе, миссионер. Казан епархиясенең беренче архиепископы (1555–1563).

[2] Һәмишә – һәрвакыт.

**Идарә**

Казан падишаһлыгы Мәскәү кенәзлегенә тоташуы белән Мәскәү идарә рәвешен кабул итәргә мәҗбүр иде. Мәскәү кенәзлеге Казанны озак вакытка кадәр бөтенләй хәрби идарә астында алып барды. Киң мәмләкәтне идарә итәргә уңайрак булсын өчен, Казан падишаһлыгын берничә кисәккә бүләргә кирәк иде. Ул кисәктә берәр урынны кальга (крепость) шәһәр итеп сайлана, шунда даими гаскәри фиркаләр куела килде (Арча, Мамадыш, Зөя). Бөтен өлкәне идарә итәр өчен кенәз тарафыннан «бөек воевода» билгеләнә, аңар ярдәмче буларак ике кечек воеводалар билгеләнәләр. Болар аталык һәм нәселле боярлардан булырга тиешләр. Өлкәнең бөтен язу һәм хөкем эшләрен башкару «дьяк» дип йөртелә торган гади кешеләрдән куелган түрәләргә тапшырыла. Болар башта бөтен Казан ханлыгында 11–12 кеше иде. Боларның янә «поддьяк»[1] дигән ярдәмчеләре дә була: халык арасына иң күп кушылып йөрүчеләр «йөз башчылары» (сотниклар) исемендәге түрәләр. Болар халык арасыннан сайланып куелырга тиешләр. Болар ясак җыя, халык тынычлыгын карый, приказларны белдерә, аларның гамәлгә куелганын тикшерә, кыскасы турыдан-туры халык белән эш итә. Болар күп вакытта җирле халыктан буладыр иде. Ясак (салым) җан башыннан, яисә йорт башыннан алынган. Күп вакытта ясакны, берәр кешегә печеп[2] бирә торган булганнар. Ясак бирмәү – баш тартудан исәпләнеп, аның өчен иң авыр җәзалар ясаладыр иде. Воеводалар Мәскәүдән бик зур вәкаләтләр алып кайталар, хакимияткә буйсынмаучыларны үлем җәзасына хөкем итәләр, бундый чакларда воеводалар хаким мотлак[3] исәпләнәдер иде. Воеводалар үзләренең хокукларыннан артык эш күргәнгә, халык алардан бер дә разый түгел, чөнки воеводалар хөкүмәткә никадәр ясак җыйсалар, үзләре өчен дә шулкадәр җыялар иде.

Жирле халыкны бәйләү, урынсызга зинданнарда асрау, хатын-кызларны җәберләү, балаларын көчләп алу кебек золымнар түрәләрнең гади эшләре иде. Мәсәлән, 1667 елда бер воеводага Мәскәүдән килгән рәсми кәгазьдә: «чирмешләрне алалар да аларны өйдә асрыйлар икән», диелгән. Хөкем эшләрендә канун юк, тәртип юк, һәрбер түрә теләгәнчә, үзенең нәфесенә ошаганча хөкем итә.

[1] Поддьяк – дьякның ярдәмчесе.
[2] Бүлгәләп мәгънәсендә.
[3] Мотлак – чикләнмәгән, бәйсез.

Түрәләрнең төрле җәзаларыннан, урынсыз золымнарыннан котылыр өчен, җирле халыклар монастырьлар, поплар ярдәменә сыгыналар, христиан динен кабул итәләр иде.

---

Казан җирен Мәскәү мөстәмләкәсе[1] итүдә өченче чара – руслаштыру сәясәте иде. Руслаштыру сәясәте иң көчле һәм зур әһәмият бирелгән як булды. Шуның өчен, Казан ханлыгы Мәскәү хакимиятенә күчкәннән бирле, ислам белән христиан диненең көрәше, дин өчен булудан бигрәк, мал һәм җир өчен иде. Мөселманнарның морзалары, бәкләре ислам динен саклаган булып, үзләре тирәсендә мөселман ярлыларын күбрәк тоталар, аларны арзанрак эшләтәләр, аларның җирләрен сатып алган булалар – кыскасы дин каплавычы астында мал һәм җир иде.

Шулай ук христиан динен тарату да җир һәм мал өчен булып китте. Христиан алпавытлары, христаин түрәләре – татар алпавытларының яхшы җирләрен үзләренә күчерү һәм артык ясак җыяр өчен, алар арасында дин тарату исеме белән кешеләр җибәрәләр, аларны тыңламадылар дигән булып, аларның җирләрен алалар, малларны үз кулларында калдыралар, һәртөрле канунсызлыкларны эшлиләр.

Дин тарату – низагысы – дин, турылык өчен түгел, бәлки көнкүреше өчен иде.

Бу юлда хөкүмәт тарафыннан эшләнгән берничә мәҗбүри тәдбирләрне[2] искә төшереп китәмен:

1 – Казан тирәсендә аерым хокуклар белән монастырьләр эшләтелде. Бу монастырьләр Казан тирәсендәге иң яхшы файдалы җирләрне беркеттеләр дә, шуннан шул җиргә рус булмаган боярларны, җиргә кызыктырып чакыра башладылар, чөнки монастырьның җир бирүгә башка тагын берничә артыклыклары бар иде. Мәсәлән: сату-алу эшендә башкаларга караганда артыклык, монастырь җирләрендә утырган халыкка җәбер, золым итүче түрәләрнең үзләре өстеннән хөкем итү кебекләр. Шуңар күрә бик тиз арада монастырь җирләренә күчеп килүчеләрнең саннары шактый арткан, хәзер Зөя монастыре тирәсендә утырган кешеләр – шул хокуктан файдаланучылардыр.

---

[1] Мөстәмләкәсе – колониясе.
[2] Тәдбирләрне – чараларны.

2 – Шулай да чукынган татарлар рәсми христиан булып иктисади хокуклардан файдаланалар да, поплар теләгәнчә христиан динен тотмыйлар, шуңар күрә 1593 елда Казан җиренә җибәрелгән зур поп Гермоген[1] Мәскәү кенәзенә ошбу рәвештә яза: «Казан һәм Зөя өязләрендә яңа чукынган татарлар, чуашлар, чукынмаган татарлар белән бергә торалар, өйләренә тәре куймыйлар, попларны чакырмыйлар, рәсми никахларны чиркәүдә ясыйлар да – үзлекләреннән янә үзләренчә никах укыталар», – дип зарланып яза.

Шуннан соң Мәскәүдән – христиан динен таратыр өчен, гражданнар тәдбире кылә: чукынган татарларны чукынмаганнардан аерып, үзләренә бер бистә төзергә, бистәгә чыкмаганнарын берәр ышанычлы христианга тапшырырга яисә зинданга ябып куярга.

3 – Чукынучыларның азлыгын морзалар, бәкләрнең тәэсиреннән дип уйлап, 1681 елда: татар морзалары әгәр дә үзләре христиан диненә чыкмасалар, аларның җирләрендә утырган христианнарны һәм мукшыларны азат итәргә, морзаларның җирләрен алып, христиан динен кабул иткән морза һәм бәкләргә таратырга дигән закон игълан ителә. Буның морзаларга тәэсире зур булганга, бундан соң зур-зур фамилияле морзалар христиан динен кабул итәләр, христиан динен тарату шул рәвештә бара.

Казан ханлыгы һәмишә шул дин талашы белән бара. Бу дин талашы халыкның көнкүрешенә һәм аның мәдәниятендә бик күп зарар итә, һәм төрле түрәләр, алпавытларга халык өстеннән теләгәнчә җәбер, золым ясарга юл ача...

---

Шулай ук Беренче Пётр[2] дәверендә дә христианлык тарату туктап тормый, бәлки көчәйтелде. 13–17 елда Пётр I: «Казан җирендә булган морзалар ярты ел эчендә христиан диненә чыкмасалар, имениеләре алыныр һәм, шул фәрманга нигезләнеп, 27 ноябрьдә андый морзаларның «авылларын алырга» дигән фәрман кылә.

1730 ел 6 мартта – христиан динен кабул итмәгән өчен алынган авылларны – морзаларның христиан динен кабул иткәннәренә би-

---

[1] Гермоген (Ермолай, 1530–1612) – православие дине эшлеклесе, Казан һәм Әстерхан митрополиты (1589–1606), Мәскәү һәм бөтен Русия патриархы (1606–1612). 1913 елда Рус Праваславие чиркәве тарафыннан изге дип танылган.

[2] Пётр Алексеевич Романов (Пётр I, 1672–1725), 1682–1721 елларда рус дәүләте патшасы, 1721 елдан Россия императоры.

рергә, дигән тәдбир була. Вә башка шундый тәдбирләр күп. Мин аларны бунда санап тормыйм ...

**Иҗтимагый һәм милли хәрәкәт**

XVII йөзнең башларына кадәр татар аристократиясе үзенең милли төсен, шанын югалтмаска тырышты. Әүвәлге буйсынуны да күрсәтә иде, үз тирәләрендәге чирмеш, чуашларны оештырып, рус җирләренә барып баскынчылык та итеп кайталар иде, ләкин бунын нигезе үзләренә мал талау, җирләрен саклау, ярлы авыл халкын ныграк эшләтү булганга, бу бервакытта да зур халык хәрәкәтенә әйләнмәде, шуңар күрә 1553 елдан 1557 елларга кадәр сузылган бундый күтәрелешләрнең берсе дә зураеп китә алмадылар.

XVI һәм XVII йөзнең соңнарында Идел буе татар аристократиясенең Кырым һәм Төркия белән мөнәсәбәттә булганы мәгълүм. Ләкин бу да фәкать аристократия арасында гына урын тотып, халык хәрәкәтен ясарлык дәрәҗәдә булмаганга әһәмияте юк иде.

Дөрест, 1571 елда Кырым ханы ике йөз гаскәр белән Мәскәүгә һөҗүм итеп, Мәскәүне яндырды, буны – Идел буе татарлары үче, диеп тә сөйләде, бу да кинәт булып узган вакыйга гына иде.

Билгеле бер план белән эшләнгән хәрәкәт түгел иде.

1606–[160]8 елларда Идел буе чирмешләре белән чуашларның гомумхәрәкәткә кушылып, Ялган Дмитрий яклы Нижний Новгород һәм Зөя тирәләрендә сугышканнар. Ләкин Зөя янында нык җиңелгәннәр. XVII йөзнең 70 нче елларында Разин[1] хәрәкәтенең дулкыны Идел буена, Казан ханлыгы җиренә килеп җиткән иде. Шуңар күрә бу хәрәкәткә Каманың түбәнге агымы буенда утыручылар, Сөри суы буендагы чирмешләр һәм Вятка суы буендагылар барысы да катышып, «һәрни һәркемгә тигез» лозунгысы белән йөрделәр. Үзләре арасыннан «атаман, есаул» сайлап, хәрәкәтнең уртасында булдылар. Мәскәү ягында булган авылларны яндырып, очраган бер боярны бөтен гаиләсе белән үтереп йөрделәр.

Казан падишаһлыгы җирендә иң зур халык хәрәкәтләреннән Пугачёв[2] хәрәкәтен санарга кирәк. 1774 елда Пугачёв Красноуфим,

[1] Степан Тимофеевич Разин (1630 тирәсе–1671) – Дон казагы. 1670–1671 еллардагы крестьян сугышлары җитәкчесе.

[2] Емельян Иванович Пугачёв (1742 тирәсе–1775) – Дон казагы. 1773–1775 еллардагы крестьян сугышлары җитәкчесе.

Шадрин һәм Уса өязләре тирәсендә башкорт, мари, ар халыкларыннан җыйган күп гаскәр белән Казан падишаһлыгы җиренә керә. Бунда да аңар чуаш һәм мари авыллары кушылалар, чөнки Пугачёв аларны коллыктан бөтенләй коткарырга, боярларның җирләрен алып бирергә, сәяси ирек бирергә вәгъдә итә. Казан һәм Мәскәү берләшеп, бу хәрәкәткә никадәр каршы чаралар кылып карасалар да, рәтле муаффәкыять[1] таба алмыйлар. 1774 елның 12 июнендә Пугачёв үзенең егерме мең гаскәре белән Казанга килеп, Казан шәһәрен ала. Татарлар, башка хаким милләт булмаганнар – барысы да Пугачёвка буйсыналар, татарлар икмәк, су белән каршы алалар. Пугачёв гаскәренә төрле ярдәмнәрдә булалар: күңелле[2] булып язылалар. Шул вакытта Казан бөтенләй яна. Пугачёв Казанның Кремлен (кальга) ала алмаганга, мәркәздән килгән Михельсон[3] фиркасе тарафыннан җиңелә дә янә башкорт сахраларына, Урал буйларына чигенергә мәҗбүр була. Ләкин бу хәрәкәт шул елны гына бетми, бәлки озак вакытка кадәр дәвам итә. Бу хәрәкәттә иң нык алдан йөрүчеләр башкортлар һәм Оренбург, Җаек казаклары иде.

1708 елны башкортларның Казан падишаһлыгы җиренең Казан һәм Уржум тирәсенә килеп, шундагы авылларны яндырып йөрүләре, авыллардан халыкны әсир итеп башкорт арасына куып китүләре – шул вакыттагы зур хәрәкәтләрнең берсе. Бунның нигезендә сәяси теләк бар иде, чөнки башкорт арасында үзләрен «солтан» дип исемләүчеләрнең уе башкорт, татар җирләрен тоташтырып, бер мөстәкыйль мәмләкәт мәйданга китерү иде. Ләкин бу хәрәкәт дини өндәүгә нигезләнгәнгә, көтелгән нәтиҗәне бирә алмаган. Әгәр дә бу хәрәкәтнең нигезендә халык көнкүреше кирәкләре салынган булса, Русиянең ул чагындагы хәрби һәм сәяси яктан зәгыйфьлеген игътибарга алганда, бу хәрәкәт муаффәкыять белән бетәргә тиеш иде.

---

Казанда соңгы революциягә кадәр татарлар үзләрендәге оешып тору сыйфатын бары «мөселманлык» астында гына саклый алганнар. «Мөселманлык» дини исем булудан бигрәк тә, сәяси төс ала башлаган. Шуның өчен дә дүрт йөз ел буенча Казан тирәсендәге

[1] Муаффәкыять – уңыш.

[2] Күңелле – доброволецлар отряды.

[3] Иван Иванович Михельсон (1740–1807) – Россия империясе хәрби эшлеклесе. Пугачёв восстаниесен бастыручы, җиңүче.

татарларның Казан вилаятендә идарә ягыннан аерымлык бирә торган бер әйберләре булса, ул да – XVIII йөздә булып узган Казанда мөселманнарга гына махсус дини һәм идарәи мөәссәсәләрдер[1]. Андый мөәссәсәләрдән ошбу төрле мәхкәмәләр булган:

Беренче, мөселман ятимнәрнең малларын саклау һәм мирас малын бүлеп бирү мәхкәмәсе[2]. Буның башында бары татарлар гына торган.

Икенче, янә татарлар «иң тәртипле рәвештә салым, имана җыеп һәм аны урынына тапшыра торган мәхкәмә.

Өченче, татарлар арасында булган хөкем һәм башка төрле хосусый татар эшләрен карый торган Ратуша[3] исемендәге мәхкәмә булган. Болар тышкы яктан, ягъни татарларның идарә итүләре ягыннан мохтариатлы мәхкәмәләрдән исәпләнгәннәр, чөнки бу мәхкәмәләрнең рәисләре татарлардан гына куелган. Карый торган эшләре дә татар эшләре генә.

Татарларга паспорт бирү дә шул Ратуша мәхкәмәсе аркылы булган.

Бу мәхкәмәләрнең һәркаюсында сайланган әгъзалар һәм рәисеннән гыйбарәт бер һәйәт[4] булган. Һәм өч мәхкәмәне берләштереп, шуның башында торган рәисе «голова»[5] исемендә йөртелгән.

Халык арасында күбрәк эш күргәне һәм атаклысы «Ратуша» исемендәгесе булган.

Бу мәхкәмәләр, әлбәттә, татарлар арасында дин берлегенең көчлелегеннән мәйданга килгән. Татарлар арасында кайбер кузгалышлар һәм Кырым сугышы вакытында татарларның Төркиягә күчү һәвәсе[6] кутәртелүдән булырга кирәк. Кырым сугышы (Севастополь, 1853–1855) вакытында бу мәхкәмәләр бетерелгән.

---

Икенче Екатерина[7] падишалыгы дәверендә Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының дини эшләрен башкара торган 1778 елда

[1] Мөәссәсәләрдер – оешмалардыр.
[2] Мәхкәмәсе – хөкем йорты.
[3] Ратуша – Казанда һәм өяз шәһәрләрендә 1728 елдан гамәлдә, сәүдәгәр һәм мещаннарның гражданлык һәм җинаять эшләрен тикшергән.
[4] Һәйәт – комиссия.
[5] Глава мәгънәсендә.
[6] Һәвәсе – теләге.
[7] Екатерина II Алексеевна (1729–1796) – Россия императрицасы.

Мәхкәмәи шәргыя[1] «Духовное собрание» исемендәге бер дини мөәссәсә мәйданга килә. Бу дини мөәссәсә 1774 елда Төркия белән Русия арасында булган Күчүк Кайнарҗа солыхы[2] буенча төзелергә тиеш булган.

Мәхкәмәи шәргыянең турыдан-туры эше никах, талак, мирас бүлү, дини мәдрәсәләр карау, имамнар билгеләү, сайланган имамнарны тасдыйк итү[3], дини китапларның дөрест басылуларын карау кебек саф дини хезмәтләр иде. Шуның өстенә соңга таба мәмләкәтнең Эчке эшләре идарәсендә булырга тиеш булган татарлардан туганнарның, үлгәннәрнең дөрест саннарын алу, аларны метрика дәфтәренә теркәү кебек эшләрне идарә итеп килде. Мәхкәмәи шәргыянең башта өч елдан өч елга муллалар Казанга җыелып, өч казый сайлап җибәрәләр иде. Янә шул казыйлар өстендә рус хөкүмәте тарафыннан чиксез вакытка мөфти исемендә бер рәис сайланадыр иде.

Мәхкәмәи шәргыя башта Оренбург шәһәрендә ачылып җибәрелгәнгә хөкүмәт кашында «Оренбургское духовное собрание» дип йөртеләдер иде.

Ләкин өч нәүбәт, ягъни тугыз еллар узгач, хөкүмәт ни өчендер Мәхкәмәи шәргыяне шөһрәтсез, Казаннан бик ерак торган Уфа шәһәренә күчерде.

Мәхкәмәи шәргыянең Уфа шәһәренә күчүе шул вакыттагы Казан мөселманнары арасында шактый шау-шу күтәреп, кечкенә генә булса да иҗтимагый хәрәкәткә сәбәп булган. Уфа шәһәрендәге Мәхкәмәи шәргыя мөселманнарның дини мәхкәмәсе булып хисапланса, рус хөкүмәте каршында Эчке эшләр нәзарәтенең[4] бер департаменты бүлекләреннән берсе булып дәвам итте.

Мәхкәмәи шәргыянең озак ел гомерендә татарларның иҗтимагый хәрәкәтләрендә күзгә бәрелгән бер эш тә күрсәтә алмады. Бәлки Казанда, Уфа вилаятендә әледән-әле татарларың кайбер хөкүмәт тәдбирләренә ачыктан-ачык протест ясаганда, хөкүмәтнең

[1] Мәхкәмәи шәргыя – Эчке Русия һәм Себер мөселманнарның дини эшләрен караучы идарә.

[2] 1774 елның 10 июлендә Россия империясе белән Төркия арасында солых төзелә, шуның белән Рус-төрек сугышына нокта куела.

[3] Тасдыйк итү – раслау.

[4] Нәзарәтенең – идарәсенең.

дини өндәүчесе урынын тотты. 1897 елдагы перепись[1] вакытындагы мөселман чуалышларында авыл халкына аерата җәза бирү дә шактый ярдәмдә булды.

**Казан каласы**

Казан –Татар Социал Советлар Җөмһүриятенең башкаласы. Хәзердә ике йөз мең чамасы халкы бар. Төп татар шәһәре булса да, хәзер Казандагы бар татар бөтен каланың дүрттән бер кадәресе генә. Казан – Советлар Русиясенең атаклы шәһәрләреннән. Казан – үзенең сәүдәсе, Шәрык һөнәре белән бик күптәннән бирле Шәрыкта гарәп, Иран һәм төрекләр арасында танылган төсле, Аурупадагы мәмләкәтләрдә дә билгеле шәһәрдер. Шәрыкта, Русиянең кай җиреннән булса да Себер татары барып чыкса, аны: «казанлы» дип кенә йөртәләр.

Казан шәһәре Идел һәм Урал буе шәһәрләренең искедән бирле баш шәһәре булып йөртелә. Казан шәһәре Идел елгасының сулъяк ярыннан шимальгә таба алты чакрым чамасында урында Казан елгасының сулъяк яры өстендә төзелгән. Хәзер Казанның бер яртысы сырт урында булып, яртысы шул сыртның итәгендәдер. Казаннан өзелгән булса да, Казан каласы идарәсендә булган Казанның берничә бистәсе бар. Яңа Бистә (татарлар гына), Пороховой (татарлар күп), Ягодный (күбрәк урыслы эшче бистәләре). Шәһәрнең уртасында Кабан исемендә зур күл бар. Бу күл бөтен шәһәрне икегә бүлә торган Болак елгасы белән Казан (Казанка) суына тоташадыр. Яз көнендә Кабан күле белән Болак елгасы бер ай чамасында язгы су белән тулып торалар. Шул су аркасында яз көнендә Казанның кышлыгы, еллыгы өчен утын, бүрәнә, гомумән бөтен агач әйбере килеп кала. Яз көнендә Казан диңгез уртасында калган атау[2] рәвешен алып, бөтен тирәсе язгы ташу суы белән чолганган була.

---

Казан үзенең төзелеше ягыннан Болак елгасы белән ике якка аерыла. Болакның уң ягын рус, сул ягын татар ягы дип йөртәләр.

[1] Сүз Россия империясендә 1897 елда беренче һәм соңгы мәртәбә барлык халык санын алу вакыйгасы хакында бара. Исәп алу 1897 елның 9 февралендә (28 гыйнварында) күренекле рус галиме П. П. Семёнов-Тян-Шанский башлангычы белән үткәрелә.

[2] Атау – утрау.

дорог, кроме Казанского стыка, не вполне благоприятных условий береговой линии Камы, в прошлом не мог создать других значительных экономических центров района, кроме Казани. Только проведение Казанбургской дороги создало благоприятную почву для возникновения и роста новых пунктов в районе, в особенности Арска, Кукмора и пограничного пункта Вятских Полян. Сравнение данных по переписи [19]20 и [19]23 г.г. показывает, что за два с половиной года, между двумя переписями, население г. Арска почти удвоилось, тогда как население г. Лаишева осталось почти без изменения, а население – г. Мамадыша уменьшилось за то же время на 10%. Рост значения поселка Кукмор и экономическое тяготение к нему значительной части кантона создало среди работников Мамадышского кантона течение за перенесение кантонного центра из Мамадыша в село Кукмор. Но такое перенесение встречает препятствие ещё в незначительности тяготения к Кукмору юго-восточных волостей кантона, тяготеющих к Мамадышу и, главное, в необходимости затрачивать значительные средства на ряд лет для того, чтобы вполне приспособить с. Кукмор к условиям кантонного центра. В общем перевод центра Мамадышского кантона в Кукмор имеет под собой значительные основания, такой перевод даст возможность прикрепления к этому кантону части смежных волостей и Арского кантона, экономически тяготеющих к Кукмору с его текстильной промышленностью. Такой перевод, как кажется, является делом только времени и финансовых возможностей. С другой стороны, работниками Лаишевского кантона возбуждается вопрос о перенесении центра в камскую пристань – Рыбную Слободу; здесь, с одной стороны, играет роль экономическое тяготение ближайших к Рыбной Слободе Рыбно-Слободской, Кугарчинской и Ново-Арышской волостей, и с другой стороны, и главным образом – соображение административного характера, т.к. Рыбная Слобода более центрально расположена для большинства волостей кантона. Но такое перенесение встречает препятствие в том же вопросе о средствах, каковых в этом случае потребуется еще больше, а также в экономическом тяготении Сараловской, Нармонской и Чирповской волостей.

Арский кантон является одним из крупнейших по величине кантонов; по количеству населения, достигающему до 400 000 жите-

лей, этот кантон занимает первое место в ТР, а по территории третье место после Чистопольского и Бугульминского. Такая величина кантона оправдывается расположением кантонного города в географическом центре кантона и диагональным прохождением через весь кантон Казань-Свердловской жел. дороги, на которой расположен и гор[од] Арск.

Общими отличительными моментами отдельных кантонов Прикамья является сравнительно большая плотность населения и распаханность, а также меньшая обеспеченность землей и скотом населения Арского кантона; большая лесистость Мамадышского кантона и большая обеспеченность лугами Лаишевского кантона. Некоторые отличия имеются в распределении культур ярового клина, в распределении кустарных промыслов и в общих экономических показателях экономики крестьянства отдельных кантонов. Объединить все эти три кантона в один укрупненный кантон с центром в Казани невозможно, ввиду получающейся несоразмерности кантонов, отсутствия непосредственного экономического тяготения значительной части территории, получающихся дальних расстояний и административных неудобств – создание из этих трёх кантонов двух, с центрами в Казани и Кукморе – встречает препятствие в получающих при этом всё же дальних расстояниях в 100 и более вёрс, в необходимости строительства нового кантонного города в Кукморе – значительных затрат на переброску – в значительной разности мощности населения и бюджетов обоих кантонов, так как экономически наиболее мощное волости будут концентрированы в Казанском и наиболее бедные в Кукморском кантоне, а также в политических неудобствах создания крупного, наиболее мощного кантона в самом центре национальной республики, с национальным составом населения, на рубеже 70–80% не совпадающим с основной национальностью данной автономной республики. Все приведенные соображения финансового, экономического и административно-политического характера заставляют сохранить и эти три кантона – Арский, Мамадышский и Лаишевский самостоятельными кантонами.

Итак, по всей ТР из 12 кантонов более или менее безболезненно можно ликвидировать только один Тетюшеский кантон, присоединив его к Буинскому.

Мысль о сокращении кантонов только в целях экономии средств на содержание кантонного аппарата также не оправдывается, так как это не даст все равно экономии на содержание ведомственной сети содержание же одних кантонных аппаратов не представляет столь крупную величину в общем составе бюджетов ТР, тем более при укрупнении кантонов придется увеличить штат остающихся кантонов, расходы на связь и командировки, на переброску и новое строительство, не говоря уже о расходах населения на поездки в дальние центры, с отсутствием экономического тяготения, – эти расходы лягут на население новым налогом, кроме того, создадут неудобства с точки зрения общего советского строительства, в связи с удалением руководящих административно-политических центров от населения.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 191 сакл. бер.*

*Мәкалә «Труд и хозяйство» журналының*[1]
*1928 елгы 4 санында «Г. Шараф» имзасы белән басылган.*

[1] «Социалистическое хозяйство Татарстана» («Татарстанның социалистик хуҗалыгы») – айлык иҗтимагый-икътисади журнал. ТАССР ХХС һәм профсоюзларның Татарстан өлкә Советы, ТАССР Дәүләт план комитеты органы. 1921 елның гыйнварыннан 1930 елның июленә кадәр «Труд и хозяйство», 1930 елның августыннан «Социалистическое хозяйство Татарстана», 1935 елдан «Социалистический Татарстан» исеме белән Казанда нәшер ителә.

# III бүлек

# ГАЛИМҖАН ШӘРӘФНЕҢ ИҖАТ МИРАСЫННАН

## КӨЗГЕ ҖИЛЛӘР

Төн буе, көн буе җил исә,
Бертуктаусыз исә көзге җил.
Йорт-җирсез тол-ятимдәй итә,
Җаннарны әрнетә көзге җил.
Күк йөзен зур болыт каплаган,
Сап-сары иттергән көзге җил.
Юпь-юеш, дым аңкый һәркайдан,
Дым ташый диңгездән көзге җил.
Кайвакыт бер өмид тә биреп,
Туктавын көттерә көзге җил.
Тагы тиз, һәр ярыктан кереп,
Ыжгыра, өрдерә көзге җил.
Яп, җаным, шул ачык тәрзәне,
Кермәсенче өйгә көзге җил.

*1939*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 140 сакл. бер.*

## ТУГАН ИЛДӘ

*(Халисә белән Фатыймага сагынмалык)*

Бүген төштә булдым туган илдә,
Сеңелләрем белән җыйдым чәчәкләр.
Килде сабый вакытларым искә,
Тулды күңел, рәхәт типкәй йөрәкләр.
Авыл буйлап салам япкан өйләр,
Буй-буй тигез урамнары тезелгән.
Чәчәк аткан көнбагышлар, мәкләр,
Һәрбер йортның түтәлләре бизәлгән.

Иркен кырда арыш, солы үскән,
Су буенда яшәрәләр болыннар.
Зиярәттә җәйге акрын җилдән
Яфракларын җилфердәтә каеннар.
Тегермәннәр бизи авыл башын,
Канатларын әйләндерә искән җил.
Искитәрлек ямьле дә булмасын,
Бик тә якын, бик сөйкемле туган ил.

*1939*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге, 20 ф., 1 тасв., 140 сакл. бер.*

## ТӨНГЕ БУРАНДА[1]

Кышкы төн. Салкын һавада
Кар бураны агыла.
Зур авылның урамыннан
Ике җәяүле бара;
Сөйләшәләр үзара:
«Кара, кара нинди буран!
Бу ни булган дөньяга?! –
Айлы төндә кар ява!
Җем-җем итеп ай нурыннан,
Нигә карлар елмая?! –
Җенме күзен уйната?!
«Нинди шаулый, ыжгыра җил, –
Кураең чыжлый, мынай,
Сорнаең суза мынай!
Нәрсәне шакылдата җил? –

[1] Войдет в детский сборник «Кыш бабай» под № 5а, после стих. «Буранда». *(Г. Шәрәф иск.)*

Барабан кага мынай!
«Әллә җеннәр кузгалдымы?
Нәрсә анда әйләнә?
Кем биеп рәхәтләнә?
Убырлы карчык мынай.
Шүрәлеме өйләнә?
Бар авылны каплаган кар,
Һәркая көртләр өйгән,
Һич күренми юл фәлән,
Һичбер өйдә янмый утлар,
Өрмиләр нидән этләр?!
Дулый җилләр, дулаталар
Ярлының җил капкасын,
Тәрәзә капкачларын.
Кара, ничек туздыралар
Түбәнең саламнарын.
Тукта, тукта, китмә алга,
Һич тә куркышмыйк әле.
Тып-тыныч булыйк әле.
Җен туемы әллә чыкты?
Бергәрәк барыйк әле.

*09.01.43*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 145 сакл. бер.*

**ШҮРӘЛЕ**
*(Баллада)*

*Тукайның үлүенә 30 ел тулганда*

Яратам таңнарда ялгызым гизәргә,
Иртәнге саф суда чумарга, йөзәргә.
Таң җиле хуш аңкып уяткач урманны,
Чык иңгән аланнан чәчәкләр өзәргә.
Яратам тургайның таңдагы сайравын,
Каенның уйланып җирфердәү-шаулавын.
Яратам кош-кортның, уятып бер-берен,
Иртәнге төшләрен узышып сөйләвен.

Хәзер кыш, агарган бар кырлар, болыннар,
Ак мамык карларга төренгән урманнар.
Һәр ботак-чыбыкка ука-чук асылган,
Һәркая ак ука чачаклар[1] сузылган.
Һәр агач, һәр куак – гүя зур ак чәчәк,
Бар урман – әйткесез, бер гигант гөлчәчәк.
Әкияттә хан кызын йоклаткандай урлап,
Сихерче кыш-суык, ыжгырып, тылсымлап.
Карларын сиптереп, мамыгын очыртып,
Бизәгән яшь сылу урманны йоклатып.

Ни өчендер, бүген бик иртә уяндым.
Өст-башка, аякка киендем, кушандым.
Җәй таңын хәтерләп, юнәлдем кырларга,
Әлеге тылсымлы бизәлгән урманга.
Мин барам тын кырдан, зәңгәрчел карлардан,
Ай алтын урагы елмая һавадан.
Көнтугыш офыктан таң нуры сузыла,

[1] Чачаклар – бизәү өчен тукыма читләренә тегелә торган җеп бөртекләрен янәшә тегеп беркеткән тасма.

Күкләрдән, җемелдәп, йолдызлар җуела.
Таң үсә, җәелә, аллана дөньялар,
Ал-зәңгәр миләүшәдәй карлы далалар.
Ул урман! Ул урман! Гаҗәеп матурлык!
Бертоташ ал чәчәк – акылдан шашарлык.
Йоклаган хан кызым яртылаш уянган,
Җан иңеп, гүя ки яңагы алланган.

Урманның юлыннан мин барам кыр ярып,
Бу тылсым, бу ямьгә исереп, шаккатып.
Чү, тукта! Кем анда чырылдый, чыелдый?
Карт имән астында кем көлә, хайхылдый?
Карасам, алдымда – мөгезле Шүрәле,
Картайган, агарган чәчләре, төкләре.
Никтер ул бизәнгән, ал чәчәк – мөгезендә,
Ал чәчәк – түшендә, сөякчел иңендә.
Зур кәкре тырнаклы бармагын тибрәтеп,
Чакыра ул мине үзенең янына.
Мин торам да бераз каранып, шикләнеп,
Юнәләм туп-туры карт имән астына.
– «Бер дә шикләнмә, – ди, – шагыйрем, син миннән,
Һич тимәм мин сиңа, тидермәм беркемнән.
Шүрәле илендә бүген бик зур бәйрәм,
Истәлек кичәсе, зур шанлык һәм матәм.
Нәкъ утыз ел бүген шагыйрем үлгәнгә,
Даһины – Габдулла Тукайны күмгәнгә.
Һич онытмый аны Шүрәле ил халкы,
Олылап яд итә[1] бар яше һәм карты».
– «Нидән соң аңарга, – дим, – болай зур хөрмәт?
Ул көлгән ич сездән, исеңдәдер әкият?»
– «Тыңла, – ди Шүрәле, – зарланыймчы сиңа:

[1] Яд итә – искә ала.

Хәзер яшь җилкенчәк һич ышанмый миңа.
Бары тик ышану яшәтә бит безне –
Өрәкне, убырны, җеннәрне, пәрине.
Шул ышанмау инде үчерә[1] илемне,
Юк итә дөньядан ыруым-нәслемне.
Ә Тукай «Шүрәле» дип, поэма язып,
«Шүрәле» дип, шигырен имзалап, кул куеп.
Таратты данымны никадәр илләргә,
Калдырды яңратып исмемне мәңгегә!»
Шулвакыт тирәмне ал томан урады,
Шүрәле хайдылдап күземнән җуялды.

Уянсам, утырам урманда, бүкәндә,
Нәкъ шунда, юнәлеп теге карт имәнгә.
Белмимен, мин күрдемме аны төшемдә,
Әллә чын Шүрәле очрадымы өндә.
Йоклаганмын байтак, көн тәмам яктырган,
Яз башы кояшы шат балкый һавадан.
Ялтырый нурларда тылсымлы урманым,
Алмаслар бизәгән бар кырын-куагын.

*Котлас, март, 1943*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 146 сакл. бер.*

[1] Үчерә – бетерә, юк итә.

**НИНДИ БӨРКҮ!**

*(Некрасовтан)*[1]

Нинди бөркү!– Буылабыз...
Төн, беткесез төн, томан.
Кайчан гына котылабыз?!
Мондый тормыш – бер зиндан.
Әй, давыллар дуласачы!–
Ил касәсе тулышкан...
Әй, яшеннәр уйнасачы,
Юл күрсәтеп офыктан!
Айка, давыл, илләрне син,
Актар диңгез төпләрен!
Түнтәр тулы касәне син,
Тарат илнең хәсрәтен.

*09.02.43*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,
20 ф., 1 тасв., 145 сакл. бер.*

[1] Иң күренекле революцион шигырьләреннән булган бу шигырен шагыйрь Некрасов XIX йөзнең 60 нчы елларында крестьян реформасыннан соң язган. Крестьян реформасының киң халык массасын канәгатьләндермәвен, «ил касәсе тулышкан» булуын күрсәтә торган көчле шигырь. Оригиналның шигырь үлчәве сакланып тәрҗемә ителгән. (*Г. Шәрәф иск.*)

## ТӨНГЕ АВЫЛ

*(сюжеты И.С. Никитиннан)*

Тын гына аяз төн
Идел өстендә.
Чытланып карый ай
Су көзгесенә.
Җемелдәп яналар
Якты йолдызлар,
Гүя күз кысалар
Тәрзәдән кызлар.
Ярда сузылган да
Зур куе урман,
Калгуга[1] талгандай,
Тынлыкка чумган.
Камыштан балкыйлар
Көмешле күлләр.
Үрдә хуш аңкыйлар
Саргылт игеннән.
Зур авыл баладай
Йоклый далада,
Елмая ападай
Күк йөзе аңа.

*Август, 1942–22.IX-44*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 142 сакл. бер.*

[1] Калгуга – йокымсырауга.

# АРЫСЛАН БӘК

*(«Китабе Коркыт»тан[1] беркадәр үзгәртелеп татарчалаштырылган)*

Көннәрдән бер көнне ханнар ханы Айбирде хан, елдагы гадәтенчә, зур туй ясап, тирә-яктагы барлык угыз бәкләрен сыйларга теләгәнен вәзирләренә, хезмәтчеләренә белдерде. Иң симез куйларны, сыерларны суеп, иң тәмле, куе сөтле бияләрдән кымыз хәзерләргә боерды:

– Кунак мәйданының бер ягына ак, икенче ягына кызыл, өченче ягына кара чатыр корыгыз. Углы булганнарны ак чатырга утыртыгыз, кызы булганнарны кызыл чатырга утыртыгыз, углы да, кызы да булмаганнарны кара чатырга утыртыгыз, астына кара киез җәегез, алдына кара куйның итен китерегез, ашаса ашасын, ашамаса – торсын да китсен! Угылсыз-кызсыз кешене Тәңре каргаган, без дә аны каргыйбыз! Белгән булсын, – диде.

Угыз бәкләре җыела башладылар. Угыз бәкләре арасында Ышаныч хан дигән бер хан бар иде. Бу ханның углы да, кызы да юк иде.

Салкынча таң җилләре җилбер-җилбер искәндә, болытлардан да өсткәрәк чыгарга өлгергән сабан тургае моңаеп-моңаеп сайраганда, җитез умарта корты безелдәп-безелдәп бал җыярга барганда, кичтән яшел үләндә утлап йөреп туйган атлар, иртә торып чыккан ияләрен күреп, шыңратып-шыңратып кешнәгәндә, иртәнге салкында угыз яшь бәкләре, батыр егетләре көрәшеп, ук атышып уйнаганда, угыз кызлары-киленнәре иртә торып уянып бизәнгәндә, кара актан аерылып, матур күкрәкле текә таулар артыннан ялтырап кояш чыкканда – Ышаныч хан да йокысыннан уянып, урыныннан калыкты. Кырык егетен бергә алып, Айбирде ханга туйга китте.

Айбирде ханның егетләре Ышаныч ханны каршы чыгып алдылар, астына кара киез җәеп, кара чатырга утырттылар; кара куйның итен китереп: «Айбирде ханның боерыгы шулай, ханым», – диделәр.

Ышаныч хан әйтте: «Айбирде хан минем ни кимчелегемне тапты: кылычыммы көчсез, табыныммы кечкенә? Миннән түбән кешеләрне ак чатырга, кызыл чатырга утыртып та, нинди гаебем өчен мине кара чатырга утыртты?» – диде.

[1] «Китаби дәдә Коркыт» – угыз төрки халыкларының иң танылган эпик әсәрләреннән берсе.

Егетләр: «Ханым! Бүген Айбирде ханнан: угыллыны ак чатырга, кызлыны кызыл чатырга; угылсыз-кызсызны кара чатырга утыртыгыз: угылсыз-кызсыз кешене Тәңре каргаган, без дә аны каргыйбыз, дип боерык булды», – диделәр. Ышаныч хан, кырык егете белән урыныннан калыкты: «Бу гаеп, бу йөз каралыгы миннәнме, бикәмнәнме?», – дип ардусына кайтып китте.

Ышаныч хан өенә кайтты да, бикәсен чакырды.

Тыңлап карыйк Ышаныч ханбикәсенә ниләр сөйләде икән:

«Кил әле монда, башымның бәхете, өемнең тәхете; тез камыштай сылу буйлым, тубыгына җиткән кара сачлым; корган уктай чатма кашлым, куш чикләвек сыя алмаслык кечкенә авызлым; көзге алмадай ал яңаклым! Татлы кавыным, багалмам! Беләсеңме ни булды: ханнар ханы Айбирде хан кунак чакырып, туй ясаган; бер җиргә ак чатыр, икенче җиргә кызыл чатыр, өченче җиргә кара чатыр корырга боерган; угыллыны ак чатырга, кызлыны кызыл чатырга, углы-кызы булмаганны кара чатырга утыртыгыз, кара киезне астына җәегез, кара куй итеннән ашарга китерегез. Ашаса ашар, ашамаса – торыр да китәр. Углы, кызы булмаганны Тәңре каргаган, бездә аны каргыйбыз, белгән белсен, дигән. Кырык егетемне алып Айбирде ханның туена бардым; Айбирде ханның егетләре каршы чыгып алдылар, кара чатырга илттеләр, астыма кара киез җәйделәр, кара куйның итен алдыма китерделәр: углы, кызы булмаганны Тәңре каргаган, без дә аны каргыйбыз, белгән белсен, диделәр. Тәңре безгә бүгенгәчә бер углы бирмәве синнәнме, миннәнме? И, хан кызы! Утырган алтын урындыгымнан торыйммы, битеңнән, муеныңнан тотыйммы, көчле укчым астына салыйммы, кара корыч кылычымны кулыма алыйммы? Кара чәчкә уралган ал йөзеңне ак муеныңнан аерыйммы, җан ачысын таттырыйммы, ал каныңны җир йөзенә түгимме? Хан кызы сәбәбен сөйлә, багыйм!», – диде.

Ханбикә сүзгә кереште.

Карап карыйк, ханбикә ни сөйләде икән?

«Күз ачкач та күргәнем, күңел биреп сөйгәнем, Ышаныч хан! Ачу белән ачы сүзләр сөйләмә, кызулык белән кызу сүзләр сөйләмә. Кара кайгы төшкән чакта каты-каты сүзләр әйтеп, мине юкка каргама. Калык, бизәкле чатырыңны кор. Иң симез куйларны, сыерларны, атларны, дөяләрне корбанга чал. Эч – угыз, тыш – угыз бәкләрен барысын җыеп, туйга чакыр. Ач килсә – туйдыр, ялангач

килсә – киендер, бурычлыны күрсәң – бурычын түләп, йолып ал. Таудай өеп, ит хәзерлә, күлдәй итеп, кымыз хәзерлә. Зур туй ясап, теләгеңне кунаклардан теләт. Арадагы бер яхшының теләге белән, бәлки безгә Тәңре бер угыл бирер», – диде.

Ышаныч хан зур туй ясады. Теләген әйтеп, атлар-тайлар, дөяләр, куйлар чалды. Эч угыз, тыш угыз бәкләрен туйга чакырды. Ачны күрсә – туйдырды, ялангачны күрсә – киендерде. Алдына бурычлы килсә, бурычын түләп, йолып алды. Таудай өеп, итен хәзерләде, күлдәй итеп, кымыз саудырды.

Кунаклар башларын иеп, күк Тәңресенә кулларын үнәлдереп, теләк теләделәр.

Арадагы бер яхшының теләге белән Тәңре Ышаныч ханга бер угыл бирде. Туган үсә; кабыргалы калка, балага унбиш яшь тулды да.

Ышаныч ханның җәйләве Айбирде хан җәйләве белән чиктәш иде.

Айбирде ханның бик көчле бер дөясе белән бер үгезе бар иде. Ил көтүләрендәге бер үгез дә, ил табуннарындагы бер дөя дә боларга каршы чыга алмый, болар белән көрәшә алмый иде. Ханнар ханы Айбирде хан үгезенең ханнар ханы Айбирде хан дөясенең көчлелектәге атагы тирә-як илләргә дә таралган иде, язын бер тапкыр, көзен бер тапкыр үгезне төя белән даладагы Ак мәйданда көрәштерәләр. Айбирде хан угыз бәкләре белән бу күренешкә карап күңел ача иде. Бу язны да өч кеше уң яктан, өч кеше сул яктан, тимер чылбырлар белән тотып, үгезне яткан җиреннән чыгарганнар, Ак мәйданның уртасына китереп чылбырыннан җибәргәннәр иде.

Нәкъ шул чакта Ышаныч ханның углы үзенең өч иптәше белән Ак мәйданда ашык[1] уйнап йөриләр иде. Үгезне ычкындыру белән балаларга качарга куштылар. Өч бала качты, Ышаныч ханның углы качмый мәйдан уртасында калды.

Үгез яшь егетне күрүе белән аны мөгезләренә күтәреп ыргыту өчен бәккә таба ташланды. Егет урынында калып, үгезнең маңлаена йодрыгы белән бер суккан иде – үгез кире чигенде. Үгез тагын егеткә ташланды, егет тагын йодрыгы белән үгезнең маңлаена сугып туктатты. Шул сугудан кулын кире алмый үгезне маңлаеннан тотып чигендереп, Ак мәйданның кырыена илтте. Аннан соң үгез егетне этеп китте. Мәйдан уртасына җиткәч, егет аякларын терәп

[1] Ашык – кузна.

басты да бер урында торды; егет тә үгезне җиңдермәде, үгез дә егетне урынынннан кузгата алмады. Егет: «Ава торган койманы багана белән терәтеп куялар; багана коймага терәк була, миңа ник бу үгезнең маңлае өчен терәк булып торырга», – дип уйлады да, үзе бер кырыйга сикереп китеп, кулын үгезнең башыннан алды. Кулны кинәттән алганга үгез сөрлегеп, башы белән җиргә барып кадалды. Шул арада егет биленнән хәнҗәрен алып, үгезнең җилкә тамырына китереп тә чәнчеде.

Угыз бәкләре егетнең батырлыгына гаҗәпкә калдылар. Тирәсенә җыелып, яшь егетне мактарга керештеләр: «Бар, чакырыгыз Коркыт бабай килсен, бу егеткә ат кушсын; егетне атасына алып барсын да аңардан бәклек һәм тәхет алып бирсен», – диештеләр. Коркыт бабайны чакырып китерделәр.

Коркыт бабай егетне атасы Ышаныч хан янына алып китте.

Карап карыйк, Коркыт бабай ханганиләр сөйләде икән:

«И, Ышанч хан! Бу егеткә – батыр егеткә син бәклек бир, син тәхет бир; бу җиңел сөякле егеткә атланырга озын муенлы ат бир; бу егеткә – көчле егеткә, азык итеп, көтүеңнән меңләрчә баш куй бир; бер оста, бу һөнәрле егеткә йөкләр төяргә төркем-төркем кызыл дөяләр бир; бу егеткә – зирәк егеткә, күләгә итеп, алтын түбәле чатыр бир; бу җитез егеткә киертергә ефәк белән теккән, ука белән чиккән киемнәр бир. Айбирде ханның Ак мәйданында бу егет үгез белән көрәште; батырлык, зирәклек, көчлелек, җитезлек, осталык, җиңеллек күрсәтте, ил табуннарында тиңдәшсез, чит илләрдә дә атаклы, ханнар ханы Айбирденең карап торган бер үгезен, көчле үгезне көрәшеп җиңде. Билендәге хәнҗәр белән зур үгезне арысландай парчалады. Арысландай бу егеткә «Арыслан» дип ат кушам! Ат кушуы Коркыттан, матур көнкүреше Тәңредән», – диде.

Ышаныч хан егеткә бәклек бирде, кыйммәтле тәхет белән алтын түбәле чатыр бирде; ука белән чиккән, ефәк белән теккән чикмән бирде. Озын муенлы ат белән, көтү-көтү куйлар, төркем-төркем төяләр бирде. Арыслан бәк алтын түбәле чатырда көн күрә башлады.

Ышаныч ханның кырык егете Арыслан бәктән көнләштеләр; аны атасы алдында каралтырга уйлаштылар: кырык явыз егет икегә аерылып, егермесе бер яктан, калган егермесе икенче яктан Ышаныч ханга киттеләр. Бер бүлеге Ышаныч ханның алдына барды.

Карап карыйк, явыз егетләр ни сөйләделәр икән:

«Күрәсеңме, ханым, ниләр булды? Углың Арыслан бәк алтын түбәле чатырыннан калкып, текә-биек матур күкрәкле Алатауга ауга чыкты; синең киекләреңне куды, синең кошларыңны атты, тотты. Анасы янына килеп, сиңа каршы яман киңәш корды. Углың усалга чыкты, ул исән булса, малыңа да, ханлыгыңа да тынычлык булмаячак, мондый угыл нигә? Андый углың булганнан булмаганы артыграк түгелме?»– диделәр.

Ул арада калган егерме усал егет тә хан алдына килеп, Арыслан бәкне каралаlarга керештеләр: «Беләсеңме, ханым, ниләр булды? Синең усал углың явызга чыкты. Ул үзенә кырык егет җыеп, бай угызларны басып, чабып йөри башлады. Кайда матур күрсә, ирексезләп ала. Кайда байлык күрсә, талап ала, казнасына сала. Ак сакаллы картларның йөзләренә суга; чал чәчлы карчыкларның ачы яшен агыза. Ханым! Начар хәбәр йөгерек агымлы сулар аркылы чыгып, текә биек матур күкрәкле Алатау башына күтәрелер дә ханнар ханы Айбирде ханга ирешер. Әйтерләр: Ышаныч ханның углы менә ничек илне болгата, диделәр. Ханнар ханы Айбирде ханнан орыш-шелтә алырсың. Ул чакта син үзең дә җир өстендә йөрүдән җир астында ятуны артыграк күрерсең. Көн күрүдән үлемне өстенрәк диярсең, мондый углың булганнан булмаганы яхшырак, ул сине хур иткәнче, син аны юк итсәң башың бәладән котылыр. Ул сине үлтергәнче син аны үлтерсәң, җаның табышка калыр», – диделәр.

Ышаныч хан: «Барыгыз, аны монда китерегез, мин юк итим үзен! Андый угыл миңа кирәк түгел!»– диде.

Явыз егетләр: «Без синең усал углыңны ничек китерик? Ул безнең сүзне тыңламас, безнең чакыру белән килмәс. Үзең алтын тәхеттән тор, бизәкле чатырыңнан калык. Кырык иптәш егетеңне бергә алып, Алатауга ауга чык. Юлда Арыслан бәкнең чатырына туктап, аны да яныңа ал, кош очырып, җәнлек куганда, уклар җибәреп, аны үлтер. Әгәр шулай үлтермәсәң, аны башкача үлтерү, үлтертү мөмкин түгел, белгән белә!» – диделәр.

Салкынча таң җилләре җилбер-җилбер искәндә, болытлардан да өсткәрәк чыгарга өлгергән сабан тургае моңаеп-моңаеп сайраганда, җитез умарта корты безелдәп-безелдәп бал җыярга барганда, кичтән яшел үләндә утлап йөреп торган атлар иртә торып чыккан ияләрен күреп, шыңгыратып-шыңгыратып кешнәгәндә, иртәнге салкында угыз яшь бәкләре, батыр егетләре көрәшеп, ук атышып

уйнаганда, угыз кызлары-киленнәре иртә торып, уянып бизәнгәндә, кара актан аерылып, текә биек таулар артыннан ялтырап кояш чыкканда, Ышаныч хан да йокысыннан уянып, урыныннан калыкты, углын алып, кырык егет ияртеп, Алатауга ауга китте. Киң далага, чокырлы тауларга, караңгы урманнарга таралып, җәнлек куарга, кошлар тотарга керештеләр.

Кырык явыз егетләрнең кайберләре Арыслан бәккә килеп: «Әтиең Ышаныч хан: углым киекләрне минем алдыма куып китерсен дә минем алдымда аларны ауласын; мин углымның ат өстендә йөрешен, ук атышын, кылыч чалышын күрәсем килә, күреп куанасым, углым белән мактанасым килә, дип әйтә», – диделәр.

Ару, яшь егет усалларның усал уен кайдан белсен?

Арыслан бәк, киекләрне куды, китерде: «Әти ат сикертешемә баксын, сөенсен, ук атышыма баксын, шатлансын; кылыч чалышыма баксын, куансын, углы белән мактансын» дип, атасы алдында киек ауларга кереште.

Теге кырык явыз егет әйттеләр: «Ханым! Күрәсеңме углың ничек киң төз даладан киекләрне сиңа таба куып китерә. Ул киеккә аткан булып, сиңа атмакчы була, ул киекне еккан булып, сине екмакчы була. Ул киекне үлтергән булып, сине үлтермәкче була. Сак бул, ханым. Ул сине үлтергәнче, син аны үлтереп кал!» – диделәр.

Арыслан бәк киек куып, киек атып, кош тотып атасы яныннан үтеп-үтеп китә; төз далаларда тау итәкләрендә ат сикертеп, ук атып, кылыч чалып юана иде. Ышаныч хан кырык явызның коткысы белән, ак өрәңгедән бөккән куркыныч чәбәле зур угын ак кулына алды да, аякларын корыч өзәңгегә терәп, җәясен киереп, ук җибәрде. Ук Арыслан бәкнең ике калак сөяге арасына тугры килеп, күкрәген үтәли тишеп чыкты. Күкрәгеннән ал кан тондырып ага башлаган яшь егет, төбенә чалгы тигән яшь камыш күк, Акбүз аттан яшел үләнгә егылып төште. Кырык явыз егет Ышаныч ханның тезгененнән тотып, атын тиз генә әйләндереп, ардусына алып кайтып киттеләр.

Ышаныч ханның бикәсе, углының беренче авыннан кайткан җиренә дип, иң яхшы сугым атларны – иң симез куйларны чалырга кушты. Батыр угыз бәкләрен сыйламакчы булды. Аудан кайтыр чак җиткәч, үзенең кырык булышчы кызы белән бергә аучыларны каршы алырга чыкты.

Аучылар кайттылар. Ханбикә ары бакты, бире бакты, углыкаен күрмәде. Йөрәге сикереп, күкрәге кысылып, бәгъренә ут кабынган күк булып китте. Кара күзләренә канлы яшь тулды.

Ханбикә Ышаныч ханга карап сүзгә кереште. Тыңлап карыйк, ханбикә ни сөйләде икән:

«Кил әле яныма, башының бәхете, өемнең тәхете, атамның кияве, анамның иркәсе, күз ачкач та күргәнем, күңел биреп сөйгәнем, Ышаныч хан! Син алтын тәхетеңнән калкып, кара яллы атыңа атланып, кызыл күкрәкле текә тауга ауга чыктың. Сез икәү киткән идегез, син ялгыз кайттың, балам кайда? Кара дөньямны якты иткән углым кайда? Күрер күзләрем, кан басып, күрмәс булалар; сөт тамырларым бала имезгән күк сулый башладылар; ак тәннәрем елан чаккан күк шешә башлады, бердәнбер углым күренми, бәгырьләрем ут яна! Коры-коры чокырларны агым сулар белән тутырдым, адәм кичмәс, хайван үтмәс елгаларга күпер салдым. Ачны күрсәм – туйдырдым, ялангачны күрсәм – кием бирдем. Теләүгә корбан чалып, тау чаклы ит җидердем, күл чаклы кымыз саудырдым. Яхшыларның теләге белән бер углы таптым! Бердәнбер углымның хәбәрен сөйлә. Йөгерек агым тынык судан углымны агызган булсаң, сөйлә. Юлбарыска, арысланга углымны ашаткан булсаң, сөйлә. Кара тунлы, явыз эчле ил дошманына углымны алдырган булсаң, сөйлә, мин этием ханга китәм, бай казна, көчле гаскәр алыйм, ил дошманнарының өстенә барыйм. Ак ефәк җиңем яраларымнан аккан кызыл канны сөрткәнче атышыйм; яраланып аягым-кулым көчсез булганчы, Акбүз аттан егылып, яшел үләнгә төшкәнче сугышыйм. Илләр, далаларны үтеп, йөгерек агым суларны кичеп, бердәнбер углымны эзлим. Ышаныч хан! Кара башым алдыңда корбан булсын. Бердәнбер углымның хәлен сөйлә!» – диде, зарилык итте, елады.

Ышаныч хан бер сүз әйтә алмыйча тик торды.

Кырык явыз егет алга чыгып: «Ханбикә, күңелсезләнмә. Углың исән-сау. Ул ауда калды. Кайда гына булса да, бүген үк йә иртәгедән калмый кайтыр. Кайгырма, борчылма! Хан кымызны күбрәк эчеп башы әйләнгән, шуңа күрә җавап бирә алмый тора», – диделәр.

Ханбикәнең күңеле өйдә көтеп утыруны күтәрә алмады. Үзе белән кырык булышчы кызын алып, сөйгән атына атланып, далаларга, тауларга угылкаен эзләргә китте. Алар, җәен-кышын, кары-бозы кипми торган Казылык тавына килделәр. Тау өстләренә менделәр.

Биектән биек тау түбәләренә күтәрелделәр. Ханбикә тирәле карап, күзе белән эзләнергә кереште. Караса, күрә: бер үзәннең эчендә карга-козгын күп-күп булып очалар. Үзән эченә бер очып төшәләр дә тагын күтәреләләр. Ханбикә атын үкчәләп, шул якка юнәлде.

Ул арада атыннан егылып төшкән Арыслан бәк җирдә ята; карга-козгыннар, кан исен сизенеп, аның янына җыелганнар. Ярасын чукымакчы булалар; яралы егет кулындагы кылычы белән аларны ярасына ултыртмый куып тора иде.

Анасы якынлашканда, Арыслан бәкнең хәле киткән, кылыч күтәрергә көче бетеп, ярасын чукырга, канын эчәргә килгән ерткыч кошларны да куа алмас булган, күзләре йомылган иде. Алай да күзенә тау иясе күренеп: «Курыкма егет, син бу яраңнан үлмәссең, анаң сөтенә манчылган тау чәчәге синең яраңа шифа булыр», – дип хәбәр биреп куйганга, егет җаны тәнендә калудан өмид өзмәгән иде.

Ханбикә килеп, углының ал кан эчендә ятканын күрде; кызганып, моңланып сүзгә кереште: «Карлыган күк кара күзләреңне йокы алган; күзләреңне ач, бәгърем! Унике тамырың типмәс булган; көчләреңне җый бәгърем! Тәңре биргән татлы җаның тәнеңнән чыкмак була; телләреңдә җан булса сөйлә, бәгърем!

И, Казылык тавы! Агар суларың акмас булсын; үсәр үләннәрең үсмәс булсын; йөгерер киекләрең йөгермәс булсын, ташка әйләнсен!

Арысланмы сине яралады, юлбарысмы сине парчалады, ничек белим, балакаем? Керпегеңдә җан булса, күзеңне ач, балакаем! Телләреңдә көч булса, сөйлә миңа балакаем!» – диде.

Әнисенең елап-сыктап сөйләгән сүзләре егетне исенә китерде. Ул ак йөзен күтәреп, карлыган күк кара күзләрен ачты. Әнисенә карап сөйли башлады:

«Ак күкрәгеен сулкытып татлы сөтен имгән анам! Ефәк биләүсәләргә биләп, карап үстергән анам! Каргама агым суларны! Казылык тавының агым сулары гаепсез. Каргама үскән үләннәрне, Казылык тавының үсемлекләре гаепсез. Каргама йөгерек киекләрне, киекләрдә гаеп юк. Арысланны каргама, арысланда гаеп юк. Юлбарысны каргама, юлбарыста гаеп юк. Каргасаң, әтиемнең юлдашы кырык явыз егетне карга. Бу аларның эше!» – диде. «Әнием, елама, борчылма! Мин бу ярадан үлмим. Курыкма! Миңа таулар иясе күренде, бу ярадан үлмәссең, диде. Тау чәчәге белән анаң сөте яраңа шифа булыр, диде; ярамны өч кат сыйпады да китте», – диде.

Моны ишетеп, ханбикәнең кырык кызы төрле якка йөгерештеләр, бер-береннән узышып, тау чәчәге эзләргә, җыярга керештеләр.

Ханбикә имчәкләрен бер сыкты, сөт килмәде; икенче сыкты, сөт килмәде; бөтен көчен җыеп өченче тапкыр сыккан иде, ал кан белән аралаш ак сөт атылып чыкты. Тау чәчәге белән канлы сөтне егетнең ярасына яптылар. Ат өстенә алып, алтын түбәле чатырына озаттылар.

Кырык көндә егетнең ярасы төзәлде. Егет савыкты; тагын атка атлана, кылыч кушана, ау аулый. Кош ата башлый.

Ышаныч хан бернәрсә дә белми, углын үлгәнгә хисап итеп йөри иде. Әлеге кырык явыз егет ни булганны белгәч: «Ышаныч хан углын күрсә, безнең эшебезне белсә, безгә яман булыр, барыбызны юк итәр. Әйдәгез, яхшы чагында Ышаныч ханның үзен тотыйк, ак кулларын аркасына бәйлик, ат кылыннан бау ишеп ак муенына муенчак ясыйк, дошман иленә алып китик тә кол итеп сатыйк», – диештеләр.

Шулай киңәшеп, алар Ышаныч ханны тоттылар, ак кулын аркасына бәйләделәр; ат кылыннан бау ишеп, ак муенына муенчак киерттеләр. Ак тәненнән кан киткәнче, муенын кыл муенчак белән кыстылар; Ышаныч ханны җәяү җибәреп, үзләре атка атланып юлга чыктылар. Карт ханны тоткын итеп сатар өчен, дошман илләренә киттеләр.

Угыз бәкләре бернәрсә дә белмиләр иде; ханбикә хәлләрне сизеп, углы янына китте.

Тыңлап карыйк, ханбикә углы Арыслан бәккә ниләр сөйләде икән:

«Беләсеңме, улым, ни булды? Җир селкенү булмаса да, биек тауны җир йотты. Илдә дошман булмаса да, синең атаңны дошман тоткын итте. Атаңның булышчылары, кырык явыз егет, атаңны тоттылар, ак кулларын аркасына бәйләделәр; ат кылыннан муенчак ясап, ак муеныннан будылар; үзләре атка атланып, атаң картны җәяү йөртеп, дошман иленә алып киттеләр. Углым, тор, үзеңнең кырык егетеңне яныңа ал, атаңны кырык явыз кулыннан коткар. Атаң, явызларның коткысы белән сиңа ук аткан булса, ул сине яхшыларның теләге белән тудырган да. Угыллы ата кол булмас. Явызларның артыннан кит тә атаңны коткар!»– диде.

Арыслан бәк анасының сүзен хуш күрде. Алтын тәхетеннән торды; кара корыч кылычын кушанды; ак өрәңгедән бөккән зур җәя-

сен кулына алды; зур чукмарлы чуен кистәнен ияренә такты; озын сөңгесен аркасына куйды; Акбүз атын тоттырып атланды да, кырык егетен ияртеп, атасын эзләргә китте.

Арыслан бәк качкыннарның артына төште; кырык явыз егет Алатауның аръягындагы ак каен астында туктап, кымыз эчеп утыралар иде; явызлар артларыннан куып килгән яшь егетне күргәч: «Әйдә, бу егетне дә тотып алыйк, муенына муенчак салыйк; дошман иленә илтеп, кол итеп сатыйк», – диделәр. Ышаныч хан: «Кырык иптәшем! Тәңре тотар, җир йотар! Нарасый егетне тоткын итә күрмәгез. Чишегез беразга гына кулымны, бирегез кулыма көмеш кубызымны. Мин бу егетне кире кайтарыйм. Аннан соң үземне үлтерсәгез дә, калдырсагыз да – сезнең ирегегез», – диде. Ышаныч ханның карт күзләре ерактан егетне танымый иде; углы Арыслан бәкне күптән үлгән дип исәпләгәннән, ул килә дип әйтсәләр дә, ышаначак түгел иде; ул яшь егетнең яшьлеген аяп кайтарырга, явызлар кулыннан коткарырга теләде. Алга чыгып көйләп кубыз уйный башлады.

Тыңлап карыйк, Ышаныч хан ни тугрыда көйләде икән:

«Озын муенлы дала атлары китсә, минем атларым булыр, араларында атың булса, әйт, сылу егет, миңа. Орышсыз-сугышсыз бирим мин аны сиңа; тик син кире кайт! Көтү-көтү куйлар китсә, минем куйларым булыр; араларында азыгың булса, әйт, сылу егет, миңа, орышсыз-сугышсыз бирим мин аны сиңа; тик син кире кайт! Кәрваннан кызыл дөяләр китсә, минем төяләрем булыр; араларында югың булса, әйт, сылу егет, миңа; орышсыз-сугышсыз бирәм мин аны сиңа; тик син кире кайт! Алтын түбәле чатырлар китсә, минем өйләрем булыр; араларында өең булса, әйт, сылу егет, миңа, орышсыз-сугышсыз бирим мин аны сиңа; тик син кире кайт! Кара күзле, нечкә билле кызлар китсә, минем кызларым булыр; араларында сайлаганың булса, әйт, сылу егет, миңа, орышсыз-сугышсыз бирим мин аны сиңа; тик син кире кайт! Ак сакаллы картлар китсә, минем картларым булыр; араларында ак сакаллы атаң булса, әйт, сылу егет, миңа, орышсыз-сугышсыз коткарыйм да, җибәрим мин аны сиңа, тик син кире кайт! Минем өчен килгән булсаң, мин углымны үлтердем. Мине алып киткәннең дошман илендә тоткын иткәннең языгы сиңа булмас, и, сылу егет, син кире кайт!» – диде.

Арыслан бәк үзенең көмеш телле кубызын алып, каршыга көйләп уйнады: «Узып барган озын муенлы дала атлары синеке булса,

араларында минем аргамак та бар; мин аны кырык явызга калдыра алмыйм! Кәрван белән киткән кызыл дөяләр синеке булса, араларында минем йөгем дә бар; мин аны кырык явызга калдыра алмыйм! Көтү-көтү симез куйлар булса, араларында минем азык та бар; мин аны кырык явызга калдыра алмыйм. Нечкә билле, кара күзле матур кызлар синеке булса, араларында мин сайлаган кыз да бар, мин аны кырык явызга калдыра алмыйм! Алтын башлы чатырлар синеке булса, араларында мин торачак өй дә бар; мин аны кырык явызга калдыра алмыйм! Ак сакаллы киткән картлар синеке булса, араларында минем дә алдакчы явызларга алданган, күзләре күрмәс булган карт атам бар; мин аны кырык явызга калдыра алмыйм. Синең углың үлмәгән, ул үлемнән котылган; инде тоткын булудан карт атасын коткара», – диде. Арыслан бәк кырык егетен ияртеп, кырык явыз өстенә ташланды; кайсының муенын өзде; кайберсен тоткын итте; карт атасын коткарды; өенә алып кайтты. Ышаныч хан бу шатлыкка туй ясады; угыз бәкләрен җыйды: ханнар ханы – Айбирде ханны да кунакка чакырды. Айбирде хан Арыслан бәккә ханлык бирде. Туйларында Коркыт бабай да бар иде. Ул яшь Арыслан бәккә югарыдагы әкиятне төзеп, түбәндәге теләкне теләде:

«Көчле күк Тәңресе ни эшләсәң дә ярдәмеңдә булсын. Урман ияләре, кыр ияләре, су ияләре юлыңа каршы төшкәннәрнең юлын кисеп, юлыңда булганнарның юлын җиңеләйтсеннәр; тауларыңда, урманнарыңда киекләр, кошлар күп булсын; далаларыңда, болынннарыңда үлән-печән күп булсын; елгаларыңда сулар мәңге кипмәсен; алтын түбәле чатырың даланы мәңге бизәсен; Акбүз атың юртып чабып, аяклары талмасын; корыч кылычың өзеп-кисеп үткен йөзе кайтмасын; очлы сөңгең тишеп, чәнчеп сынмасын. Гомерләрең озын булсын, ханлыкларың котлы булсын; барыннан да бигрәк балаларың күп булсын: балалар – бәхетле кулларга Күк Тәңресенең кадерләп биргән бүләге», – диде.

*Галимҗан Шәрәф. Арыслан бәк. Казан: Мәгариф, 1921. 15 б.*
*«Балалар күңеле» сериясенең 5 нче төп 47 нче китабында басылган.*
*Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче мәртәбә дөнья күрә.*

# IV бүлек

# ХАТЛАР, БӘЯЛӘМӘЛӘР, ДОКУМЕНТЛАР

# РӘСМИ ХАТЛАР

## В ГЛАВПРОФОБР[1] ТОВ[АРИЩУ] М.А. ЗЕЛЬДОВИЧУ

Многоуважаемый тов[арищу] М.А. Зельдович,

Пользуясь любезно предоставленным Вами разрешением, решаюсь затруднить Ваше внимание настоящим письмом. Дело об утверждении моей, Г.Ш. Шарафа, доцентуры направлено было в Главпрофобр уже в июне 1927 г.[2] В октябре 1927 г. во время своего пребывания в научной командировке в Москве, я справлялся в Главпрофобре о положении своего дела. Тогда мне сообщили, что необходимые рецензии от специалистов получены, имеется заключение Совнацмена и Научно-Педагогической секции, и, что заключения благоприятные и остается только проведение окончательного утверждения. С тех пор прошло более года, но таковое утверждение не последовало. Неизвестность положения дела и причин его подобной задержки и принудили меня обратиться к Вам за содействием.

После направления моего дела на утверждение Главпрофобра у меня уже появились в печати ряд новых работ как по основной моей специальности по линии языковедения и татарскому языку, так и по дополнительной специальности по линии статистики и экономики местного края. Из этих работ укажу на следующие:

1. «**Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими**», Казань, 1927 г. 40 стр. о.ф. Работа напечатана в «Вестнике научного общ-ва Татароведения» и отдельной книгой, посвящена сравнительному изучению звуков татарского и русского языков методом применения искусственного нёба. Здесь выявляется ряд неотмечавшихся ранее особенностей фонетики тюркских языков, и дается экспериментально-фонетическое доказательство парности по твердости и мягкости и согласных звуков тюркских языков, и нашими и западно-европейскими тюркологами базиро-

[1] Главпрофобр – Главное управление профессионального образования, центральный орган управления профессиональным образованием в РСФСР в1920–1930 годах.

[2] Дело направлено было Восточно-Педагогическим Институтом в г. Казани, где я состою преподавателем и числюсь доцентом с 1922 г., т.е. с самой организации ВПИ.

валась на парности только одних гласных звуков. Представленная в этой работе новая трактовка «закона сингармонизма» выдвигает необходимость пересмотра и изменения освещения многих элементов фонетики и морфологии тюркских языков (крупное значение этой работы в области тюркологии отмечалось проф. В.А. Богородицким, проф. А.Н. Самойловичем и др.).

2. «**Сонорная длительность татарских гласных**», Казань, 1928 г. 88 стр. о.ф., напечатана в № 8 «Вестника Научн[ого] О-ва Татароведения» и отдельной книжкой. Здесь, на основании изучения длительности татарских гласных кимографом Verdin «а и гортанной капсулой Bousselot[1] впервые научно устанавливаются законы ударения в тюркских языках, а также зависимость общей агглютинативной морфологической структуры тюркских языков от условий экспираторного (динамического) ударения в них. В этой работе одна глава посвящается неизвестному до сих пор в лингвистике экспериментально-фонетическому показателю относительной силы слогов слова и сочетаний слов. Этот впервые выявленный здесь показатель, собственно, и дал возможность переходить от сонорной длительности гласных к законам ударения (так как печатание этой работы только что закончено, то о ней еще отзывов не имеется, но в рукописи она была просмотрена членом-корресп[ондентом] Академии наук СССР проф. В.А. Богородицким, с одобрения какового она и печаталась).

3. «**Психологические основы американского метода обучения грамоте и некоторые особенности применения этого метода в чистом виде в татарских школах**» (Тезисы к сделанному Г. Шарафом докладу на Всесоюзной конференции преподавателей тюрко-татарских языков и литератур в 1927 г. в г. Казани. Напечатано в «Материалах конференции» на тат[арском] языке).

4. «**Вопрос о выделении слогов, звуков и букв при методе целых слов**» – работа составлена мною совместно с И. Алексеевым и напечатано в журнале «Магариф» Татнаркомпроса. В этих двух работах, а также в подготовленной к печати работе об «Особенно-

---

[1] Экспериментально-фонетический метод исследования языковых явлений в области тюркских языков в широком объеме (в этой и предыдущей работе) введен нами впервые. До сих пор тюркские языки этими методами почти не исследовались. *(Прим. Г. Шарафа)*

стях применения американского метода к татарскому языку» (около 7 печ. листов) обосновывается необходимость применения в татарских школах метода целых слов в чистом виде, а также вопрос об использовании при этом агглютинативно-морфологической структуры тюркских языков.

5. «**Исходные методологические моменты экономического районирования применительно к районам Поволжья и Прикамья**» – журнал «Труд и Хозяйство» № 3–4 за 1928 г. стр. 6–25 (перепечатывалась также в сборниках «по районированию Волжско-Камского края» на русском и тат[арском] языках). Эта работа посвящена анализу вопроса об относительной важности принципов хозяйственной специализации, хозяйственного комбинирования и экономического тяготения в качестве районообразующих факторов при определении границ и центров экономических областей.

6. «**Сравнительная характеристика татарского, русского и нацменовского крестьянского хозяйства ТР**». Эта статистико-экономическая работа базируется на данных весеннего опроса крестьянских хозяйств 1927 г. Составлена она мною совместно с т. В.М. Ермолаевым и напечатано в № 11–12 журнала «Труд и хозяйство» за 1927 г.

7. «**Очерки по экономической географии Татарской С.С.Республики**». Эта работа около 17 печатных листов, составлена мною совместно с управляющим Центр. Статист. Управлением Т.Р. тов. В.М. Ермолаевым и печатается одновременно на русском языке и на тат[арском] языке с латинским шрифтом. Одной из особенностей этой большой по объёму работы является изучение в ней социально-культурных и экономических явлений в жизни местного края в национальном разрезе.

Перечисленные выше 7 работ, в случае необходимости, я могу прислать в Главпрофобр в дополнение к присланным ранее 24 печатным трудам, могу прислать также отзывы соответствующих крупных специалистов об этих работах. Так как в октябре прошлого года в Профобре мне сказали, что в этом пока надобности не имеется, то таковые я до сих пор не высылал.

Что касается моей общественной физиономии, то об этом ясно свидетельствует адрес, преподнесенный мне Правительством («ЦИК»ом и СНК) ТР по случаю пятилетнего юбилея ТР, копия

которого при сем прилагается. Лично обо мне и о моей деятельности могут дать отзывы в Москве: 1) бывш[ий] председатель ТЦИК тов[арищ] Шаймарданов[1], ныне инструктор ЦК ВКП (б) по работе в деревне, 2) бывш[ий] Пред. Совнаркома ТР т[оварищ] Габидуллин Х.[2], ныне член Президиума Малого СНК РСФСР, 3) бывш[ий] Пред. ТатЦИК тов[арищ] Сабиров Р.[3], ныне работающий при Президиуме ВЦИК и др. работники – татары, поработавшие в ТР.

Обращаясь к Вам настоящим письмом, прошу оказать содействие скорейшему прохождению через соответствующие инстанции моего дела по утверждению в доцентуре, нет ли необходимости прислать дополнительно научные труды мои и отзывы на них.

Заранее благодарный /подпись/

16 ноября 1928 г.

Мой адрес: г. Казань, ул. Жуковского д. № 15, кв. 4, Г.Ш. Шарафу.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 2 тасв., 1 сакл. бер.*

## МНОГОУВАЖАЕМЫЙ ГАЛИМДЖАН ШАРАФОВИЧ!

От приехавшего сюда Н.И. Воробьёва[4] я узнал о напечатании в Казани весьма интересной карты ТССР, которая вышла при Вашем ближайшем участии. Очень просил бы Вас выслать мне эту карту, крайне необходимую при обработке антропологических материалов по ТССР. Я надеюсь приготовить работу по татарам для «Вестника», выходящего в Казани. Нельзя ли через Вас получить и юбилейный сборник по ТССР, также весьма для меня интересный.

---

[1] Шаймарданов – Шәйгардан Шәймәрдән улы Шәймәрдәнов (1890–1940), дәүләт эшлеклесе, 1925–1927 елларда ТатҮБК президиумы рәисе, 1927 елда ТАССР Халык Комиссарлары шурасы рәисе.

[2] Габидуллин Х. – Хаҗи Заһидулла улы Габидуллин (1896–1937), ТАССР Халык Комиссарлары Шурасы рәисе (1924–1927). РСФСР кече ХКШ әгъзасы (1927–1930). РСДРП(б) әгъзасы (1917 елдан).

[3] Сабиров Р. – Рәүф Әхмәтсабир улы Сабиров (1894–1937), дәүләт эшлеклесе. 1925–1932 елларда СССР ҮБКында милләтләр бүлегендә эшли.

[4] Н.И. Воробьёв – Николай Иосифович Воробьёв (1894–1967), Россия совет этнографы, географ, педагог, физик география профессоры, музей хезмәткәре.

Ни Об[щест]во Татаровед[ения], ни отдельные лица ничего мне сюда не высылают из своих изданий, совсем забыли, между тем, я также интересуюсь Тат[арской] Респ[убликой], как и раньше. Просил бы и Вас вспомнить обо мне и выслать просимое, если это возможно.

Чтобы не затруднять Вас почтовыми хлопотами, посылаю талоны для бесплатной пересылки. Достаточно наклеить их вместо марки и послать за № от учреждения, хотя можно и от частного лица. Как это будет Вам удобнее. Адрес указан на штампе, только припишите к названию музея: «Антропологическое Отделение» – тогда попадет мне в руки. Мою фамилию к адресу Музея не приписывайте: тогда не дойдет бесплатно.

Всего лучшего. Желаю успеха в Вашей интересной работе.

Уважающий Вас Б. Вишневский

19.12.1925.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 2 тасв., 25 сакл. бер.*

**ДОРОГОЙ ДЖАН ШАРАФОВИЧ!**

(Так мы звали Вас. На книге стоит «Галимджан»).

С большим удовольствием я получил Ваши книжки (об одной из них я знал уже по ссылкам Василия Алексеевича в одной из его статей и сам хотел просить прислать мне её). Я рад и за Вас, и за кабинет (дорогой мне по воспоминаниям). Из беглого просмотра Ваших работ я вижу, что Вы нашли в экспериментальной фонетике то, чего я не сумел найти (из-за чего, вероятно, и отошел от неё): настоящий жизненный интерес и возможность разрешать большие принципиальные вопросы еще раз: рад за Вас и за кабинет!

От всей души благодарю Вас. К сожалению, мне нечем отблагодарить Вас: фонетикой (и лингвистикой вообще) активно я не занимаюсь (читаю чужие работы, но ничего не делаю сам), а заметки по сказкам вряд ли для Вас будут интересны. Буду рад при случае получить от Вас весточку. Жму Вашу руку. Ваш Н. Андреев.

24.1.1929.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 2 тасв., 25 сакл. бер.*

# ШӘХСИ ХАТЛАР

## Г. ШӘРӘФНЕҢ ХАТЫНЫ ӘСМАГА ЯЗГАН ХАТЛАРЫ

**Аппак**[1]

Крепко-крепко целую всех. Сегодня получил твое письмо от 25/IX.

Да, милая, ничего не можем делать; остается терпеть, терпеть, терпеть и спокойно, мужественно переносить постигшее нас великое горе, бесконечные страдания и даже, может быть, потерю ненаглядной единственной нашей дочери Юлдузика во цвете лет. Единственное что могу советовать тебе для менее болезненного перенесения горя – это отдаться делу и занятиям, чтобы в процессе дела хоть сколько-нибудь увлечься и забыться, что я и сам делаю и всегда к этому средству прибегал и прибегаю в тяжелые минуты жизни.

Письмо Арсику со стихами, из-за отсутствия 31/X и 1/XI поезда на юг, задержалось, отправляю сегодня ночным поездом. Закончил и прибавил стихотворения-загадки об Арсике (№ 166), а сегодня написал утром экспромтом детскую песню «Голубки» (№ 161) на русском языке, их посылаю с этим же письмом. Таким образом, посылаю 9 новых детских стихотворений и 5 басен для крыловских сборников. Видишь, какая продуктивность; ведь она связана стремлением забыть постигшее нас великое горе. Поцелуй от моего имени Юлдузчика.

Целую много раз, всем привет. Твой Шараф.

1/XI-44

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 2 тасв., 2 сакл. бер.*

[1] Г. Шәрәф хатыны Әсмага Аппагым дип эндәшкән.

**Дорогая Аппак!**

Посылаю ещё одну небольшую группу стихов. Эти стихи перепиши совместно с прежними. Эти стихи пришлось восстановить в памяти, в условиях подготовки к новому этапу перед отъездом из г. Канска[1]. Я их записывал, и в тех случаях, когда основную редакцию не вполне восстановил в памяти какой либо случайной редакцией их. На днях отсюда уезжаем. Больше можете сюда не писать. Новый адрес сообщу по прибытии в новый лагерь.

Целую и поздравляю Юлдуз с блестящим окончанием семилетки, Арсланчика записью в школу.

Всем привет, всех крепко целую. Твой Джан.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 140 сакл. бер.*

## ӘСМАНЫҢ ИРЕ ГАЛИМҖАН ШӘРӘФКӘ ЯЗГАН ХАТЫ

**Дорогой Джан!**

Крепко целую, шлю сердечный привет и желаю здоровья. Ибо это самое основное. Все невзгоды, лишения, несчастья перенести легче, когда ты здоров. А когда ко всему этому + ещё, что ты долго болеешь так, что душа истерзана от этих жестоких болей, все тяжести жизни, недостатки, лишения и т. п. перенести в 10 раз труднее. Теперь нет возможностей, чтоб будучи инвалидом можно было жить не будучи обузой. Да, мой друг, настроение моё самое наисквернейшее, так что едва ли доставит тебе удовольствие читать моё письмо. Приняла ужасно мучительный курс новокаинового обкалывания. Делали 10 сеансов по 75,0 кажд[ый] раз – это значит по 5,0 – 15 раз колоть площадь – правое бедро (сзади) несколько уколов в икру. Так что в такую малую область столько иголок, что я вынуждена даже сидеть на одной половине и лежать на правом боку не могу.

---

[1] Красноярск өлкәсендәге шәһәр.

Сначала было ужасное обострение, потом наступило некоторое облегчение, а в последние дни опять стало плохо. Ничего не остается как на 3–4 месяца слечь в постель, так чтоб тебя кормили с ложки, т.к. это безумная невозможность по условиям жизни придется страдать до тех пор пока хватит остатка силы воли, а там вы знаете что. В последнее время после того, как получила открытку от 19/ XII со стихом, 4 литературных даров не получала. В квартире очень холодно. Днём сидим в пальто, а ночью накрываемся всем, что можно покрыть на себя. Дрова кончились, чтоб купить 3 кбм[1] дров надо где-то у кого-то занять 1500 руб[лей] денег. Пока никаких надежд на это нет. Топим маленькую железку, чтоб воду вскипятить и варить картошку. Получила письма следующ[их] дат, хотя об этом писала 2 раза, 18/XI, 20/XI, 22/XI, 25/XI, 27/XI, 30/XI, 10/XII, 14/XII, 20/XII, 19/XII, 21/XII, 5/I–10/I-45 г. От всех привет и поцелуй. Будь здоров и бодр. Целую. Аппак.

16/VI[2]

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 2 тасв., 24 сакл. бер.*

## Г. ШӘРӘФНЕҢ УЛЫ АРЫСЛАНГА ЯЗГАН ХАТЛАРЫ

### КЕЧКЕНӘ КУНАК

Утырам мин беркөнне
Бик арып эшләремнән;
Бер кунак килеп керде
Кечкенә улым белән.

Бигрәк сөйкемле улы,
Нәкъ минем Арысланым!
Сине күргәндәй булдым,
Ерылды авызларым!

[1] Кубометр.
[2] Хатның язылу елы билгесез.

Утырам да яныңа,
Сөйләшә дә башладым:
«Укуга кердеңме?– дип,–
Бармы,– дип, – чаңгыларың?»

Әй, кыю!.. Уйнап, көлеп
Сөйләшә минем белән;
Ул да нәкъ синең кебек,
Яңа укырга кергән.

Бер рәхәтләнде җаным,
Шаярып аның белән;
Кайчан соң инде, улым,
Уйнарбыз синең белән?

Бигрәк, улым, сагындым
Үзеңне, сүзләреңне;
Дүрт ел була инде,
Күрмәгәнгә йөзеңне.

Сөекле Арысланым! Бу шигырьләрне Яңа елны көтеп утырганда яздым, сезне сагынып, моңаеп яздым. Алдагы яңа елны бергәләп, һәммәбез туганнар белән бергә, өйдә каршыларга насыйп булсын. Улым, нигә хатлар язмыйсың? Синең хатларыңны алмаганыма бик күптән. Әллә инде син язып та, почтада югалып бетәме? Йолдызның исәнлеген, үзеңнең сабакларың, уеннарың, иптәшләр турында яз. Кышкы киемнәрең бармы? Тимераяк, чана, чаңгы шуасыңмы? Уенчыкларың бармы? Яңа елны ничек каршы алдың? Һәммәсен яз! Хуш, һәммәсен дә яз.

Хуш, үбеп, Әттәң. 31.12.42.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 1 тасв., 143 сакл. бер.*

**Милый Арсланчик**

Крепко-крепко целую тебя и Юлдузика. Передай мой привет Әннә, Әббә, Тияп, Наиле и всем родным. Сам жив и здоров. Только за последний год от тебя совсем не получаю писем. Нехорошо, Арсик, забывать Әттә! Тем более и от Әннә последние пять-шесть месяцев письма крайне редки, а с начала сентября и совсем не получал. Поэтому и о состоянии Юлдузика, и о здоровье всех остальных, и о получении большого количества посланных лит[ературных] пакетов нахожусь в полной безвестности.

С этим письмом посылаю 4 стихотворения, новых.

(№ 155–158) для включения в сборники, подготовляемые к печати. Передай их для хранения Әннә и не откладывая в долгий ящик напиши мне ответ-открытку об их получении. Спроси Тияп и напиши о состоянии Юлдузика, и о здоровье остальных. Вообще, давай, милый сынок, имей привычку в каждую 10-ти дневку писать мне по одной открытке и сообщать о здоровье всех домашних и родных, о состоянии Юлдузика, и о получении моих писем, в особенности всех литературных писем, непременно с указанием даты их отправления мною.

Также спроси у Әннә и напиши мне, какие из следующих моих писем получили: от 10 / III, […] 20/ III, 25/ III, 5/ IV, 20 / IV, […] 5/ VIII, 29/ VIII, 9/ IX, 16/ IX, 30/ IX, 15/ X, 16/ X, 20/ X.

Вопрос этот серьёзный и к исполнению моего поручения, милый сынок, относись серьёзно, ты уже большой и славный отличник. Итак, пиши открытку каждую десятидневку. Я несколько раз об этом писал, ещё раз повторяю, относись серьёзно. Ровно через пять месяцев (может быть и раньше, в эти же месяцы) я приеду и расцелую тебя. Будьте здоровы.

Крепко целую. Әттә.

24. X – 44.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 2 тасв., 20 сакл. бер.*

## Г. ШӘРӘФНЕҢ КЫЗЫ ЙОЛДЫЗГА ЯЗГАН ХАТЫ

**Йолдызның сагынмалык дәфтәренә**

Йолдыз, моңсуланма,
Елмаеп кара.
Күрче тормыш нинди
Шат, ямьле ага.
Юк күктә болыт һич,
Нинди саф, аяз.
Сибәли алтындай
Нурларын кояш.
Күк зур фирүзәдәй
Нур белән тулган.
Зөбәрҗәт тезгәндәй.
Баг, болын, урман.
Елмаеп син көл дә,
Ачылсын йөзең,
Яктыртсын тагын да
Җир вә күк йөзен.
Елмаеп бер көл дә,
Шатландыр мине.
Ун ел күрмәгәндәй,
Сагындым сине.
Әттәң.

В ноябре послал тетрадь стихов (около 35 стр.). Жив, здоров, получил посылку, посланную в конце августа и письмо № 9 от 21/X, обрадовался, особенно вашей фотокарточке. Пока живём здесь, дальше на север, вероятно мы выезжать не будем. На днях перебираемся чуть-чуть на юг. Пока здесь зима стоит довольно тёплая. Дни короткие. 2–2 1/2 часа солнце не поднимается выше деревьев. Целую всех.

От всех сегодня получил ещё 2 письма (от 1/IX и 14/XI). Рад вашему здоровью. Г.Ш.

3/XII-40

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге,*
*20 ф., 2 тасв., 4 сакл. бер.*

# Г. ШӘРӘФ ТАРАФЫННАН ЯЗЫЛГАН БӘЯЛӘМӘЛӘР

## ТӨРЕК[1]-ТАТАР ТАРИХЫ. ЗӘКИ ӘФӘНДЕ ВӘЛИДИ ӘСӘРЕ

*(1915 елда Казанда басылган[2])*

Татарларда милли рух күтәрелә башлау берлә, милли тарихыбызны белергә кызыгучылар да арта башлады. Милли рух башта мәктәпләремезгә милли телне кертсә, инде милли тарихны да кертеп бара. Хәзер дә милли тарихның мәктәпләрдә төпләп урынлашуы яхшы тарих дәресләре булуга вә мөгаллимнәремезнең тарих берлә берникадәр таныш булуларына мәүкуфдер[3].[4]

Соңгы ун елга кадәр тарихымыз берлә танышыр өчен, телемездә җитдирәк бары ике мәнбәгъ[5] бар иде: берсе Әбелгазый Баһадур ханның «Тарихе шәҗәрәи төрк» дигән китабының Казан төркисенә тәрҗемәсе (Габделгалләм Фәйзи хан углының тәрҗемәсе булып, 1891 елда Казанда басылган), икенчесе дә Шиһаб хәзрәт Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»е иде.

Анлардан башка Казан төркисендә «Тәварихе Болгария», «Кыйссаи Чыңгыз вә Аксак Тимер», «Шәҗәрә»ләр, «Чыңгыз хан»нар вә «Җәмигыл тәварихе тәрҗемә»се кеби әсәрләр булса да, бунлар

[1] Төрек – төрки мәгънәсендә.

[2] Бу җентекләү иптәшләр учагы өчен язылган иде. Бу ел 2–3 йирдә милли тарих имтиханнарында булуым, бу мәкаләнең матбугатка чыгуы кирәклекне миңа күрсәткән иде. Яз көне милли тарихтан тагын дәреслекләр язучылар барлыкны ишеттем. Анларда тарих мөгаллимнәре дә, әсәрнең мөәллифе *(язучысы)* дә яңадан бастырганда бәлки файдаланыр өмиде илә әсәр 15 нче елда чыккан булса да, җентекләүне матбугатка чыгарырга тиеш күрдем. *(Г. Шәрәф иск.)*

[3] Мәүкуфдер – бәйледер.

[4] Бу ел җәй Багбостан ханым вә Зыя әфәнде Камали тарафыннан ачылачак мөгаллимнәр курсларының матбугатта чыккан программаларында милли тарих дәресләре булмауны тәэссеф берлә укыдым. *(Г. Шәрәф иск.)*

[5] Мәнбәгъ – чыганак.

тарихи җәһәттән әһәмиятсез, күбесенчә хорафат вә хикәяләр берлә тулган. Баштагы икесе генә халык арасында таралган иде.

Соңгы ун ел эчендә исә, милли тарихымызга гаид[1] әсәрләр байтак арттылар вә һаман да артмакталар. Әсәрләрнең саны гына артып калмыйча, мөндәриҗәләре җәһәтеннән дә бик тиз тәрәккый итүләре, бу юлда эшләүчеләребезнең көннән-көн күбәюләре шанлы, ләкин эшләнмәгән, тикшерелмәгән, өсте тузан вә пычрак берлә капланган тарихымызның тиздән җанлану – аякка басуыны вә читләр тарафыннан ташланган пычраклардан арулануыны тиздән күрү өмидене бирә.

Хәсәнгата хәзрәт Габәши үзенең «Мөфассал тарихе кауме төрки» вә аннан соң чыккан «Мөхтәсар тарихе кауме төрки» вә «Төрек ыруглары» исемле әсәрләрендә төрек каумнәренең бүлек вә ыругларыны, бер тәрбия мөнәсәбәтләрене, электәге хәлләрене тәгаен итәргә теләсә, Ризаэддин хәзрәт «Шура»дагы мәкаләләре вә кыйммәтле «Асаре» илә элекке вә соңгы милли тарихымызда әһәмиятле урын тоткан аерым шәхесләр вә анларның фәгалиятьләре[2] илә таныштырды. Гайнетдин Әхмәровның хезмәтләре Болгар вә Казан заманаларының күп якларын ачтылар. Һади әфәнде Атласи «Сибирия тарихы»ны язды. Ләкин 1912 елга кадәр телемездә төрек халыкларының тарихыны иске дәверләрдән алып соңгы вакытка кадәр китергән, фәндә мәкъбүл[3] ысуллар илә бер чиккә тезгән, төрле дәверләрнең бер-бере илә мөнәсәбәтләрене тәгаен иткән әсәр юк иде. Рус матбугатында да мондый әсәрнең булмавы эшне тагын читенләштерә иде. Бу хәл мәктәп вә мәдрәсәләргә милли тарихның кереп урынлашып китүе өчен бик зур манигъ[4] булып тора иде.

Яшь мөәррихләремездән[5] Зәки әфәнде Вәлидинең 1912 ел башында чыккан «Төрек вә татар тарихы» исемле «Милләт» көтебханәсе тарафыннан нәшер ителгән әсәре, тарихымызга гаид материалны фәнни ысуллар илә җыеп, бер тәртипкә кую, бер системага китерү юлында беренче тәҗрибә иде. Зәки әфәнде монда югарыдагы

---

[1] Гаид – караган.

[2] Фәгалиятьләре – эшчәнлекләре.

[3] Мәкъбүл – кабул ителгән.

[4] Манигъ – киртә.

[5] Мөәррихләремездән – тарих язучыларыбыздан.

әсәрләрдә булган мәгълүматны бер чиккә тезү берлә генә калмый, аларда булмаган, татар укучылары өчен яңа булган байтак мәгълүмат та керткән, тарихымызга гаид Шәрык вә Гаребтә басылган бик күп әсәрләр вә мәкаләләр илә таныштырган иде.

Билгеле, беренче тәҗрибә булганлыктан, Зәки әфәнденең бу әсәрдә ялгыш юлдан киткән урыннары, дөрест булмаган карашлары да аз түгел, ләкин алай да булса, беренче адым булганлыктан, тарихымызның үз телемездә эшләнүе юлында бу әсәрнең әһәмияте игътираф ителергә[1] тиештер.

Бу әсәр үзе артыннан озакламый Г. Баттал әфәнденең «Татар тарихы» дигән әсәрене тугдырды. Г. Баттал әфәнденең әсәре төзелеш, теле берлә мәктәптә укыту өчен Зәки әфәнденең югарыда мәзкүр[2] әсәренә караганда уңайрак булса да, мөндәриҗәсе берлә татар матбугатында булмаган бер нәрсәне бирү түгел, Зәки әфәнде тарихыннан соң артка таба бер адым иде. Бу әсәрдә тарихымызның бары бер кисәге –XII гасырдан башлап XVI гасырга кадәр булган бер кыйсеме генә күрсәтелә. Бу ике арада да байтак әһәмиятле моментлар төшерелеп калдырыла. Әсәр өчкә бүленгән: болгарлар хакында (күбрәк этнографияләренә гаид мәгълүмат) – 12 сәхифә[3], татарлар хөкүмәте – 45 вә Казан падишаһлыгы – 40 сәхифә. Бөтен әсәр гүя, Болгар хөкүмәте төзелгәнчегә кадәр татарларның, бабаларымызның тарихы булмаган, Казан ханлыгы беткәннән соң да аларның тарихы юк, дигән тәэсирне калдыра.

Әсәреннән күрелгәнчә, мөәллиф тарихымызга гаид әсәрләрдән татарчада чыкканнарыны гына күреп, әсәрене шулар буенча гына язган булырга кирәк. Телемездә булган әсәрләрнең һәммәсендәге гаепләр Баттал әфәнденең тарихына да күчкәннәр. Чыңгызга кадәр тарихымызның телемездә йитәрлек эшләнмәгән, татарча китапларда бу тугрыда мәгълүмат аз булуына карап, мөәллиф туктап калмаган, тоткан да тарихымызның әүвәл кыйсемене ташлап калдырган. Болгар вә башка төрек-татар халыкларының нәселләре вә бер-беренә мөнәсәбәтләре тугрысындагы фикерләреннән дә мөәллифнең бу хактагы фәнни агымнар берлә төпле рәвештә таныш түгеллеге күренә.

[1] Игътираф ителергә – танылырга.
[2] Мәзкүр – телгә алынган.
[3] Сәхифә – бит.

Г. Баттал әфәнде тарих мөтәхассыйсы[1] булмаганлыктан, бу йитешсезлекләр өчен, билгеле, аны гаепләргә мөмкин түгел. Мәйданга мәктәпләрдә дәреслек урынында истигъмаль итәрлек[2] бер китап та юк вакытта чыгарылганга, анысына да рәхмәт укырга гына тугры килә. Баттал әфәнде тарихында бик зур йитешсезлекләр булганга, Зәки әфәнденең 1912 елда чыккан тарихы да дәреслек өслүбендә язылмый тарих мөгаллимнәре файдаланырлык рәвештә генә язылганга, яхшырак төзелгән яңа бер милли тарих дәреслегенә зур ихтыяҗ бар иде. Шуны күзгә алып булса кирәк, Зәки әфәнде Вәлиди мәктәпләремез өчен «Кыскача рәсемле төрек-татар тарихы» исемендә дәреслек нәшер итте. Безнең җентекләячәк әсәремез – бу әсәрдер.

Әсәрнең тышына «Беренче җөзьә[3]» дип куелган, иншаллаһ, башка җөзьәләре дә чыкса кирәк. Мөәллиф мөкаддимәсендә[4] тарих өчен мөфассал хәритада[5] нәшер итәргә вәгъдә итә. Әсәр зур кулда, 136 битлек булып, Казанда «Өмид» матбагасында басылган.

Әсәр дүрткә бүленгән: 1) Иске заманда төрек халкы – 13 сәхифә; 2) Төрекләр һәм исламият – 17 сәхифә; 3) Төрек иле магулларның шәүкәте[6] дәверендә – 73 сәхифә; 4) Вак ханлыклар һәм төрек иле шәүкәтенең төшүе – 31 сәхифә.

Әсәрдә әлегә чаклы чыккан тарихларымызда булмаган берничә артыклык бар:

1) Милли җиһангирларымызның иң зурларыннан берсе булган Аксак Тимернең шәхесенә, хөкүмәт төзүенә вә аның балалары гасырына зур әһәмият биреп тукталынган. Әлегә кадәр безнең тарихларымызда аңар махсус туктап тормаенча, кырыйлап кына үтәләр иде.

Шиһаб хәзрәт «Мөстәфадел-әхбар»да Тимергә махсус туктамадыгы кеби, Ризаэддин хәзрәт тә үзенең «Шура»сында милли тарихтагы күренгән шәхесләремезнең тәрҗемәи хәлләрене язганда, Ак-

[1] Мөтәхассыйсы – белгече.
[2] Истигъмаль итәрлек – кулланырлык.
[3] Җөзьә – бүлек.
[4] Мөкаддимәсендә – сүз башында.
[5] Мөфассал хәритада – тулы картада.
[6] Шәүкәте – көче, даны.

сак Тимерне калдырып үткән. Зәки Вәлиди дә беренче тарихында шулар артыннан барып булса кирәк, Тимерланның тарихыны төшереп калдырган иде[1]. Шул материаллар буенча гына дәреслегене төзегән Г. Баттал әфәнде дә, билгеле, тарихымызның бу бүлегене төшереп калдырган иде. Һәммә тарихларымызда Аксак Тимер, төзегән хөкүмәте вә балаларының тарихы булмавы зур бер китек вә йитешсезлек булып тора иде. Мөәррихләремезнең шундый бөек бер батыр, заманында дөньяны тетрәткән җиһангирымыз яныннан, ят күреп, тиешле сәламне бирми үтүләре ихтирамсызлык булуы кеби, башкалар берлә таныштырганда балаларымызны бу җиһангир берлә таныштырмый калдыру да күңелгә җинаять кеби тоела иде. Зәки әфәнденең соңгы тарихында бу бушлыкның тутырылуыны шатлык берлә күрсәтеп китәмез.

2) Әсәрдә төрек халыкларында төрле дәверләрдә мәдәният дәрәҗәләрене күрсәтеп китүгә зур әһәмият бирелгән вә китапның бу бабларына бик күп материал кергән. Хосусан, мөәллифнең уйгурлар вә магуллар дәверендәге мәдәният (мәгариф вә әдәбият) тугрысындагы фасыллары тулы вә яхшы язылган.

3) Әсәрнең «Вак ханлыклар һәм төрек иле шәүкәтенең төшүе» дигән бүлеге мөндәриҗәсе җәһәтеннән, беренче мәнбәгъләрдән алынып, татарчадагы тарихларда гына түгел, Аурупа мөәррихләрендә дә табылуы мөмкин булмаган байтак мәгълүматны бирә вә ханлыкларның төзелү вә югалуларының шактый гына җанлы рәсемнәрен күз алдыннан үткәрә.

[1] Ризаэддин хәзрәт үткән елгы «Шура»лардан беренең тышында: «...Әмир Тимур тәрҗемәсене салкын кан берлә язуымызга ышанмаганлыгымыздан бу көнгә кадәр “Шура”да баса алмадык. Безнең аңарга булган үпкәмезнең бетү вә ачуымызның аз гына да йомшау ихтималы юк...», – диеп (1915, 18 нче сан) вә аннан ук 1909 елгы «Шура»да башка бер җиһангирымызның тәрҗемәсене язганда: «Төрекләрне берләштерү юлында гайрәт иттеге вә төрек кауменең шан вә шөһрәтене гарешләргә чыгардыгы өчен Чыңгыз хан иң бөек адәмнәремездән, вөҗүде илә ифтихар идәчәк *(мактаначак, горурланачак)* бөекләремездән исә дә, бу тугрыда улан хиссияте диниямез, хиссияте каумиямезә күрә галибдер *(җиңүчедер)*» («Шура», җилд 2, б. 129), – диеп язган иде. Бу икене бергә кушкач, Ризаэддин хәзрәтнең Тимерланның тәрҗемәсене ни өчен язмавы аңланса кирәк. Ихтимал, хәзрәт өчен дә шул ук сәбәп булгандыр. *(Г. Шәрәф иск.)*

4) 30 лап, күбесенчә, оста вә белеп сайланган рәсемнәр дә әсәргә зур бер кәмаләттерләр[1]. Күп вакытта кечкенә бер рәсем, берничә сәхифәләрдә язып белдерергә мөмкин булмаган тормышны һәммә тәфсилләре берлә күз алдына бастыра ала.

5) Һәр бүлекнең актыгында шул бүлектә кузгатылган мәсьәләләр хакында байтак мәнбәгъләр күрсәтелүе дә һәм тарих мөгаллимнәремез өчен һәм тарихымыз берлә шөгыльләнә башлаган яшьләремез өчен бәһасез бер материал икәнене әйтми үтә алмыйбыз.

Гомумән алганда, бу әсәр – милли тарихтан язылган әсәрләремездән үз бабында иң күп китап күреп язылганыдыр, дисәк, мөбаләга[2] иткән булмасак кирәк. Ләкин шулай да булса, әсәрнең гаепләре, йитешмәгән яклары да юк түгел, байтак бар. Инде аларга күчик:

1) Әсәрнең иң зур гаепләреннән берсе – Чыңгызга кадәр булып үткән төрек хөкүмәтләренә тиешле микъдарда урын бирелмәведер. Бу яктан Зәки әфәнденең беренче тарихы да, бу соңгысы да – Хәсәнгата хәзрәт тарихыннан соң артка таба бер адымдыр. Төрекләрнең иң шәүкәтле заманнары, бөтен Азияне үзләреннән куркытып, зур кыйсемене кулларында тоткан вә Аурупага да күп күз ачарга ирек бирмәгән заманнарыннан һуннар (хунну), төрекләр (тукю) дәверләренә мөәллиф бик аз урын биреп, ярты-чирек сәхифә берлә генә үткән.

Шәүкәт дәверләренең мәркәзләрендә торган: Угыз (Мәүда), Әтил (Атилла) кеби Һун кааннарына, Тумин, Моган, Шигуй вә Шиби кеби шәркый вә гарәби төрек кааннарына вә анларның дәверләренә озаклабрак туктарга кирәк иде. Уйгур, тугыз угыз, болгар, хәзәр вә кыпчакларга кыска-кыска булса да, аерым фасыллар бирелсә, анлар тугрысында шәкертләрдә түгәрәк бер аңлаеш калдыру өчен файдалы булыр иде.

Мөәллиф күчмә төрек кабиләләренең, гомумән, бер-беренә мөнәсәбәтләре, мәмләкәтләрендәге идарә рәвешләре тугрысында тулырак мәгълүмат бирсә, укучылар вә шәкертләргә бу гасырларда төрек хөкүмәтләренең берсе күтәрелеп, берсе төшү кинәттән дөньяны тетрәтерлек хөкүмәтләр тууының сәбәбене аңлау өчен, йиңелрәк

[1] Кәмаләттерләр – камиллектер.
[2] Мөбаләга – арттыру.

булыр иде. Бу вакытлардагы төрек хөкүмәтләренең күршеләренә (кытай вә фарсыларга) сәяси мөнәсәбәтләре дә кыска вә буталчык язылып, күбесенчә, гомуми сүзләр берлә генә үтелгән.

2) Шул ук беренче бүлектә мөәллиф иске төрек дине (шаманизм) тугрысында да берничә юл гына язып китә. Бердән, халыкның дингә ышану вә хорафатлары, аның музыкасы, әдәбияты кеби, рухы берлә танышыр өчен иң яхшы мәнбәгъ, иң дөрест көзге булганга, икенчедән, ничә мең еллар бабаларымыз өчен бердәнбер рухани азык булып килгәнгә, шаманизм тугрысында болай 5–6 юл берлә генә иктифа ителмәскә[1] тиеш иде. Бу кыска мәгълүматта да бигүк тугры булып йитмәгәннәре бар. Иске төрекләр, мөәллиф әйткәнчә, (7 нче сәхифәнең актыгы) «Күкнең, йирнең, ут, су, агач вә мәгъдәннәрнең мәҗмугысы бер Алладан гыйбарәт» дип ышанмаганнар. Бәлки болар һәркаюсы аерым Аллалар диеп таныганнар. Тик бунлар арасында «Күк Тәңре» (яхуд «Хан Тәңре»), халык гел әйтеп, Аллаһы вахидка[2] якын рәвештә башка Аллаларның вә мәхлукатның[3] өстендә саналган. Мөәллиф әйткәнчә, тауларны хөрмәтле санамаганнар. Таудагы рухны хөрмәтләгәннәр. Сугыш, мөәллиф әйткәнчә, дин буенча хөрмәтле саналмаган, бәлки һәрвакыт сугышып торырга тугры килгәнлектән, сугышка яшьтән өйрәтү, лябед[4], менә нәрсә булып киткән (иске төрек динендә Сугыш Тәңресе булу, билгеле, аларның сугышны тәкъдис итүләренә[5] дәлил була алмый). Иске төрек дине тугрысында Зәки әфәнде берничә йирдә «мәгънәсез мәҗүсият» дигән сүзне куллана. Шактый тирән вә матур булган бу дин тугрысында мәгънәсез дигән сүз – безнеңчә, исәпләбрәк кулланугa тиеш булдыгы кеби, иске төрек диненең мәҗүсият булып, әле тәфтишләрдән соң гына өзелергә тиеш мәсьәләдер. Башка күп диннәр кеби, Тәңре дине дә бик күп тәхрифләргә[6], үзгәрүләргә очраганлыктан, хәзерге шаманиларның

[1] Иктифа ителмәскә – канәгатьләнмәскә.
[2] Аллаһы вахидка – бер Аллаһка.
[3] Мәхлукатның – җан ияләренең.
[4] Лябед – котылгысыз.
[5] Тәкъдис итүләренә – мөкаддәс итүләренә.
[6] Тәхрифләргә – үзгәртүләргә.

дине иске төрек дине берлә танышканда материал гына була алалар[1].

3) Мөәллиф: Төрек, маньчжур, магул, фин вә гайре буыннарга кардәш халыклар өчен гомуми исем итеп «Туран» сүзене истигъмаль итә (б. 2, 4, 31 вә башкаларда), элегрәк «Туран» исемене гарби[2] мөәррих вә этнографиядән истигъмаль итүчеләр булгалаган. Бәгъзылар бу исемне төрек-магуллар хакында гына, бәгъзылар төрек, магул вә маньчжурлар өчен (Шәмсетдин Сами бәк тә «Камусел-әгъләм»дә шул мәгънәдә истигъмаль итә) вә бәгъзылар исә Зәки әфәнде кеби төрек, магул, маньчжур, угро-фин вә арадагы башка кардәш халыкларга гомуми исем итеп кулланганнар. Туран исемене тагын да киңрәк мәгънәдә истигъмаль итүчеләр дә булган. Хәсәнгата хәзрәт тә «Тарихе кауме төрки»дә (б. 20) югарыда күрсәтелгән һәммә халыклардан тыш, кытайлар вә японнарны да әкъваме[3] туранидан саный.

Бердән, «Туран» исеме югарыда күрсәтелгәнчә, төрле галимнәр тарафыннан төрле киңлектә истигъмаль ителгәнлектән, аны алу фәнни җәһәттән уңайсыздыр. Икенчедән, хәзерге туран инеше (низменносте) мөәллифнең туран диеп атаган халыклары өчен характерный булмадыгы кеби, «Шаһнамә» бәетләрендәге вә фарсы

[1] Шаманизм берлә танышырга теләүчеләр өчен русчадагы әсәрләр:

1. *Базаров.* «Черная вера или Шаманизм», СПб. 1891.

2. *Михайловский.* «Шаманство» (Изв. Имп. общ. люб. ест. Т. 75 м. 1892).

3. *Трощанский.* «Эволюция черной веры у якутов», Казань, 1902.

4. *Валиханов.* «Следы Шаманства у Киргизов» (в собр. соч. СПб. 1904).

5. *Молов С.* «О Шаманстве у соргутуров» (Жив. ст. 1912).

6. *Радлов В.* «Мифология и миросозерцание жит. Алтая», Вост. обозр. 1882–1883.

7. *Васильев В.* «Изобретения долгано-якутских духов, как атрибуты Шаманства», Ж. ст. 1909.

8. *Васильев В.* «Шаманский костюм и бубен у Якутов» (Сб. Музея по антр. и этногр. при Акад. Наук, VIII, СПб. 1910.

9. *Хангалов.* «Новые метариалы о Шаманстве у Бурят», Иркутск, 1890.

Монда бу тугрыдагы әсәрләрнең әһәмиятлерәкләре вә яңа танышучылар өчен әһәмиятләре тәртибенчә язылды. Бу тугрыда Азия вә Сибириягә сәяхәтнамәләрдә байтак мәгълүмат бар. Радловның «Төрек каумнәренең халык әдәбияты нәмунәләре», Катановның «Урянхай телен тәфтиш» вә Гамбуевның «Иске магул гадәт вә ышанулары» дигән әсәрләрендә шаманиларның бәгъзы догалары бар. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Гарби – Көнбатыш.

[3] Акъваме – кавемнәр.

ганганәләрендәге[1] тураниларның, магул, маньчжур йә финнардан булуы дәлилләр берлә сабит[2] мәсьәлә түгелдер. Иран вә Туран сугышыны, аклар берлә сарылар сугышы булмаенча, кардәш халыкларның үзара тәхет вә өстенлек өчен генә сугышулары диеп караучылар бар.[3] Шул уңайсызлыклардан котылыр өчен булса кирәк, соңгырак Гареб галимнәре «Туран» истыйляхыны[4] ташлаганнар, төрек-магулларга Алтай халыклары исемене вә төрек, магул, маньчжур, угро-фин вә башка арадагы халыкларны бергә алган да «Урал-Алтай халыклары» истыйляхыны истигъмаль итәләр.

4) Мөәллиф: «Маньчжур, магул, финнарга һәрвакыт төрекләр кулы астында, алар идарәсендә гомер итәргә тугры килгән», – ди (5 вә 31 б.). Тарих, башка Урал-Алтай халыклары берлә финнар арасында сәяси мөнәсәбәтнең бик аз булуыны күрсәтә. Шуңа күрә башкалар финнар кулы астында булмадыгы кеби, финнар да, гомумән алганда, ни төрекләр, ни башка Урал-Алтай халыклары кул астында булмаганнар. (Тарих тик Атил–Атилла кулы астында берникадәр фин-угыр ыруглары булуыны гына ачык күрсәтә.) Маньчжурлар илә магуллар хакында да һәрвакыт төрекләр идарәсендә булганнар дияргә мөмкин түгел: һән (хунну) вә төрек (тукю)лар дәверендә маньчжур вә магуллар төрекләр кулы астында торган булсалар, Чыңгыз вә аның балалары вакытында маньчжурлар да, төрекләр дә – һәммәсе магуллар кулы астында иделәр. Тукюлар берлә чыңгызилар дәвере арасында исә һәм төрекләргә, һәм анларның магул бүлегенә күбесенчә Кытайда хөкүмәт сөргән маньчжур сәләләләре[5] кулы астында яшәргә тугры килде. Шуңа күрә, мөәллифнең югарыдагы фикере тугры булып бетмидер.

Мөәллиф үзе дә 9–10 нчы сәхифәләрдә бу заманны «асылы төрек булмаган сәянпы вә жуҗаннарның бөтен төрек, магул вә маньчжурларны үз кулларында тотулары» тугрысында сөйли. (Әйтеп китәргә кирәк ки, һәм сәянпы, һәм жуҗаннар тугрында бу сүзләр мөбаләгалыдырлар[6]. Аның өстенә сәянпы вә жуҗаннарның

[1] Ганганәләрендәге – сүз күчүләрендәге.

[2] Сабит – ачык.

[3] Иностранцевның «Һуннар-хуннулар» дигән әсәре каралсын (Жив. стар. 1900 воп. 3–4). *(Г. Шәрәф иск.)*

[4] Истыйляхыны – атамасын.

[5] Сәләләләре – ыру, нәселләре.

[6] Мөбаләгалыдырлар – арттырылулыдыр.

асылы төрек булып булмавы да – хәзергә фән карашында өзелмәгән мәсьәләдер).

Сүз тугры килгәндә, мөәллифнең магул вә төрекләрнең нәсел ягыннан бер-берсенә мөнәсәбәтләренә, карашларына да бераз туктап китик. Мәгълүм ки, антропология галимнәре магуллар илә кыргыз вә якут, нугай вә башка төрек халыкларында күпчелек арасында баш вә тән сөякләренең, чәчнең вә тән тиресенең төзелеше ягыннан аерма тапмыйлар. Шул ук халыкларның мәдәният ягыннан бер үк баскычта торганнарның хәвәлә, ышану вә гадәтләрнең бердәй диярлек якын булуы күрелә. Магуллар арасында да кыргыз, башкорт, хәтта Анатулы төрекләре арасында очраган сөякләр очрыйлар. Лисан галимнәренең тәфтишләре тел ягыннан башка төрек телләренә Урал-Алтай телләре арасында иң якыны магул теле икәнен күрсәтәләр. (Абал Рамуза, Кастрен вә башкаларның әсәрләре каралсын.) Магул шивәсен дә, төрек шивәсен дә бик яхшы белгән галимнәр дә сүзләрнең төпләрен (корень) тикшергәндә бу асыл магулча, бу асыл төрекчә дип аеру мөмкин түгел дәрәҗәсендә дип карыйлар (Катановның «Урянкт»лар теле тугрысындагы бөек әсәре каралсын). Венклер, Рамстаутларның соңгы тәфтишләре элек тә магулчага гына махсус дип саналган бәгъзы төпләрнең төрекчәдә булган төпләрдән үк булганлыгын күрсәттеләр. Мөтәхассыйслар бу телләрнең сарыф вә нәхү якларыннан да төзелеше бердәй булуыны сөйлиләр. XII гасырдан мөкаддим хәзерге магул халкының вә аның теленең булуы да әле ышанычлы дәлилләр берлә исбат ителгән бер мәсьәлә түгел. Амур мәнсабларыннан[1] килеп, XI–XII гасырларда Шимали Кытайны рәхәтсез иткән, маньчжур халыкларыннан булган ман-гу берлә Чыңгыз хан магуллары (ман-гу) – бер-бере илә башкадырлар. Соңгылар мангу (магул) исемене Чыңгыз каан булгач кына вә сәяси гарызлар[2] буенча гына кабул иткәннәр[3] вә буңа яңа исемле халыкның төбенә күбесенчә конгыр (конграт), кирәй (караит), сакиз (найман), татар, җалаер, уңгы (уңгыт), уйгурлар кеби асылы

[1] Мәнсабларыннан – тармакларыннан.

[2] Гарызлар – аңлатулар, тәкъдимнәр.

[3] Труды Вост. Отд. Р. Арх. общ. ның IV җилдендә Васильевның әсәре вә «Махун»ның тәрҗемәсе, Шмидтның магул вә каганиус әссәнаигъ чәчәнне нимесчәгә тәрҗемәсе (Питер, 1829) вә «Чыңгыз йортының яшерен тарихы» дигән әсәр каралсын. *(Г. Шәрәф иск.)*

төрек булган[1] элементлар булса да, арага маньчжур элементлары вә бер ни кадәр Кытай элементлары (әсирләр) дә кергәнгә, кушмадан хасыйл булган яңа халыкның теленә алар да тәэсир иткәннәр. Маньчжурлар шәркый төрекләр вә кытайлар арасында борын-борыннан кыз алып, кыз биреп торулар булганны, бер ыруг икенче ыругтан булган гаиләләрне хәтта кечерәк ыругларны бөтене берлә әсир итеп алып китүләр булганны күрсәтәләр. Билгеле, бу йотулар һәр ике тарафтан теленә дә тәэсирсез калмаган. Чыңгыз вә балалары дәверендә билкасд[2] төрле ыруг халыкларыннан оештырылып ясалган гаскәр бүлекләре, гомумән, чыңгызилар дәвере йирле төрек кабиләләре берлә Шимальдән вә Шәрыктан килгән маньчжур кабиләләрене бер-бере илә катыштырган, бутаган. Шулай итеп, хәзерге Монголия өчен гомумирәк бер тел мәйданга килгән булса кирәк. Иске Кытай тарихлары үзләренең шималендә берсе – тауларның уң ягындагы маньчжурлар, икенчесе –тауларның сул ягындагы халык. Тауның уң ягында да, сул ягында да һаман бер үк халыкларның алмашынып торуларыны күрсәтәләр. Магулларны да шул ук төптән вә халыктан, диләр.[3] Синалог[4] вә монголологлардан Якинов, Шмидт вә башкалар XIX гасырның беренче ярымында шул әсас буенча монда булып үткән халыкларның (хунну, тукю вә уйгерларның) һәммәсенең магулдан булуыны дәгъва иттеләр. Ләкин уйгурча язулар вә «Котадгу белег»нең табылуы уйгурларның «төрек»тән булуыны күрсәттеләр (хәзер дә төреклекләрене бер дәрәҗә югалткан уйгурлар булса да, бунларның төрле тәэсирләр астында гына үзгәргәнлекләре күренде). Орхон язуларынының табылуы тукюларның төрек икәнлекләре вә «тукю» сүзе үзе «төрек» дигән сүзнең кытай хәрефләре берлә генә язганы икәнен күрсәттеләр. Хуннулар да төрекләрнең бабалары булуыны Гареб галимнәре кабул

---

[1] Бу халыкларның төп төректән булуларыны ислам мөәррихләре сөйлиләр, Хоуберт, Аристов кеби галимнәр исбат итәләр. Орхон язулары күрсәтәләр, боларны Кытай мөәррихләре Шато тукюннән (дала төрекләре) саныйлар. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Билкасд – алдан уйлап, ниятләп.

[3] Якиновның иске кытай әсәрләреннән җыеп тәрҗемә иткән «Урта Азиядә торган халыклар тугрысындагы хәбәрләр» дигән әсәренең мөкаддимәсе каралсын. *(Г. Шәрәф иск.)*

[4] Синалог – Кытайны өйрәнүче.

иттеләр.[1] Якинов вә Шмидтларның фикерләре ялгыш булып чыгуы, кытай тарихларындагы әсасның ялгыш булганын күрсәтмиләр, тик бу галимнәрнең кытай тарихлары сүзенә ялгыш мәгънә биргәннәрене генә күрсәтәләр. Кытай мөәррихләрендә күрсәтелгәнчә, чыннан да, тауларның сул ягындагы халыклар һаман бер төптән, бер нәселдән килгән халык булуы мөмкин, ләкин бу нәсел, бу асыл – алар уйлаганча, «магул» түгел, «төрек»тер. «Магул» үзе дә – шул асылдан бер бүлек кенәдер. Болай караганда, кытай мөәррихләренең фикере берлә мөселман мөәррихләренең фикере бергә киләләр. Чөнки мөселман мөәррихләре дә бу тарафларда торган угыз, уйгур, кыргыз, татар вә магулларны – һәммәсене бер асылдан – «төрек»тән таралган диеп саныйлар. Магул ханнары сарайларында булган рәсемне мөәррихләр дә тарихларында магулларны төрек кабиләләреннән берсе итеп кенә таныйлар.[2] Чыңгыз нәселеннән булган мөәррих[3] Әбелгазый Баһадур хан «Тарихе шәҗәрәи төрк»ендә магуллар төрекләрнең бер кыйсеме генә булуыны тәэкид итә[4]. Без кулымызга төшкән башка фарсы, гарәби вә чыгтайча әсәрләрдә дә моңа каршы булган бер фикер очратмадык.

Без монда китерелгән дәлилләрнең XIX гасырның соңгы яртысында Аурупа голямасы арасында мәшһүр булып киткән төрек берлә магулны аеру вә магулны (монгол) фин, кытай, япун вә төрек кеби сары җенестәге төп асыллар арасына кертү дәгъвәсе илә тәнкыйть берлә карау өчен йитәрлек дип уйлаганымыз кеби, магулны төрекнең бер фәргысы[5] гына түгел диючеләрнең фәнни әсаслардан чыккан шөбһәсез дәлилләре булмаган мөддәттә, ислам мөәррихләренең дә, кытай мөәррихләренең дә карашларына тугры килгән вә югарыда күрсәтелгән әсаслары булган магулны төрекнең фәргысы диеп тану әсасыны ташларга ихтыяҗ юк диеп беләмез.

[1] Хуннуларның асыллары тугрысында Иностранцевның югарыда мәзкүр әсәре каралсын. Башкаларның асыллары хакында «Живая старина»да (1904) Аристов әсәре каралсын. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Фазлулла Рәшидетдиннең «Җәмигъ эт-тәварих»ка мәдехле *(мактаулы)*, Галәетдин Җөвәйнинең «Тарихе җиһаншай», Мирхавандның «Раузател-сафа», Хаванд- Әмирнең «Хәбибес-сәер» дигән әсәрләре вә гайреләрнең һәммәсендә бу мәсьәләгә карашы бер төрледер. *(Г. Шәрәф иск.)*

[3] Мөәррих – тарихчы.

[4] Тәэкид итә – раслый.

[5] Фәргысы – тармагы.

Зәки әфәнде исә әсәрендә магул берлә төрекләрне бөтенләй аерып куя (2, 4, 40 б. вә гайреләр), хәтта тезгәндә төрек, маньчжур, магул диеп санап (31 б.) маньчжурларны урта арадагы бер милләт итеп күрсәтә. Бу караш гареб асарендә соңгы вакытка кадәр мәшһүр караш булганга, Зәки әфәндене бу карашка кушылуы өчен, билгеле, гаепләргә мөмкин түгел. Ләкин бу агымны ихтыяр вә кабул итсә, мөәллиф әсәрендә баштан актыкка кадәр шул юлдан барырга тиеш иде. Әсәрдә исә бу күренми. Ул магулларны төрек-татарлардан аерым, анларга ят милләт диеп карый. Ләкин үзе «Төрек-татар тарихы» диеп исемләнгән китабының өчтән ике өлешене магуллар шәүкәте дәверенә хәсыр итә[1] вә бу дәвер тугрысында: «Бу дәвер төрек халкы хәятында матур бер дәвер хисаплана. Бу дәвердәге хәятында төрек халкы чиксез зур кузгалышлар ясап, үзенең кем икәнен дөньяга янә ачыграк танытты»... , «төрек халкы бу вакыт үзене йирнең иң күп өлешенә һәм йир йөзендәге күп милләтләргә чын мәгънәсе берлә хуҗа булып торганын, үзенең милли хәяты, милли көче берлә тереклек итә ала торган бер тоташ икәнен ачык күрде», – ди (б. 82–83). Бу сүзләр күрше килене пешергән ботка берлә мактану булыбрак чыгалар.

Әгәр мөәллиф югарыда әйткәнчә, магулларны төрекләргә ят халык дип караса, аларның тәслитъ[2] дәверене төрекләр өчен шәүкәт дәвере дип түгел, төшкенлек дәвере диеп карарга тиеш иде вә төрекләрнең иң зур шәүкәт дәверләре итеп, һун, төрек (тукю), уйгур хөкүмәтләренең заманалары саналырга тиеш вә китапта иң күп урын шуларга бирелергә тиеш иде. «Магуллар шәүкәте дәвере» дигән бүлектәге күзгә бәрелгән әсәрнең гомуми агышы өчен әһәмиятле булган бәгъзы хаталарны да күрсәтеп китик:

1) Мөәллиф: «Кытайдагы император нәселе, Тимучинның саксызлыгыннан файдаланып, аны әсир итеп алды. Тимучин анда ун еллап гомер итте», – ди (33 б.). Дөрест, Мән Хун дигән бер кытай сәйяхы[3] шундый бер хәбәр яза[4]. Ләкин рәсеме кытай тарихларында бу тугрыда һичбер нәрсә улмадыгы кеби фарсы вә гарәп мөәр-

[1] Хәсыр итә – билгели.
[2] Тәслитъ – хакимлек.
[3] Сәйяхы – сәяхәтчесе.
[4] Труды Вост. Р. Арх. общ. т. IV ср, 218. *(Г. Шәрәф иск.)*

рихләрендә дә мондый хәбәр күренми[1]: бөтенләй диярлек Чыңгызның Монголиядәге хәятына хәсыр ителгән «Алтан Тобчи»[2] вә «Сәнаигы чәчән» кеби магул вакыйг нәвисләре[3], Чыңгызның башыннан үткән һәммә башка читенлекләргә туктап та, бу тугрыда һич нәрсә язмаганнар. «Чыңгыз йортының яшерен тарихы»нда да бу тугрыда бер хәбәр дә юк[4].

2) Мән Хун әйткәнчә, кытайлар арасында 10 елдан артык калу Чыңгызның табигатенә тәэсир итәргә, һич булмаганда Чыңгыз бу вакыт эчендә кытайча сөйләшергә өйрәнергә тиеш иде. Ләкин Чыңгыз хәятының дәвамы бунларны күрсәтмиләр. Рәшидетдин вә Җөвәйни Чыңгызның ана теленнән башка телне белмәвене язалар.

3) Чыңгызның бөтен хәяты дәлилләр берлә, сабит вакыйгалар берлә тулы булып, бу вакыйга өчен унъеллык буш урын юктыр.

4) Мән Хун бер сәйях кына булдыгыннан, аның тарихка гаид сүзләре башкаларга хилаф булмаганда вә анлар тарафыннан да тәэкид ителгәндә генә кабул ителергә тиеш. Шундый сәбәпләрдән булса кирәк, Доусон, Һаир, Һоворт кеби гареб мөәррихләре Мән Хунның бу сүзене кабул итмәгәннәр. Зәки әфәнденең бу сүзне ни өчен генә кабул итүене без белә алмадык.

5) Мөәллиф: «1200 елларга кадәр ул (Чыңгыз) Байкал күле әтрафындагы, Орхун буендагы һәммә кабиләләрне җыйды», – ди (33 б.). Тарих исә Чыңгызның бу вакытка кадәр Онон буендагы кабиләләрне генә җыйганын күрсәтә. Мөәллиф үзе дә югарыда күрсәтелгән урыннарда торган, караит, найман вә гайреләрнең 1200 елдан байтак соң кушылганнарын яза (33 вә 34 б.).

6) Чыңгыз гасырында Харәзем мәмләкәтендә «Харәземшаһ исемендә башта хәлифәнең валисе[5] булып та, соңында аңа каршы истикъляль игълан иткән бер нәсел идарә итә иде», – диелгән (38 б.). Тарих исә буны күрсәтми. Харәземшаһларның төп бабалары Ануш сәлҗүк ирләреннән Билгәткиннең сатып алган колы булган, соңрак моның балалары Төркестанда урнашканнар. Истикъляль игълан

[1] Бу соңгы әсәрнең Баллади тарафыннан русчага тәрҗемәсе «Труды Пекинской Миссии»ның 4нче җилдендә басылган. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] «Алтан Тобчи» – XVII гасыр монгол елъязмасы.

[3] Вакыйг нәвисләре – танылган язмалары.

[4] Ибне Лясиз. Әл-Кямал, җилд 10, б. 182. «Тарихе җиһаншай», «Бартольд» «Магул дәверендә Төркестан», җилд 2, б. 346–350. *(Г. Шәрәф иск.)*

[5] Валисе – идарәчесе.

итүдән элек исә, Мөхәммәднең бабасы атсыздан башлап кара кытай гүрханнары кулы астында аларның валие булып торганнар. Гүрханнарның куәтләре кимегәч, Харәземшаһ Мөхәммәд вакытында гына ихтилял чыгарып, истикъляль кәсеп иткәннәр. Димәк, бер вакытта да Мөхәммәднең бабалары хәлифәнең валие булмаганнар[1].

7) «Каныклылар чыңгыз килгән вакытта Харәземшаһка “бик мотыйгъ”лар иде», – диелгән (39 б.). Тарих бу вакытта каныклылар берлә Харәземшаһ Мөхәммәд арасы бозык булуыны күрсәтә[2]. Сәмәркандта каныклыларның бер юлы кырык меңләп үз ихтыярлары берлә Чыңгызга бирелгәннәрен мөәллиф үзе дә шул ук сәхифәдә яза.

Гомумән, Чыңгызның Төркестан сәфәренә 4–5 сәхифә бирелеп тә, магуллар шәүкәте өчен әһәмияте аннан ким булмаган кытай сәфәренә ярты сәхифә дә бирелмәгән.

8) Казан ханлыгының тарихы башка вак ханлыклар арасына гына кертелеп, аерым тукталмаган. Бөтен Казан ханлыгына башкалар арасында берничә юл бирелеп, шуның берлә генә үтелгән. Әсәргә фәнни бер әсәр дип, фәнни ноктадан гына караганда, мөәллифнең бу эшене бер дәрәҗә сөкүт[3] илә үтәргә мөмкин булса да, милли ноктадан күз алдында тотылып, язылуы тиеш булган бер дәреслек өчен бу да гаептән саналырга тиештер.

9) Әсәрдә карап бетермәүдән килгән ялгышлар да еш очрыйлар. Мәсәлән: маҗарлар бер йирдә «фин»нардан, бер йирдә «төрек» кабиләләреннән (25 б.), бер йирдә һәм төрекләргә һәм финнарга аерым бер асыл итеп тәлкыйн ителә[4]. Әсәрнең 2 нче сәхифәсендә венгр вә маҗарларны бер-беренә башка ике халык диеп аңларга мөмкин (дөресе бу ике исем – «угро-фин»нардан булган бер үк халыкның ике исемедер). Күлтәгин бер йирдә (10 б.) Билге каанның

---

[1] Ул вакыттагы Багдад хәлифәсе Насретдинулла берлә Харәземшаһ Мөхәммәднең арасы яхшы чагында Харәзем мәсҗедләрендә хотбә исеменә укылып та, аралары бозылгач, Харәземшаһ башка берәүне хәлифә итеп игълан итүе вә хотбәне аның исеменә укыта башлавы мәсьәләсенең сәяси истикъlялга мөнәсәбәте юктыр. *(Г. Шәрәф иск.)*

[2] Каныклылар Мөхәммәднең үги анасы Тәркан катын тарафында булганнар. Шәйх Мәҗдетдин Багдадины төһмәт илә үлтерткәннән соң, Тәркан катын берлә Мөхәммәднең арасы бозылган. Каныклылар да шуннан соң Мөхәммәдкә кырын карый башлаганнар. *(Г. Шәрәф иск.)*

[3] Сөкүт – дәшми тору.

[4] Тәлкыйн ителә – аңлатыла.

агасы диеп, бер йирдә (12 б.) энесе диеп йөртелә (дөресе соңгысыдыр). Чыңгызның икенче углы – Чагатай, өченче углы – Үгәдәйдер (36 нчы сәхифәдә ялгыш тәртиптә куелган), 37 нче сәхифәдәге «төрек-магул гаскәре тәмам сугыш киемендә» дигән рәсем ни йөзе, ни тәне, ни дә киемнәре берлә төрек гаскәре дә, магул гаскәре түгелдер. Әсәрнең һәр битендә диярлек 6–7 матбага хатасы булуы да әсәрнең күрекене йибәрә. Әсәрдә баштан актыгына кадәр бер имля сакланып барылмаган.

10) Әсәрнең теле матур түгеллеге, иләмсез вә ялгыз төзелгән җөмләләрнең байтак очравы да сөкүт илә узылырга тиеш түгелдер. Әсәрдә: «Шундый дошман кешеләр, кабиләләр, Темучинга атасының бабаларының дәүләтен кайтарып алырга кыйвынлык (?) бирделәр» (33 б.), «Хәрам булган эшләрне (?) истигъмальдан халкын бик нык тыйды»..., «Чыңгыз фәкать шамани мәзһәбендә торды, мәмләкәт һәм фәтвахат (?) һичбер дини ният тотмады. Тимер исә, шаманлык (мәҗүсилек) өстенә (?) бик нык мөселман иде» (75 б.) кеби сәер генә җөмлә вә мәгънәләр «ул үзе күчмә тереклекне бик ярата, халкының шул күчмә мәгыйшәттә булулары берлә бергә гыйлем вә һөнәр дә шәп һәм бай булуын теләде» (44 б.) җөмләсендәге кеби сәхифәләрне ялгыш истигъмаль итүләр дә очрыйлар.

Әсәрдә «Әй сез! Миннең гаскәрем! Сез миннең кәпәчемнең өстенә тезелгән алмас-зиннәтләр төслесез» (35 б.), «миннең башыма төшкән авырлыклар» (36 б.), «миннең аркамдагы кабыргаларым» (43 б.) вә башка шундый җөмләләрдә яңа әдәбиятымызда мәкъбуль вә мәгъруф «минем» сүзе урынына «миннең» истигъмаль ителүене чыгтайчага иярүме (архаизм), башкортчага иярүме (провинциализм) дияргә аптырап калдым.

Югарыдагы җөмләләрдә «миннең» дигән сүзләр бөтенләйгә төшерелеп калдырылса да, җөмләләрнең татарчалыгы артып, тәрҗемәлеге югала гына төшә вә мисалга зарар килми бугай.

Хәзергә шулкадәр берлә тәмам итик. Билгеле, һәр әсәрнең яхшы ягы да, йитешмәгән ягы да була. Тарих язу йиңел эш түгел. Хосусан, төрек халыкларының тарихы башкаларныкына караганда да эшләнмәгәнрәк булуы, бу юлда хезмәтне тагын да авырлаштыра төшә. Зәки әфәнденең әсәре – күрсәтелгән йитешсезлекләре берлә алганда да, мәктәпләремез өчен дә, гомумән, тарих берлә шөгыльләнүчеләремез өчен дә бәһасез вә кадерле бер әсәрдер. Монда бәгъзы

йитешсезлекләре күрсәтелсә дә, алар әсәрнең әһәмиятене төшерергә тиеш түгел. Әсәрләрнең күбрәгендә андый йитешсезлекләр монда күрсәтелгәнчә кечкенә гадәдләргә[1] генә сыймыйлар. Анларның хаталарыны күрсәтергә керешсәң, бөтен әсәрне яңадан язып чыгарга кирәк була. Татар матбугатында тарихтан язылган әсәрләр эчендә андыйлар да юк түгелдер. Һәммә тарих мөхибләренә[2] вә тарих мөгаллимнәренә әсәрне тәүсыя итеп, мөәллифенә әсәре өчен тәшәккер итәмез, милли тарихымыз бабында тагын җитди әсәрләр көтеп каламыз.

Галимҗан Шәрәф. Аксу – июнь, 1916 ел.

*Мәкалә «Шура» журналының 1916 елгы 13 һәм 14 нче саннарында «Галимҗан Шәрәф» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге язуда беренче тапкыр басыла.*

## Х. БӘДИГЫЙНЕҢ «ТАТАР ТЕЛЕ ГРАММАТИКАСЫ ДӘРЕСЛӘРЕ» ТУРЫНДА

*(Тел программаларын карау мөнәсәбәте белән)*

Бу китап хәзерге татар теле программасының кереш бүлеге һәм читтән торып укучылар программаларында кулланма итеп күрсәтелгән. Бу китапта, бигрәк тә, хәзерге татар теле курсының кереш бүлегенә караган методологик бүлегендә байтак җитешсезлекләр бар. Боларда кайберләре:

1. Китапта телнең гомуми табигатен билгеләүдә, марксист телчеләр карашыннан меньшевикланучы идеализм дип танылган теория, Волошиновның[3] телгә билге дип карау теориясе нигезендә барыла (3, 6, 8, 9, 14 б. һ.б.). Телнең үсеш, развитиесе дә 10 нчы бит башында шул томга – билгеләр үзгәрүгә кайтарып калдырылып, формалист тел тарихчылары карашы бирелә.

2. 6 нчы биттә: «Уй – тамгалар белән тутырылган идеология акты. Икенче төрле әйткәндә, уй тамгалы мөндәриҗә белән тулган чакта гына, шулай булгач, иҗтимагый мөнәсәбәт процессында гына

[1] Гадәдләргә – саннарга.

[2] Тарих мөхибләренә – тарихны яратучыларга.

[3] Волошинов Валентин Николаевич (1895–1936) – лингвист, философ, музыка белгече.

чын уй булып әверелә. Кешедә уй сүздә, мәгънәле ымда һәм башка шундый тышкы материалларда гына оялый ала. Бу материаллардан башка ул – тамгалар белән яктыртылмаган ялангач физиология акты гына булып кала», – диелә. Димәк, монда Ленинның «Материализм һәм эмпириокритицизм»[1] дигән әсәрендә көрәшеп килгән иероглифлар теориясе бирелә.

3. 9 нчы бит актык абзацта төзәтмәләрсез Бухаринның[2] тигезлек (равновесие) теориясе тел үсешенә анализ өчен нигез итеп алына.

4. 9 нчы бит 2 нче абзацта: «Өстен сыйныф телгә сыйныфсызлык мәңгелек характерын бирергә, аның эчендә бара торган иҗтимагый акцентларның көрәшен сүндерергә, җөгәрсезләндерергә, аны бер генә акцентлы итеп калдырырга омтыла», – диелә. Аерым социаль шартларга бәйләнмичә болай, өстен сыйныфлар «телдә сыйныфсызлык характерын бирергә омтылалар» дип куя, хәзерге шартлар өчен дә, халык телен «урам теле» кара халык теле дип караган буржуа шартлары өчен дә дөрес булып җитми.

5. Әдәби тел белән шивә телләре мәсьәләсе дә социал-экономик шартларга, җәмгыятьнең сыйнфый төзелешенә диалектик рәвештә бәйләнми куела. «Әдәби тел, гадәттә, халык теленә каршы куела. Болар һәр икәве бер үк халыкның, бер үк тел коллективының телләре булсалар да, ләкин һәрхәлдә алар арасына тигезлек билгесе куярга мөмкин түгел. Халык теле – чуар тел», диелә (8 б.).

6. Шул ук биттә «Башлап кеше төркемнәренең ыру булып, аның артыннан милләт булып берләшүләрен санарга кирәк», диелә (6 б.) Бу уңышсыз тәкбир, Маркс-Ленин-Сталин өйрәтүе буенча феодализмнан капитализмга күчү чорында гына туган милләт төшенчәсен гомуми рәвештә ыручылык чорына ук илтеп тоташтыра.

7. Безнең шартларда тарихи рәвештә пантюркизм белән бәйләнгән баба тел теориясенә, тел гыйлемендә буржуа теориясе булган һинд-европачылыкка каршы, үзенең методологик мәсьәләгә якыннан кагылуына карамастан, китап бер сүз әйтми китә. Киресенчә, язучы бу теория тегермененә су коя торган кайбер уңышсыз тәд-

[1] В.И. Ленинның 1908 елда язылган, 1909 елда басылган «Материализм и эмпириокритицизм. Критические заметки об одной реакционной философии» дигән хезмәте.

[2] Бухарин Николай Иванович (1888–1938) – сәясәтче, дәүләт һәм партия эшлеклесе.

бирәләр куллана: «Хәзерге вакытта дөньяда бер-берсенә башка булган бик күп телләр бар, ләкин бу телләр үзләренең үсү процесслары буенча төбендә һәммәсе дә бергә генә кайтып калалар» (6 б.). Шулай ук 8 биттә. Укучы тәҗрибәсе бу формулировка студентларда телләр бердән күпкә таба үсеп барган дигән карашны калдырганы күрсәтә.

Татар әдәби теленең тарихына карата да 9 нчы биттә шул ук баба тел теориясенә тартым караш бирелә. Монда язучы болай ди: «Татар әдәби теленең тамыры ерак тарихка, XII–XIV йөзләр арасында Сыр-Дәрьяның түбәнге агымы хаузасында, Харәземдә һәм XIII йөздән алып Волга тамагындагы «Алтын Урда»да яшәгән кыпчак-угыз әдәби теленә барып тоташа. Кыпчак-угыз әдәби теле үз чорында бөтен төрек халыклары өчен уртак бер әдәби тел иде. Заман үтү, төрек халыклары арасында җәмгыять төзелеше үзгәрү белән бу уртак әдәби телдән хәзерге вакытта азмы-күпме (? – *Г.Ш.*) тарихка ия булган аерым төрек халыкларының үз әдәби телләре, шулар эчендә татар әдәби теле аерылып чыга» (9 б.). Җирле шивәләр нигезендә һәм аларның, бездә аерым әдәби тел туганга, формалашканга кадәр өстен сыйныфлар арасында элекке – руслардагы чиркәү теле, француз, немецләрдә латин теле кебек язу теле итеп куллангалап килгән «үле» төрки һәм башкалар белән башлангыч чорлардагы һәм аннан соңгы катнашулары нигезендә мәйданга килгән, үскән, интернациональ юнәлештә үсеп барган татар әдәби телен, ниндидер бөтен төрек халыклары өчен уртак бер телдән аерылып чыккан дип кую, билгеле, баба тел теориясе тегерменәнә су кою була. Телләр билгеле, монда куелганча бердән күпкә таба бармыйлар. Бәлки, Маркс-Энгельс-Ленин-Сталин куйганча, академик Марр[1] тарафыннан бик күп материаллар белән беркетелгәненчә, күптән бергә таба баралар. Русларда, татарларда һәм дөньядагы башка бик күп халыкларда, аерым милли әдәби телләр туганга кадәр, аларның өстен сыйныфлары язу (дин, дәүләт, әдәбият) теле итеп чит телләр йә «үле» телләр белән файдаланганнар икән, мондый телләр үз әдәби телләре формалашуына да тәэсир иткәннәр икән, бу фактларны аерым әдәби телләр бөтен төрек халыклары өчен уртак бер телдән

[1] Марр Николай Яковлевич (1864–1934) – филолог, тарихчы, этнограф һәм археолог.

аерылып чыкканнар» дип «ачу» – марксизм тел белеме нигезендә ачу дип карап булмый.

